Нәзифә Кәримова

# Сагынасыңмы, дип сорыйлар...

**Повесть, хикәяләр, пьеса**

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2004

УДК 820/89 (470)
ББК 84 (2 Рос = Тат) – 4
К 95

**Кәримова Нәзифә**

К 95 Сагынасыңмы, дип сорыйлар...: Повесть, хикәяләр, пьеса.— Казан: Татар. кит. нәшр., 2004.— 159 б.

Язучы-журналист Н.Кәримованың йөгерек, җор тел белән язылган повесть-хикәяләре тормышны җанлы итеп, истә калдырырлык образлар аша чагылдыруы белән әһәмиятле. Аларда туган җирне, яшьлекне сагыну балачак хатирәләре белән үреп бирелгән.

ISBN 5-298-01426-7
©Татарстан китап нәшрияты, 2004

# Повесть



# Карурманнан чыккан юлчылар...

Күрәзәчеләр, фалчылар, багучылар, йолдызларга карап язмыш маҗараларының бормалы сукмакларын ачып бирүчеләр белән дөнья тулы хәзер. Кемдер тылсым көче белән, кайберәүләр мәрткә китеп уянганнан соң бу кодрәтләргә ия булганнар, имеш. Баштарак бу кешеләр, аларның күрәзәчелек сәләте белән кызыксынсалар да, хәзер инде мондый шаккатулар узып бара. Аның урынын битарафлык, ис китмәү алыштыра. Шулай ук дөньяның асты өскә килү, өметсезлек элекке ышанулар белән хәзерге ышанулар арасында аерма китереп чыгарды.

Ә элегрәк, мин бала чакта, илленче елларда нинди беркатлы, сабыйларча ышанучан иде минем авылдашларым. Өмет белән ышаныч иде халыкның ике канаты. Хәер, безнең халыкның өметсез яшәгән чагы булды микән? Юктыр.

Әнә шул еллардан бүгенге көнгә кадәр минем өчен серле бер истәлек булып калган вакыйганы бик еш искә төшерәм мин. Тик аның төбенә һаман да төшенеп бетә алганым юк. Ул, авылдашларымның өметләре өстенә бәхет вәгъдә иткән серле вакыйга, авылга килгән сукыр күрәзәче белән бәйләнгән.

Ул вакытта әле авылда радио да, электр да юк. Читтән берәр кеше кайтса, халык җыелып, дөнья хәлләрен сораштырып белә торган заман. Шунысын да әйтергә кирәк, ул вакытта әле авыл советларының да кәттә чагы. Зурлар гына түгел, балачагасына хәтле бер-берсен «Авыл советы Хәбригә әйтәм!» дип куркыта. Ә «Кара кул» дип кушамат тагылган Хәбридән халыкның коты алынып яши. Дөрес, Хәбринең бик ягымлы, тәмле телле чаклары да булган. Донбасстан яшь хатын ияртеп, сул кулына кара бармакча киеп кайтканнан бирле, «җен алыштырган» аны.

Илленче еллар... Әйбәт, туклыклы, ипиле тормышка халыкның өмете түгәрәкләнеп килгән чаклар. Андый вакытта фал ачтыру үзе бер күңелле, чөнки алдагы тормыш матур, киләчәгебез якты икәнлеген фалчылардан башка да беләбез. Тик менә шул матур киләчәктә шәхсән үзем ничек яшәрмен микән ди-

гән хыял ачтыра ул фалны. Әлбәттә, ул «якты киләчәк» әле һаман да җир белән күк тоташкан урында, һаман да барып җитә алганыбыз юк ул якты киләчәккә. Без югарырак күтәрелгән саен, офыклар киңәйгән кебек тә, тик «якты киләчәк» һаман алга йөгерә, куып җитеп булмый әле. Ә ул вакытта... Якында, бик якында иде якты киләчәк. «Бәхет» дигән кадерле нәрсә берсенең ире, икенчесенең улы булып сугыш кырларында ятып калса да, өмет әле сүнмәгән, өмет әле күңелләрдә, ул яшәргә көч тә, бәгырьләргә ныклык та, сагышларга яктылык та өсти торган өмет иде ул...

Безнең бакча башыннан гына башланган, кул сузсаң орынырга торган каракучкыл-күгелҗем урман сихерле ул. Адаштыра торган урман. Бигрәк тә кыш көннәрендә. Хәер сорашып кайтканда, авылыбызның Гөлҗамал исемле кызы туңып үлгән бу кара урманда. Әнә шул Гөлҗамал өрәге адаштыра кешеләрне. Төннәр буе елый ул Гөлҗамал. Ипи сорый. Кыш көннәрендә, бигрәк тә кояш баеган вакытта, серле, куркыныч, тереклек качкан дөнья чите булып күренә миңа безнең урман. Тик ниндидер сихри көч белән үзенә тарта ул мине. Әни дә миңа, кояш баеган вакытның ниндидер тылсымга ия булган мизгел икәнлегенә басым ясап: «Кояш баеганда кычкырып көлмә, җырлама, иплэп йөр, зәхмәтле урынга басарсың, Ходайдан бәхет-тәүфыйк сора!» — ди. Бу сүзләрне әни иртәнге мәлләрдә дә әйтә әйтүен, тик ул вакытта бик куркыныч түгел, серлелек тә алай ук тоелмый. Ә менә кояш баеганда... Әни әйткән сүзләргә яшеренгән сер әнә теге күгелҗем-кара урмандадыр кебек тоела миңа. Әнә шул кара урманнан күтәрелгән кара җәймә әкрен генә авыл өстен каплагач, караңгылык төшә сыман. Мин, бакча ягына чыгып, шул серле кара урманга карыйм да Ходайдан бәхетемне, тәүфыйгымны сорыйм. Урманда адашып, ач көе туңып үлгән Гөлҗамалны кызганам. Шундый моңсу булып китә. Йөрәкне әллә нинди миңа аңлашылмый торган сагыш биләп ала, елыйсы килә башлый.

Юк, бик озак моңсуланып торырга мөмкинлек бирмиләр миңа. Чөнки ул вакытта өйдә эшнең иң күп чагы. Мал карыйсы да бар, су китерәсе, дәресләргә утырасы, җитмәсә, бала карау да минем өстә.

Ә инде эшләр беткәч, кич утырачаклар. Әни оек бәйләр. Әти киез итекләргә олтан салырга утырыр. «Кич буе бакчадагы каты карны ерып, итекләреңне эштән чыгаргансың!» — дип, мине ачуланып та алыр әле, мөгаен. Әгәр кич утырырга күршеләр дә керсә, бәлки, ачуланмас та. Күршеләр керсә, бик күңелле була кич утырулар. Әти инде ике унлы лампага да керосин салып кертеп элде. Тәрәзәдән төшкән сүрән яктылыкка карап, әни лампа куыкларын чистартты да, берсенә ут алып, сыер саварга чыгып китте.

Әти малларны карап бетергән, күрәсең, мал өеннән аның кычкырып-кычкырып сарык бәрәннәрен сөйгән тавышы ишетелә.

— Ну, тәтә соң безнең каракай! — Шап-шоп, шап-шоп.

Безнең беребезне дә болай каты яратканы юк әтинең. Бозауны ярата, сарык бәрәннәрен сөя. Ә нигә безне шулай каты яратмый икән? Бөтен яратуын бәрәннәргә бирә дә бетерә. Бишектәге сеңлемне сөйгәне бар барын.Үземнең күргәнем бар.

— Ну, тәтә соң безнең кыз! — дип сөйде.

Ә мине яратырга вакыты җитми, күрәсең. Бәләкәй чакта яраткандыр әле дип уйлыйм. Мин хәзер олы кыз инде. Тик шулай да бер дә бала карыйсым килми. «Бишек янына бәйләп куймый булмый инде сине»,— ди әни. Әле менә бүген дә бер дә өйдә утырасым килми шул, балага имезлек чәйнәп салдым да, бишек бавын энемә тоттырып, ишегалдына чыктым.

Бакча ягына чыга торган җилкапка бар безнең. Бернинди атынгыч та кирәкми бакча капкасы булганда. Аратасына басып, баганасыннан җиңелчә генә этеп җибәрәсең дә рәхәтләнеп атынасың. Капка ачылган чакта, ишегалдына карыйсың, капка ябылганда — урманга. Әти күрсә кирәкне бирер иде инде, тик ул мал өендә, мине күрми. Күгәнен каерып чыгарырмын дип курка, шуңа күрә атындырмый капкада. Ә капка әкрен генә ачыла да ябыла, ачыла да ябыла. Ишегалды — урман, урман — ишегалды, урман... Кинәт урман караңгылыгыннан ниндидер карамчык аерылып чыкты. Гөлҗамал өрәге! Әнекәем! Мин күзләремне чытырдатып йомдым да җиргә чүгәләдем. Әллә күземә күренде инде... Бик каты курыксам да, башымны күтәреп урман ягына карадым. Бу карамчык торган саен үсте, әкрен генә безнең бакчага якынлашты. Уф! Кешеләр икән. Икәү. Эчемә җылы йөгерде. Кемнәр микән болар болай соңлатып? Шушы кышкы кичтә, өрәкле урманда нишләп йөриләр микән? Мин яңадан җилкапкага үрмәләдем. Тегеләр тыкрык буйлап төштеләр дә безнең урамга керделәр. Тукта әле, урамга чыгып карыйм әле, кемнәргә керерләр микән... Шул вакыт, мине дерт итеп сискәндереп, әнинең тавышы яңгырады.

— Һаман киртә башында! Кереп кит өйгә! Бала елый торгандыр!

— Бала янында кеше бар бит анда...

— Эт эткә, эт койрыкка... Учакны кара, ут төшеп ятмасын. Утын ала кер әнә, бушка селкенеп йөрмә...

Эчемнән генә әнигә үпкәләп, утынлыкка таба киттем. «Бәхетле кешеләргә кунак кайта, миңа карап калырга да ярамый...»

Әкрен генә, утыннарның вагракларын сайлый-сайлый кочагыма төядем дә, өйгә кертеп , мич каршысына бушаттым. Бала да еламый, ут та төшмәгән. Тик бала карап арыган энем генә: «Мин дә урамга чыгам!»— дип шыңшырга тотынды.

— Үскәнем, еламасаң, мин сиңа кипкән җиләк бирәм...

— Җиләк... Бир...

— Хәзер, яме, тәрәзәдән карап тор, мин хәзер керәм. Әнә теге лапас торыгы астындагы урман печәне арасында җиләкләр беләсеңме күпме? Җиләкле аланнан чапкан печәннәр анда... Көтеп тор, яме... елама... яме...

Бу малайдан котылуыма сөенеп, урамга йөгердем. Тик теге кешеләр юк иде инде урамда. Тәрәзәгә карап алдым. Тәрәзәнең катмый калган өске өлешеннән энемнең ялтырап торган чәчсез маңгае белән тәрәзәгә таянган кулларын күреп алдым. Җиләк көтә инде бу малай. Ишегалдында эңгер-меңгер. Табарсың бу караңгыда җиләк. Эзләргә кирәк инде, көтеп тора бит. Кабат бала янында калдырып булмас аннары. Мин әле көндез үк торык астындагы печән арасында җиләк яфраклары күргән идем. Мин, учмалап-учмалап, ул печәнне йолкырга керештем. Шулай да, күп йолкый торгач, бер тәлгәш таптым бит! Кибеп, корышып бетсәләр дә, җиләк җиләк инде ул. Урман исләре килеп тора! Берсен генә авызыма каптым да калганнарын, энемә дип, бияләй эченә тыктым.

Шул вакыт урам капкасыннан ишегалдына бер көтү кеше килеп керде. Капка тавышына, лапас астыннан чиләк күтәреп, әни дә килеп чыкты. Бер көтү дигән идем, өч кенә кеше булып чыкты болар. Берсе Сәмигулла абый. Безнең урамның хәтәр озын кушамат тагып йөрүчесе «Кыл өстендә калды Сәми», ә теге икесе... Болар бит урманнан чыккан баягы кешеләр! Шулар, шулар! Таныдым мин аларны. Кулларындагы таяклары да, аркаларындагы биштәрләре дә... шулар...

— Исәннәрмесез! — диде Сәмигулла абый, ни өчендер як-ягына каранып. Әтине дә күрергә өмет иткән иде, күрәсең, ишегалдында әти күренмәде.

— Әйбәт кенә әле... Әллә кунаклар белән инде син, Сәмигулла,— диде әни, сораулы караш белән.

Кунаклар инде, кунаклар. Безнең авыллар түгел бит. Киемнәре дә әллә нинди сәер... Ир дигәненең өстендә солдат шинеленнән теккән пәлтә. Аркасында кычыткан капчыктан ясалган зур гына биштәр. Кулын хатынының иңбашына салган. Әстәгыфирулла! Сукыр бит бу кеше. Сукыр шул. Безгә дә йөзе белән карап тормый, янбашы белән баскан. Күзләре гел икенче якка караган... Йөзендә, борчыдык инде, гафу итегез, дигән сымак оялчан гына елмаю. Ә хатыны... Бигрәк ябык, бигрәк бәләкәй, шундый мескен кыяфәтле... Өстендә сырып теккән кыска бишмәт. Бишмәте астыннан чуар чәчәкле күлмәге күренеп тора. Ә башындагы сарык йоныннан бәйләгән шәлендә берничә ямавы да бар. Иңенә букча сымак кечкенә янчык аскан. Аягында олтанлы киез итек. Ә бите ап-ак. Шушы кышкы салкында да алсуланмаган да, ичмасам. Әллә урманда туңып үлгән Гөлҗамал инде... Ул Гөлҗамалны гомеремдә дә күргә-

нем булмаса да, бу ак йөзле апа бик охшаган иде мин жәлли торган Гөлҗамалга.

— Кунаклар дип инде, Мәүҗидә апа... Мосафирлар ди... Бер кич булса да кунып чыгарга кирәк икән аларга. Кая алып барырга да белмәдем. Авыл советына барырга соң инде. Хәбри абыйның өенә барырга курыктым. Айсылуттиләргә кергән идек, юк, юк, кертә алмыйм, өебез бәләкәй, дип, кире чыгарды...

— Безнең өйдән дә бәләкәй түгел инде аларның өе дә,— диде әни.

Сукыр абый йөзеннән елмаюын бер дә сүндермичә:

— Сезнең күңел киңрәк... дип куйды.

— Мәүҗидә апа, без китап ачучылар, диләр алар. Ничек була микән ул? Синең ишеткәнең бармы?

— Һәр кешедә тары бөртегедәй әүлиялык бар, дип әйтәләр, ә бу абыйда әүлиялык бар да бар,— диде әни.— Шулай булмаса каян белсен ул минем күңелнең киң икәнен. Әйдәгез, өйгә керегез. Туңып беткәнсез бит. Еракткан киләсезме?

Тегеләр бер сүз дә чыгармадылар. Берсе сукыр, әллә икенчесе саңгырау инде.

— Мәүҗидә апа,— диде Сәмигулла абый пышылдап кына,— Харис абый нәрсә дип әйтер микән?

— Анысы өчен кайгырма, Сәмигулла. Авыл сәвите түгел, кергән кешене куып чыгармас.

Өйгә килеп керүгә, бала бишегенә тотындым, тик теге кунаклардан күземне дә алмадым. Әни аларга җылы итекләр бирде, киемнәрен элеште, самавыр куеп җибәрде. Сәмигулла абый да чыгып китәргә ашыкмады. Ишек төбендәге сандык өстенә утырып, ярдәм итәргә әзер торулы кыяфәт белән, китап ачучыларны күзәтте.

Әни тагы бер мәртәбә ишегалдында биргән соравын кабатлады.

— Еракткан киләсезме? Кайсы яклар сез?

— Ерактан...

— Нишләп кичкә каршы юлга чыктыгыз соң?

— Без чыкканда көн иде. Юлда кич булды. Урманыгыз адаштыра икән. Юл таба алмый йөрдек...

Әйткән идем аны!

Кунак апа һаман да җылы таба алмый, ике кулын мичтән алмады. Ә сукыр абый, бишләрен кулыннан төшермичә, сәке йөзлегенә урнашып, кымшанмый гына утыра бирде.

— Шулай инде, шулай...— дип җөпләп алды әни.— Кышкы юлның җәяүлесе, хәзер кич була...

— Әле бүген ерактан килмибез. Кичә күршегездәге авылда идек. Сезнең авылны мактап, юлны күрсәтеп озатып җибәрделәр иртән. Гел караңгы төшкәнче монда килеп җитүебезгә бик сөендек әле. Урманы урман, басуларда юл юк...

— Быел кар тирән басуларда. Юкка гына «көртлекләр» димиләр инде безне. Иңкүлектә утырабыз бит. Юлны белмичә йөрсәң, адаштыра аның басуы да, урманы да. Нинди җилләр ташлады соң сезне кышкы юлга? Кәсеп итеп йөрисезме?

— Кәсеп итеп дип инде...— дип сузды сукыр абый.— Рәхмәт төшсен, безне алып килүче егеткә әйткән идек инде. Китап ачучылар без. Фалчылар. Ишеткәнегез бардыр инде?

— Нәрсә сөйли соң сезнең китап?

— Үткәнне, киләчәкне, язмышны сөйли...

— Язмышы кеше кулында түгел инде анысы,— диде әни.— Багучыга барма, башыңа бәла алма, диләр. Куркам мин багучылардан,— диде ул көлеп.— Йә үләсең дип әйтерләр.

— Үлмисең...— диде фалчы сузып кына.— Әнә теге чакта, Иделдән чыкканда көймәгез капланган булса, үлә идең. Ә хәзер юк, яшисең әле!

— Әнекәйләрем! Әллә син дә бар идеңме ул көймәдә, абыкаем! — диде әни шаккатып.— Безнең авылда да бар берәү, ногыт борчагы белән фал ача. Тик мондый күрәзәчене ишеткәнем юк иде әле.

Әни тиз-тиз табын әзерләргә тотынды. Сандык өстендә дөньясын онытып утырган, авызы бер карыш ачылган Сәмигулла абзыйга борылып:

— Ишеттеңме, Сәмигулла? Менә күрдеңме инде, нинди кешеләр килгән безнең авылга,— диде.— Бар, бу хәбәрне авылга тарат. Язмыш турында сөйли торган фалчылар килгән, диген, яме. Аның хакы күпме тора соң? Хакын нәрсә белән аласыз?

— Акча белән. Өч тәңкә,— диде сукыр абый.

Ишек тоткасына тотынган Сәмигулла абый ишетелер-ишетелмәс итеп кенә «өч тәңкә» дип кабатлады да ачык ишектән кергән суык пар эчендә йомылып калгандай юкка чыкты.

Кеше керсә, ни күп сөйләшә торган әни, арып килгән юлчыларны күп сүз белән интектермәде. Безнең белән дә сабыр булырга тырышып, ашатты-эчертте дә барыбызга да урын түши башлады. Чынлап та, күңелең киң булса, урын табыла икән. Без бала-чагалар сәкегә тәгәрәдек. Фалчыларга урынны идәнгә җәйде әни. Ә инде безнең күп сөйләшми торган әти, бу хәбәрне урамнан ук ишетеп кайткан иде, күрәсең, әнинең ризалык көткән сораулы карашына : «Ярар, гомерлеккә килмәгәннәрдер әле»,— диде дә сәндерәгә менеп ятты.

Икенче көнне бу хәбәрне ишеткәч, авыл беркавымга гөжләп торды. Хәбәрне таратуга Сәмигулла абый көчен җәлләмәгән, күрәсең. Каравыл өенә җылынырга кергән фермада эшләүчеләрнең дә, пужарныйга кич утырырга җыелган ирләрнең дә, су буендагы хатын-кызларның да телләрендә «фалчылар» дигән сүз булды. Ишетмәгәне ишеткән булып, ишеткәне күргән кебек итеп сөйләде.

Кичке якта чишмә буена җыелган хатыннар тагы шул турыда сүз яңарттылар:

— Бүре Бәдәренең кодачасы килгән, ди, Ушмыдан. Бу кешеләр алар авылында да булган икән. Шул кодача сөйләп торган, ди. Аларның күршесенә «Үләсең, быелдан калмыйсың!» дип әйткән фалчы.

— Әнекәем! Юк, юк, гомеремдә дә ачтырасым юк ул фалны! Турыдан-туры «үләсең!» дигән кешегә өч тәңкә акча чыгарып тоттырырга монда! Әндри казнасы юк!

— Нәрсә сөйлисең син! Нишләп күрә торып, тере кешегә син үләсең, дип әйтсен ул?

— Күрә торып булса әйтмәс иде, дөм сукыр, ди. Сукыр булгач әйтә дә әйтә инде, шуның өчен акча ала бит ул.

— Ышанмагыз шул Бүре Бәдәренең сүзенә, кызлар! Ногыт борчагына фал ачтыручылар бетәр дип курка ул. Бер тамчы да дөрес күрсәтми борчагы. Ачтырып караганым бар инде,— диде Нәсимә.— Килгән саен, «Быелдан калмыйсың, чыгасың кияүгә!» дип җибәргән була. Йә, әйтегез әле, кая соң ул кияү?!

— Мич алдында күмер ашый сиңа дигән кияү...

— Ашасын иде әле. Миңа насыйп була, дисәләр, үскәнен күтәргә дә риза. Ә Бәдәр сибә генә борчагын.

— Әй, сөйләп тормагыз әле шуның сүзен,— диде Хәбибулла абзыйлар килене Гөлбостан.— Уйлап чыгарырга булса, аңар куш инде. Урманда җиләк пешә башладымы, урманда качкыннар да гел аңар гына очрый. Чикләвек җитлегә башласа, котырган бүре белән кабан дуңгызы да гел аңар гына ташлана. Килен булып сезнең авылга килгәннән бирле шаккатып йөрим мин сезгә. Бигрәк беркатлылар сезнең авыллар. Шуның сүзенә ышанып җиләксез дә, чикләвексез дә каласыз. Җәй җиттеме, урманга кермәслек итеп, халыкны куркыта да куя. Безнең авыллар булса, күптән акылга утыртырлар иде инде. Ә кыш буе кипкән җиләкме, чикләвекме ул гына сата.

— Кызлар, ишеттегезме, өстерелек Абдул белән йөри, дип әйтәләр аны.

— Йөрер шул, йөрмичә,— диде Нәсимә.— Урманда икесе генә калгач!

— Икәү генә дигәннән, бу китап ачучылар да икәү, ди. Ирле-хатынлы, ди.

— Китапны ире генә ача икән, ә хатыны иптәшкә йөри, ди.

— И-и, кызлар! Икәү вакыт бәхетле вакыт инде ул. Сукыр булса да, ир ир инде ул. Аның бөтен җире дә сукыр булмый. Көлмәгез, кызлар, көлмәгез. Их, Ризагым исән булса! Белмим, кызлар, кемгә нәрсә, мин үзем үткән гомерем турында сорар идем. Алдагысы кирәк түгел, язмышы да Алла кулында... Ризагым исән чакта матур яшәгәнбез икән, кадерләрен генә бел-

мәгәнмен. Шундый өметле күренгән иде тормыш... Ул бала-чагаларны ничек аякка бастырырмын...

— И-и, Фәгыйлә! Өметең сүндемени шулай ук. Ирнең үгие булмый аның,— диде Фаягөл.— Хатын-кызларның унике чырасы була, берсе сүнсә, икенчесе яна, диләр. Шушы яшеңнән киләчәгем кирәк түгел, дип торасың. Утыз улың булганчы...

— Әй, сөйләп торма инде, Фаягөл! Миңа түгел, әнә ябь-яшь Нәсимәгә дә юк әле ул кияү. Кырды бит сугыш өрлектәй ирләрне. Яралары булмаса, минем Ризагым исән булмас иде дисеңмени?

— Алай димә син, язган булса...

— Булмас, булмас... Ымсынмыйм да. Аннан соң тәкәрлек күкәе шикелле кендеккә кадәр сипкелле бу тәнемне күрсәтәмме соң башка иргә.

— Кара әле, фалчыга барам, дидеңме? Әллә үткәнеңне тагы бер ишетер өчен генә дә бирер идеңме акчаңны?

— Тамчы да жәлләмәс идем, акчасы юк әле аның. Булса да барыбер куркам. МТСларда күп йөрде, сугышны айкап кайтты. Сине генә яратмаган, башка мәхәббәтләре дә булган дисә, нишләрмен?

— Ышанмассың! Менә юләр! Ачкан бер фалга ышана барсаң. Мин барыбер ышанмыйм фалга, хет әллә нәрсә дисеннәр. Ачтырып караганым бар минем,— диде Нәсимә.

— Мәүҗидә апаларда, ди ул фалчылар. Менәбезме бүген кич белән?

— Менмичә, менәбез. Үзебезнекен белмәсәк, кешенекен ишетербез.

— Бәдриҗамал! Кул эшеңне онытма, яме! — дип кычкырды Фаягөл.

Чиләкләренә суны иң беренчеләрдән алган, самавыр борыныннан чыккан кебек әкрен генә ага торган чишмәдән дүрт-биш пар чиләк тулганны көтеп, бер генә сүзләрен дә ишетми калмыйм дип авызын ачып тыңлаган Бәдриҗамал, үз исемен ишеткәч, талпынып куйды. Кинәт, хатыннар абайламый да калдылар, чиләкләренең икесе ике якка атылып китте, көянтә алга очты, куллары белән һаваны бутап, чишмә юлының тар сукмагына Бәдриҗамал лапылдап килеп тә төште.

— Нәрсә булды?

Бу тамашадан тыела алмый көлгән хатыннарның үз хәлләре хәл иде. Бәдриҗамал урыныннан торса да, һич кенә дә аягын күтәреп атлап китә алмады. Селкенми дә басып торган Бәдриҗамалның киез итеге бозга ябышып каткан булып чыкты. Хатыннар, көянтә-чиләкләрен куеп, Бәдриҗамалга ярдәмгә ашыктылар. Киез итекне әкрен-әкрен генә боздан кубарып алганчы, чиләкләренә су да алып бирделәр. Ярый әле итек олтаны да урынында, чиләкләренең дә төбе төшмәгән. Бәхетле бу

Бәдриҗамал! Бер җире дә авыртмаган тагы, үзе башкаларга караганда да кычкырып көлеп, су буйларын яңгыратып җибәрде.

— Бәхетле мин, кызлар! — диде Бәдриҗамал.— Фалчыларың бер якта торсын! Итеге дә соңгы пар, чиләге дә соңгы пар дигәндәй, берсенә дә зыян килмәде, Аллага шөкер!

Хатыннар, берсе артыннан берсе тезелешеп, тар сукмактан өскә менә башладылар.

Югары очтан, елганың теге ягыннан, чиләк-көянтә аскан Хәбри хатыны Сәгыйдә суга төшеп бара иде.

— Нигә шулай кеше сөймәс хатын микән бу? — диде Фаягөл.

— Иреннән курка торгандыр,— диде Фәгыйлә.— Хәбри җанын ала бит аның. Авылда ничә ел бит инде, күршеләренә дә керми, диләр аны.

— Мескен,— диде Нәсимә .— Ни туганы, ни тумачасы.

— Аның каравы ире — Хәбри,— диде Фаягөл.

— Ире-е, «Хәбри хатыны» булмаган хатын сирәктер безнең авылда,— диде Нәсимә.

— Әллә синең дә капкаңны кактымы?

— Хәзер сезгә барысын да әйт, барысын да сөйлә! — дип, сүзне уенга борды Нәсимә. Тик шунда ук җитди тавыш белән.— Кагып карасын! — диде.— Хатынын җәллим мин аның. Нишләп тора диген. Бала-чагасы юк. Дүрт ягы кыйбла.

— Яратып тора. Ач-ялангач түгел,— диде Фаягөл.

— Яраткан кеше алай яшәми ул,— диде Фәгыйлә.— Донбасс тикле җирдән нишләп ияреп кайткан диген син аны. Хәзер бик китәсе килсә дә, милиция белән кайтартам мин сине, дип әйтә ди Хәбри. Китеп кая барсын, кайда да бер кояш...

Хатыннарның чиләкләрендәге суларының өсләре чыйрап, боз булып капланып бара иде инде. Әле чатка барып җиткәч тә, аерылып китәр кебек түгелләр иде. Тик шул вакыт, кәнсә урамыннан бураннар уйнатып килгән ак айгыр җигелгән кошевканы күргәч, төрле якка сибелделәр. Кошевка сыздыртып үтеп китте, ә кошевкада, толыпка төренеп, кырын яткан кеше авыл советы рәисе Кара кул Хәбри иде.

Фалчылар турында һәр өйдә дә сөйләштеләр. Бөтенесе дә кичне көтте. Югыйсә читтән килеп кәсеп итеп йөрүчеләр авыл өчен бер дә ят нәрсә түгел инде. Безнең авылда самавыр төзәтүчеләр дә, кием тегүчеләр дә юк. Бу эшләрнең барысын да әнә шулай, фалчылар кебек, читтән килгән кешеләр эшләп китә. Яз җиттеме, ике көннең берендә, тәрәзә артыннан көйләп әйтелгән моңлы тавыш ишетелә.

— Самавыр төзәтергә юкмы, самавыр!

Авыл халкы бу тавышка күнеккән инде. Бары тик бала-чагалар гына, мондый кешеләрдән кызык табып, аларга ияреп, әче тавыш белән самавыр төзәтүчеләргә «ярдәмгә» чыгалар.

— Самавыр төзәтергә юкмы, комган!

Әнә шулай кычкырып, арбаларын тартышып, авыл башына чаклы озаталар ул кешеләрне. Кычкыруга оста без, башкасын булдыра алмасак та. Ә гомумән алганда, безнең авыл кешеләре яхшы күңелле, эчкерсез, беркатлылар. Үзләренең беркатлылыкларыннан сөенеп, тәм табып яшиләр алар. Хәйләсезләр. Шуңа күрә кәсепләре дә юк аларның. Кәсепле кешегә кирәк ул хәйлә. Ә боларның кәсебе булмагач, нәфесе дә юк. Авылның бар кешесенә җитәрлек итеп, шаяртып тагылган кушамат та бар. «Көртлекләр» диләр безне. Ни өчен көртлекләрме? Кар күп ява безнең авылда. Чөнки чокыр эченә урнашкан безнең авыл. Ә инде кыш җиттеме, көртлекләр кебек кар эченә чумабыз да калабыз. Кышкы юлда безнең авылны бик интегеп кенә табар кеше, тапса да. Авылыбызның иң зур керем чыганагы — бәрәңге. Шул бәрәңгесен сатып салымын да түли, киемен дә ала, тормышын да алып бара. Авыл кешеләренең беркатлылыгын күрсәткән бер хәлне дә сөйләп китсәм, безнең кем икәнлегебезгә тәмам ышанырсыз.

Әнә шул бәрәңге сатып көн иткән вакытларда, күршебез Касыйм абыйның мактанып сөйләгәнен ишеткәнем бар.

— Кенәген базарда Иске Комазаннарны күрдем әле. Билләһи, үзләре танып, килеп күрештеләр.

— Безнең кодалар түгелдер бит,— диде капка төбенә җыелышкан ирләрнең берсе.

— Юк ла... белгән кешеләрем түгел... Менәтерә, «абый, син Арташтанмы әллә?» дигәч, шаккаттым. Нәрсә, мин әйтәм, маңгайга язылганмы әллә, фәлән фәсмәтән!

— Һәй, сезне танымаска, көртлекләрне! — ди бит теге, билләһи! Башта мине таныдылар дип, бик сөенгән идем, «көртлекләр» дигәч, ачу чыкты, малай! Үземнең субсунный кушаматны да әйтсә, билләһи, мин әйтәм, базар уртасы дип тә тору юк иде, тозлап-борычлап яңак тамырына ямау салам дип, менә шушы йодрыкны чытырдатып йомарлаган идем. Эш алайга ук барып җитмәде, авызы ерык тегенең. Көлеп торган кешегә ничек сосмак кирәк. Ярый, мин әйтәм, күргәнең, күрмәгәнең шул булсын, таныгансың икән, әйдә таны! «Һәй, сезне танымаска! — ди бу һаман.— Мин бит сине үзеңнән түгел, атың белән арбаңнан таныйм! Дилбегәңдә ничә төен? Атыңның аркасына ыңгырчак суккан! Сездә генә бит ул төенле дилбегә. Атыңның дагасы да юктыр әле... әйтәм бит. Арба тәгәрмәчләрендә дә агач чәкүшкә! Май чүлмәге тышыннан билгеле, диләрме әле, әллә кайдан күренеп тора Арташтан икәнең!»

— Каян килгән эз танучы малай, мин әйтәм. Әйе шул, безнең авыллар югала торган түгел! Сезгә барып арбага чәкүшкә сораган юк әле. Ә дилбегәдәге төеннәрне Гөлсирә апаң төйнәп җибәрде, мин әйтәм, аласы әйберләр төене ул, онытмаска. «Ярар,

ди бу, шаяртып кына әйтәм... Шул төен чаклы әйбер бөтен кибетләрдә дә юк бит ул. Серкәң бер дә су күтәрми икән. Арташлар бик ачык күңелле кешеләр, дип ишеткән идем» ди. Шуннан дуслашып киттек.

— Дуслашып! Ул сине мыскыл итеп торсын, ә син дуслаштык, дип сөенеп торасың, сабый!

— Минме! Иткән пычагым! Нишләп мыскыл итсен ул мине! Дилбегә синеке! Әле Гөлсирә апаңа сылтаганга рәхмәт әйт. Бу бер! Ат колхозныкы. Бу ике. Арба Шәйдинеке! Бу өч! Арбадагы бәрәңге үземнеке иде, анысын, күз ачып йомган арада, талашып алып бетерделәр.

— Очсыз җибәрдеңме әллә?

— Очсыз дип инде... Бәрәңге бәһасе... Шәһәр хатыннары белән сатулашып торырга...

Касыйм абый көлеп җибәрде. Кызык халык бит шәһәр хатыннары, каһәр! Кайсы мыегымны мактый, кайсы чиләгемне яратты, аның бәрәңгесен әйтмим дә инде... Ә менә берсе...— Касыйм абый пышылдауга күчте,— Гөлчирә апаң кадәр ике булыр, ипидер менә, ул иреннәр, мин сиңа әйтим, кып-кызыл, ул йөрешләр! Бар бит шәһәр җирендә хатыннар! Анысының өенә үк илтеп бирдем. Карап торуга лашман бияседәй, ә үзе боргаланган була: «Бик авыр булды бит әле, бәлки, ярдәм итәрсез тол хатынга»,— дигән була.

— Потлы чиләкләр белән җибәрдеңме әллә?

— Потлы инде, потлы. Бәрәңге бит ул, җиләк түгел. Ашасыннар рәхәтләнеп. Тегене әйтәм әле, башка вакыт килгәндә, атыңны үземә куеп торырсың, дип, каш сикертеп, бил уйнатып калды озатканда. Кара әле, монысын сиңа гына сөйлим, дилбегә биреп торганың өчен, кешегә тишә күрмә, яме. Базарга баранитә калсаң, әдрисен сиңа да бирермен.

— Әнә шундый безнең авыллар. Барысы булмаса да, күбесе шундый. Фал ачучылар бик белеп килгән безнең авылга.

...Кич белән өй тулып халык җыелса да, берсе дә «Мә өч тәңкәмне, кара әле китабыңны, нәрсә дип әйтә микән» дияргә базмады. Бик тыйнак кына, авыл хәлләрен сорашып кына утыра башладылар.

Кешеләр җыелгач, фалчы абый янында гына яткан капчыгын капшарга тотынды. Ә фалчының ап-ак йөзле хатыны, анысы да үзенә эш тапты, бертуктаусыз бала бишеген тирбәтте. Әллә кайчан йоклаган баланы тирбәтә дә тирбәтә. Безнең өйгә килеп кергәннән бирле, «рәхмәт сезгә»дән башка бер генә сүзе дә ишетелмәде әле аның. Әле әнинең сөйләшеп утырырга вакыты гына юк, безнең әни телсезне дә сөйләштерә ул. Аулакта гына калсыннар әле. Исемен дә белгәнем юк әле. Үзе әйтми, ә мин сорарга оялам. Эчемнән генә Гөлҗамал дип исем

бирдем мин аңар. Урманда адашып үлгән Гөлҗамалны нәкъ менә шундый итеп күз алдына китергән идем. Кем белә, бәлки, ул Гөлҗамал үлмәгәндер дә әле, адашып йөргәндер дә фалчыга ияреп авылга кайткандыр. Үзен танытмаска гына эндәшми утырадыр, кем белә...

Фалчы абый капчыгын чиште дә өстәлгә бер-бер артлы өч китап тезеп салды. Башын югары күтәребрәк, ярым йомык күзен түшәмгә текәп, бар серләре эчендә микән дигән шикелле, бик җентекләп, китап битләрен капшарга тотынды. Мин арттан гына килеп, үрелеп аның китабына карадым. Әнекәем! Бер генә хәреф тә юк аның эчендә! Төртке дә төртке! Менә нинди була икән ул фал китабы.

Сукыр фалчы кинәт елмаеп җибәрде, тамагын кырып куйды да, басынкы тавыш белән:

— Әһ-һем, мин сезнең авылга бер генә көнгә килдем, иртәгә китәм...— диде.

Җыелышкан хатыннар аның ни әйтергә теләгәнен тиз аңлап, бер-берсен кыстарга тотындылар.

— Әнекәем, бармагы белән укый...— дип пышылдады Фаягөл, шәл бәйләвеннән туктап.

Барысыннан да алдан килеп, сандык өстеннән урын алган Сәмигулла, бу хикмәтне табуда үзенең дә өлеше барлыкны сиздереп, мич казнасына арка терәп, идәнгә тезелешкән хатыннарга тантаналы караш ташлады. «Безнең өчен чүп тә түгел ул бармак белән уку» дигән кыяфәт белән аягын аягына атландырып куйды да, уч төпләренә төкереп, ике кулын ышкып алды, хәзер башлыйбыз, янәсе.

— Ягез инде, бер батыр да юкмыни, яшьләр! Әйдәгез инде, безнең туй узган, тун тузган,— диде җеп катып утырган Бәдриҗамал.

— Әнә Сәми чүт тыелып утыра, өстерәгез әле шуны уртага! — диде ак кәтүк җебеннән челтәр бәйләп утыручы Нәсимә.— Кайчан өйләнәсен әйтер үзенә. Йөри шунда йөрәк яндырып.

— Әйдә, әйдә, Сәмигулла! Гомер буе «кыл өстендә калды Сәми» булырга димәгән, ал әле беренчелекне,— диде Фәгыйлә апа, утырган җиреннән Сәмине чабуыннан өстерәп.

...Сәмигулланың бу кушаматы үзе туганчы ук нәселе табып куйган кушамат түгел, үзе дөньяга килгәч, аның үзенә генә атап тагылган кушамат. Бу хәл болай була. Сәмигулла туып, берничә айлык чагында, әбисе белән бабасы күрше авылга кунакка китәләр. Үзләре генә калган әти-әнисе, аулак өй ясап, өй тутырып яшьтәшләрен җыя. Китә уен, китә җыр. Кысып биләүгә бәйләнгән баланы мендәргә салалар да сәке түренә куялар. Уен-көлкеләрдән соң, яшь җилкенчәкләрнең күбесе аулак өйдә кунарга кала. Кайсыдыр баланы күрмичә мендәрен тартып алганмы, ничек булгандыр инде, бала тәгәрәп китә, сәке

йөзлегенә килеп җитеп, идәнгә төште дигәндә генә, әтисе эләктереп ала моны.

— Ну, егетләр, кыл өстендә калды Сәми! — дип кычкыра ул, сабыен күкрәгенә кысып.

Әнә шулай дип әйтү җитә уен-көлке белән кич утырган яшьләргә. Әтисенең шул сүзләре кушамат булып ябыша да кала Сәмигуллага. Шул вакыттан бирле «кыл өстендә калган» Сәмигулла һаман да кыл өстендә. Шуңа күрә бар нәрсәдән дә куркып яшәргә өйрәнгән ул. Гомер буе нахак сүз, нахак бәла белән көрәшә Сәмигулла. Каравыл өендә мич юшкәсен кайсысыдыр куптарып киткәч тә, гаепләне бик төпченеп эзләп тормадылар, Сәмигуллага сылтадылар да куйдылар. Авыл советы җыелышында бу хәлне тикшергәннән соң, Кара кул Хәбри ун көн хезмәт көнен кисәргә дигән карар чыгаргач:

— Кыл өстендә калды Сәми! — диделәр.— Ярый әле заманасы икенчерәк. Теге елларда булса, болай гына калмас иде. Кыл өстендә калса да, бәхете бар икән!

— Тентү белән керсәләр табалар иде инде,— диде җыелыштан чыгып килүчеләрнең берсе.

— Юк миндә ул нәрсә, юк! — диде Сәмигулла ачынып.

— Нишләп булмасын, мичегездә нәрсә, төннекмени?

—Анысы әллә кайчангы бит аның, үзебезнеке!

— Кәҗүнни нәрсәгә катышкач, кубарып та чыгарлар, шаяртма!

Нәрсә дисен Сәмигулла, бәхете шундый булгач. «Их!» диде дә йотты. Ун хезмәт көне нәрсә ул бер уйлаганда. Ике йөз граммнан өләшсәләр дә, ике кило арыш. Шул да булдымы югалту. Тик андамыйни эш! Гарьлек бит! Оят, кызлар алдында оят, их!

...Фәгыйлә апа чабуыннан тарта торгач, Сәмигулла урыныннан торды да салкын суга башы белән чумарга әзерләнгән кешедәй «Ух!» дип куйды.

— Әй, булмаса булган икән! — диде ул, кулындагы бүреген сандык өстенә бәреп.

— Абый, менә сиңа өчлек, ышанмасаң, әнә җиңәчәйдән сора. — Бала тирбәтеп утырган фалчының хатынын сискәндереп, өчлекне аңа да күрсәтте.— Кулым җиңел минем. Калганын син әйт!

— Утыр,— диде фалчы.

Сәмигулла тезелешеп утырган «тамашачыларга» каш сикертеп алды да фалчы каршында әле һаман да буш торган бүкәнгә чүмекте.

— Исемеңнең баш хәрефе ничек? — дип сорады аннан фалчы.

Сәмигулла бу сорауны көтмәгән иде бугай, кая, кайсыгыз белә минем исемне, әйтегез әле дигән шикелле, аптыраулы караш белән хатыннарга текәлде.

Тегеләре дә эшләрен ташлап, берсүзсез калып, бер-берсенә караштылар. Бу сорау барысының да зиһенен таратып җибәрде.

— Ничекме... Сәми... Сәмиыйк... Сәмигулла! — дип кычкырып җибәрде ул.— Мулла кушканы Сәмигулла!

Фалчы өч тәңкәне учына кысты да бармаклары белән китабының битләрен капшарга кереште. Акчалы кулы белән укыды китабын. Күрәсезме, сезнең акча йөртә минем бармакларны дип әйтәсе килү микән, әллә акчасыз ачылмый микән аның фалы.

— Бер дә сүзең үтми икән,— диде фалчы.— Ышандыра алмыйсың кешеләрне. Шуңа күрә үзеңне нахактан да саклый алмыйсың... Күптән түгел сине тимер әйберсе урлауда гаепләгәннәр... Тик синең эшең түгел бу, биредә башка кул уйнаган.

Бу сүзләрдән исе китkән Сәмигулла тирләп чыккан битен сыпырып алды да фалчының авызына керердәй булып алга иелде. Сукыр абый әкрен генә китабының тагы бер битен ачты. Тик Сәмигулланың алга таба да әйткәннәрне көтәргә тамчы да түземлеге калмаган иде, күрәсең, ул урыныннан сикереп торды.

— Менә шулай, авылдашлар! Ишеттегезме инде! Еландай телләремне чыгарып ялындым бит! «Мин түгел!» дидем. Ышанмадылар. Ун хезмәт көнемне кистеләр шул гайбәт өчен. Менә минем сүзгә ышанмасагыз, гөнаһсыз сукыр әйтте дә бирде.

Фалчыга «сукыр» дигән сүзне күп ишетергә туры килгәндер, күрәсең, йөзен дә бозмады, каршы да әйтмәде, бары тик сукыр күзләре генә тартышып куйды.

— Булды, абзый! — диде Сәмигулла.— Шунысы иде глауный. Калганы пүчтәк. Әнә Хөснүрияттигә әйтерсең күбрәк итеп. Калган акчасы хәердән булсын. Тоталар да «Сәми каравыл өеннән юшкә урлаган!» диләр. Җыелыш саен торалар да «Сәми каравыл өеннән юшкә урлаган!» диләр. Ишеттегезме инде: ур-ла-ма-ган! Сүз үтми минем, анысы да дөрес.

— Урыныңны бушат,— диде фалчы.

— Утыр Хөснүриятти, рентгенга синең чират! — диде Сәмигулла. Минем яхшылыгымны белеп бетермисез әле сез дигәндәй, өй тулы халыкны тагы бер мәртәбә күздән кичерде. Сандык өстендәге бүреген табып башына киде дә, кош тоткандай сөенеп, өйдән чыгып чапты.

Сәмигулла ишегалдында үзләренең чиратларын көтеп торучы яшьтиләре янына килде.

— Кая, көйрәтик әле,— диде ул, кулын сузып.— Кайсыгызда бар? Ишеттегезме инде?

— Ишеттек, ишеттек,— дип көлештеләр тегеләр.— Синең шулхәтле кычкыруыңа, авыл советында да ишетелгәндер ул.

— Ишетелсен,— диде Сәмигулла.— Җитәр инде, кот алынып күпме яшәргә була. Егетләр, әйтеп калыгыз яхшы чакта,

өч тәңкәмне җәлләмим, валлаһи яңадан кереп сорыйм, барыбер табам кемдә икәнен!

Әле бу минутка чаклы бу юшкәне эзләү, табу аның башына да килмәгән иде. Ә хәзер табасы килеп китте. Кемдер алган бит инде аны...

Ул, нидер исенә төшкәндәй, кызулап, каравыл өенә таба атлады. Юл уңаенда пожарныйга да кереп чыкты. Андагы «кич утыручылар» авылның соңгы хәбәрләрен сөйлиләр иде. Ә менә Сәмигулланың соңгы хәбәре егып салды «кич утыручылар»-ны. Ышанырга да, ышанмаска да белмәделәр. Шулай да кайберәүләр, төпчекләренә төкереп, урыннарыннан кузгалды. Соңгы хәбәрләрнең үзәге безнең өй иде бүген.

Ә Сәмигулла, фалчы әйткән сүзләрне тагы бер мәртәбә күңеленнән үткәреп, авылның буш урамы буйлап, фермалар ягына таба китеп барды. Нәрсәләр диде соң әле аңар фалчы. «Юшкәне син урламагансың»,— диде. Тагы нәрсә диде соң? Башка бер сүз дә әйтмәгән бит бу! Ә язмыш? Ә алдагы көн? Эх!

Сәмигулла шушы уйлар белән каравыл өенә килеп җитте.

Анда ут яна, димәк, эчендә кем булса да бар. Тик Сәмигулланың шатлыгы алай ук түгел иде инде. Хәзер аның башта шатлыклы булып тоелган бу хәбәргә ачуы да килеп китте. Шул ачу белән каравыл өенең ишек тоткасына тотынды да, ишекне түбенә кадәр каерып ачып, эчкә атлады. Кергәч тә Сәмигулла бер мәлгә аптырап калды. Әле яңа гына фалчыга керергә дип үз чиратын көтеп калган Тимершаны монда күрермен дип һич кенә дә башына китермәгән иде. Шул арада ничек өлгергән дә, кыш көнендә кызыл балчыгын кайдан алган диген! Тимерша теге «Сәми урлаган» юшкәне иплəп кенә урынына урнаштырып маташа иде.

— Иплисеңме? — диде Сәмигулла, беркавым өнсез торганнан соң.

Бөтен авыл фалга җыелган дип уйлаган Тимерша кеше килеп керер дип көтмәгән иде, күрәсең, шулай да, каушавын сиздертмәскә тырышып, баскан урындыгыннан сикереп төште дә, мыскыллы оятсыз карашын Сәмигуллага текәп, балчыклы кулын мич йөзлегенә ышкый башлады.

— Күпне күрмә, яме,— диде ул янап.

— Ишшу куркытып торган була, хәчтерүш! — диде Сәмигулла.— Мышнавыңны бел. Мин алмаганны әйткәч, кем алганын да әйтеп бирер дип курыктыңмы. «Каракның бүреге янаа!» дип утырган була бит әле җыелышта. Синең башны пешергән ул бүрек.

— Әллә мин алдым дип әйткәнне көткән идеңме?

— Синнән кем яхшылык көтсен! Ярый инде җиде ят килеп йөземне аклады. Әле дус, яшьти, дип йөргән була. Шушы юшкә аркасында алдагы тормышымны да сорарга оныттым. Менә

хәзер баш ват инде: Сажидәгә өйләнергәме, Вәгыйзәгәме? Шушы кәҗүнни юшкә аркасында яшь тормышым чәлпәрәмә килсә килер икән.

— Тиле, әллә шул сукырның сүзенә карап өйләнер идеңме?

— Нишләп өйләнмәскә? Аннан да дөрес сүз әйтүчене очратканым юк әле минем. Бар, ышанмасаң үзең сора. Сатып алгандай булдым мин бу юшкәне. Өч тәңкә акчаңны бир дә, юшкә сүзе чыгуга, җан-фәрманга чыгып чап, имеш! Бар, бар, бәлки, сиңа да акыл өйрәтер!

— Үз акылым үземә бик җиткән минем. Әле сиңа ачкан фал да миңа китереп сукты. Синең кебек шыр тиле түгел лә мин, халык арасына чыгып, «Тагы ниләр урлаганымны ачып салыгыз әле» дияргә. Барыбыз да колхозда яшибез.

— Анда барып сорамасаң да беләләр синең кем икәнлегеңне. Синең ише ике катлылар түгел, минем ише беркатлылар кешесе ул фал ачучы.

— Беркатлы...— диде Тимерша, мыскыллы көлеп.— Җитәкләп, өйдән өйгә фатир эзләшеп йөргәч, юшкә нәрсә, бәлки, өйләндереп тә китәр иде.

— Нәрсә! — Сәмигулла Тимершаның якасына килепябышты.

— Шаяртып кына әйттем бит,— диде Тимерша, Сәмигулланы үзеннән этеп җибәреп.

— Бәйләнеп торасы килми,— диде Сәмигулла. — Утлы табага бастырырга була иде инде сине.

Ул шулай диде дә, каравыл өенең бозланып каткан ишеген тибеп ачып, тышка чыгып китте.

Ул чыгып киткәч, Тимерша җиңел сулап куйды. Тәрәзә янына килеп, ярыйсы гына кер күтәргән чуар тәрәзә пәрдәсенә кызыл балчыклы кулын сөртте һәм, теш арасыннан сызгыртып төкереп, әче итеп сүгенеп куйды.

Сәмигулла чыгып киткәннән соң, фалчыга килүчеләр бераз көлешеп шаулап алдылар. Кайберәүләр тел шартлатып, башын чайкап куйды, «ишеттеңме?» дигәндәй, бер-берсенә мәгънәле караш ташладылар. Күпләрдә фал ачтыру нияте ныгыса да, бияләй эчендәге өчлекләрен тирләгән учларына ныграк кысып, тагы бер ике кешегә әйткәнче түзәргә булдылар. Күпләре кесә төпләренә төшеп җитә алмый «азапланды», кесә төбенә төшеп җитсә, ничек тә бер өчлекне тартып чыгарыр кебек иде кыяфәтләре. Ә инде сәкегә терәлеп утырган ике карчык Шәрифелтти белән Хәбибҗамалтти оек кунычларын капшап куйдылар. Фаягөл йомгагына карап алды. «Җепне азрак алганмын, өйдәгесен дә калдырмаган булсам, бу шәлнең уртасы бүген бәйләнеп бетәсе булган икән» дип уйлады ул. Аның янына утырган Бәдриҗамал башын артка ташлап, авызын ачып, йоклап китеп бара иде. Бу шау-шуга кинәт уянып китте дә, мин-

нән көләләр, ахрысы, дип уйлап, каударланып, җилкәсенә шуып төшкән яулыгын рәтләргә кереште. Алдындагы бәйләме идәндә, ә йомгагы, әллә кайларга тәгәрәп, песи баласына уенчык булган иде. Бәдриҗамал тиз генә бәйләмен күтәреп алды да, йокы аралаш ялгышып, бишинәнең күзәнәклесен тартып чыгарды да ашыга-ашыга күзәнәкләрне җыярга тотынды. Ул монда бүген кул эше белән генә килмәгән, ире Миңлекәйне дә иярткән икән. Өйалдыннан анысының бертуктаусыз кычкырып көлгәне ишетелеп торды. «Миңле» кушымчасы тагылган кешеләр күп безнең авылда. Миңлегөлләр, Миңлебикәләр генә дә әллә ничә. Хәтта бер Миңлерафаел да бар. Бәдриҗамал белән Миңлекәй кебек пар килгәннәре сирәк. Ник моны эшләмисең юк, кайда йөрисең юк. Әме — ә, җәме — җә. Ул дуслык, ул татулык, бөтен авыл шакката аларга. Унлап бала үстерделәр. Балалары да менә дигән. Тормышларында һәрвакыт шаяру, уенкөлке. Аларга карасаң, тормыш бик тә җиңел кебек тоела. Утын кирәк, печән юк дип тә кайгырмый алар. Уйнап-җырлап, биеп-көлеп дигәндәй алып баралар тормышны. Миңлекәй кешедән түгел, үзеннән-үзе көләргә ярата. «Мин туып килүче пролетариат. Шуңа бернәрсәм дә юк минем. И бернәрсә дә кирәк тә түгел! Кырыемда Бәдриҗамалым булсын да балаларны саулыктан аермасын. Киттем бардым шәһәргә, бер күрешеп сөйләшергә зар-интизар булып торырсыз әле!» — ди.

Әле бүген Бәдриҗамал да, Миңлекәй дә ни күрәчәкләрен белмиләр. Үз бәхетләренә нык ышанганнар, шуңа күрә кеше фалын тыңлыйлар.

Сәмигулла утырырга кушып киткәннән соң, Хөснүрия урыныннан торды да, «Тәвәккәлләсәм ничек булыр микән» дигән шикелле, тылсым күрергә килгән авылдашларыннан күз карашы белән теләктәшлек көтте.

— Җә инде, ялындырма инде, утыр дигәндә инде...— диештеләр хатыннар.— Безнең өчен шултикле җирдән килгән кешене тилмертмә. Монда син генә түгел, әйдә, әйдә...

Шундый уңайсыз булып китте Хөснүриягә. Эш анда гына торса, ул риза. Шултикле халыкны көттерәме соң, бер минут та көттермәячәк.

Хөснүриянең өстендә кара якалы билен кысып торган күз явын алырлык ачык зәңгәр төстәге кышкы пәлтә. Үз гомерендә беренче мәртәбә киде ул аны бүген. Ташкенттагы апасы җибәргән иде. Тол да калгач, бердәнбер баласы да үлгәч, Ташкенттагы апасы игътибарлырак була башлады Хөснүриягә. Сырып, юрганнар да җибәргәләде. Бик мамыклы як икән ул Ташкент ягы. Мондый пәлтәне бәрәңге сатып кына ала алмас иде Хөснүрия. Аннан соң пәлтә киеп кая барсын. Әле монысы да күпме ятты инде сандык эчендә. Матур пәлтә, әйтә торган да

түгел. Мондый кием укытучыларда да юк әле. Башында кәҗә мамыгыннан бәйләгән күпереп торган мамык шәл. Мамыклы кәҗәсе бар Хөснүриянең, шәлне дә үзе бәйли. Шәл астында май сөртеп таралган чем-кара чәчләр. Дулкынлануданмы, өйдәге эсселектәнме, битләре кызарып чыккан. Бөтен нәселенә бер кыяфәттә яратылган, кәкрәебрәк торуга карамастан, бөтен битенә сыйпап куелгандай җәенке борын. Килешеп тора үзенә. Шул борын өстен ялтыратып берничә тир бөртеге дә бәреп чыккан.

Хөснүриянең болай күз камаштырырлык итеп киенүенә фалчылар гына сәбәпче түгел. Юк! Мондагы сәбәпләрне әйтә китсәң! Кырыкка да җитмәгән, бөтен күзәнәкләреннән бу тикле көчне, бу тикле назны кемнең иңнәренә, йөрәк ялкынын кемнең йөрәгенә түгеп арыныйм микән, дип иңгерәеп йөргән чаклары Хөснүриянең. Нигәдер соңгы айларда йөрәге акылына юл куймый башлады. Ирләр назына мохтаҗ күңеленең моңы күзләренә бәреп чыкты. Башының иләс-миләс килгән көннәре иде. Күңел бит ул каһәр! Өмет белән күпме яшәтергә була аны. Кыш уртасы дип тә тормый икән, йөрәктә кан кайный, ашкына күңел! Шуның өчен дә җанына урын таба алмый йөдәде Хөснүрия. Нәкъ менә шушы көннәрдә Югары оч Миңнисаның кече кызы кайтып төште авылга. Үзе генә кайтмаган, Сабан туена чаклы озак, дип, яңа кияүен күрсәтергә алып кайткан икән. Бәлки, Сабантуйларына кадәр кем бар да, кем юк дип, әнисенең күңелен тынычландырырга кайтты микән. Ул турыда сөйләшүче булмады, тик менә яңа кияүнең уңганлыгы, осталыгы, нәрсә кирәк шуны төзәтә белүе хакындагы хәбәр бик тиз таралды авылга. Нинди генә осталар килсә дә, сәгать төзәтүчеләрнең килгәне юк иде әле моңарчы. Хөснүриянең, үзе әйтмешли, хан заманнарыннан калган җиз герле, җиз телле, бик матур итеп суга торган сәгате ничә ел инде моңаеп эленеп тора иде стенада. Шуны гына карап китмәсме икән, дип чакырган иде яңа кияүне Хөснүрия. Әнә шул сәгатьтән башланды инде барысы да. Кем уйлаган ул кияүнең шундый матур, шундый ыспай, шундый тәвәккәл буласын. Көтебрәк торса да, өенә ир кеше килеп кергәч, Хөснүрия югалды да калды. Кая барып бәрелергә белми, әле кунакка урын күрсәтте, әле самавырына барып тотынды. Шул кызулык белән сәгатьне дә алып бирмәкче иде Хөснүрия, тукта әле, кая ашыгам, ишектән кермәс борын кешегә эш тоттыраламмыни, дип, өенең уртасында басты да калды. Калтыранган куллары белән яулыгын рәтләде, алъяпкычын сыпырып куйды. Ә тегесе ник бер сүз әйтсен, әллә исәнләшмәде дә инде. Хөснүриянең каушавыннан кызык табып, шундый серле итеп, мин синең уйларыңны беләм бит дигән сымаграк көлемсерәп, пәлтә сәдәфләрен чишеп җибәрде. Күтәрелеп карарга бик оялса да, күзләре очрашмыйча кала алмады. Карамыйча түзә алмады Хөснүрия. Әнә шул өтеп алган караштан

әллә нишләде дә китте башы. Йөрәге дерт итеп урыныннан купты, бөтен тәне буйлап җылы бер дулкын йөгереп үтте. Шулай да аны-моны сиздертмәскә тырышып, ул җәһәт кенә урындык куйды да стенадагы сәгатькә үрелде. Әллә ашыгудан, әллә башка сәбәптән, кинәт кенә күз аллары караңгыланып, башы әйләнеп китте Хөснүриянең. Янына басып, сәгатьне алырга дип ике кулын сузып торган «кияү»нең кочагына ничек килеп төшкәнен сизми дә калды шул...

...Башкасын рәтләп хәтерләмәде дә Хөснүрия. Әллә өндә булды, әллә төштә. Бигрәк назлы өермә булып чыкты бу сәгать төзәтүче. Алар сәгатьне дә, вакытны да оныттылар. Ишегалдыннан ишетелгән савылмаган сыерының шелтәле мөгрәве генә айнытты аны бу халәттән.

«Нәрсә булды соң әле бу? Нишләтте мине бу кеше? Йомшаклыкның чигенә чыкканмын икән... Җебегән! Беренче килеп кагылган ир каршысында шулай мәлҗерәп төш инде... Уф, үләм! Тагы нәрсәләр төзәттерәсем бар икән!» — дип уйлады Хөснүрия.

Стенадагы сәгать, келт-келт итеп йөреп, өйгә җан кертте. Тавышлары җыр кебек. Кай арада төзәтте соң ул аны. Тик «кияү» генә чыгып киткән иде. «Әй Ходаем, тагы кемнәрнең сәгатьләрен төзәтеп йөри икән?» дигән көнләшүгә охшаш бернәрсә чеметеп үтте Хөснүриянең йөрәген. Ул идәнгә ишелеп төшкән «Ташкент юрганнарын», мендәрләрен сәкегә күтәреп өйде дә инде ничә айлар кулы кагылмаган сандыгын ачты. Буйлап салынган көе иң өстә яткан, әле бер тапкыр да киеп салынмаган кара якалы зәңгәр пәлтәсен кулына алды. Пәлтәсен кочаклаган көе, сәкедәге мендәрләргә, стенадагы сәгатькә карап алды да йөзе белән капланып елап җибәрде. «Нәрсә бу, бәхетме бу, әллә бәхетсезлекме бу? Барам әле фалчыга».

Әнә шул сәгать төзәттергән көннең киче иде ул. Нафталин исләрен аңкытып, Хөснүрия фалчы каршысындагы бүкәнгә килеп утырды.

— Исемең? — диде фалчы.

— Шафикова Хөснүрия.

— Исемеңне генә әйт, фамилиясе нәрсәгә,— диделәр төрле яклап.

— Хөснүрия инде, Хөснүрия.

Фалчы озын бармаклары белән калын китабының битләрен актарырга кереште. Бер бит, ике бит, өч бит... Дәшми фалчы. Бары елмая гына. Хөснүрия әле фалчының йөзенә, әле китап битләренә карады. Их, язуын таныса! Менә бит, монда гына бит, якында гына язмыш хәбәре...

— Китабың минем турыда бернәрсә дә сөйләмимени, ник әйтмисең,— диде түземлеге беткән Хөснүрия.

— Башыңда фикерләрең чуалган чагы, ахры,— диде фалчы, тагы бер битне ачып. — Тормышың турында уйла...

— Әнекәем! Минем тормышым турында мин уйламый кем уйласын! Бер башыма мең исәп. Әйт инде бер генә сүз!

— Ялгыз яшисең икән.

— Яшим шул, ялгыз шул... аны белү өчен генә фал ачтыру кирәк булдымы икән...

— Бар әле, өеңә кайт,— диде фалчы аптырап.— Озак итеп уйла да яңадан килерсең. Акчаңны кире ал... Бәлки, яңадан киләсең дә килмәс... Бар, бар, туры өеңә кайт...

Хөснүрия коелып төште, фалчының акча сузган кулына борылып та карамады. Башын түбән игән килеш урыныннан торды да, беркемгә дә күтәрелеп карамый, өйдән чыгып китте. Ишегалдында торучы яшьләр, алардан да бигрәк юк-бардан кызык табып ихахайлап көлгән Миңлекәй яныннан йөгереп диярлек узды. Урамга чыккач кына «Уф, Алла!» дип авыр сулап куйды да әкрен генә өенә таба атлады. Капка янына килеп җиткәч, башын күтәреп караса...ни күзләре белән күрсен! Каршысында сәгать төзәтүче «кияү» басып тора иде. «Үләм! Бу кешенең безнең капка төбендә торганлыгын фалчы кайдан белде икән?» дип, Хөснүриянең исләре китте.

Нишләп белмәсен, фалчы бит ул шуңа күрә дә. Әле ул аңар бик күп нәрсәләр турында әйткән булыр иде. Әйтә генә алмады. Чөнки Хөснүриянең башындагы фикерләре чуалып, зиһене таралган чак иде шул. Фалчы түгел, Хөснүрия үзе дә очына чыга алмады ул фикерләрнең. Авылдашлары алдында барысын да ачып салырга әллә кызгандымы ул Хөснүрияне? Әгәр дә кызганмаган булса, ул аңар «Озак тормас, ул синең сәгать төзәтүчең китәр, ләкин сине бәхетле итеп китәр» дип әйтер иде. Чөнки Хөснүрия бу вакыйгадан соң бер матур гына малай алып кайтты. Әллә бәхет булды, әллә бәхетсезлек. Бәхеттер, мөгаен. Авыл халкы: «Харап кына итте бу сугыш ир-егетләребезне! Шундый гына бәхеткә өмет белән яшимени хатын-кыз! Ялгыз булса да, олыгайган чакта таянырга кешесе булды, бәхетле ул Хөснүрия», — диделәр. Хөснүриягә каты бәрелүче булмады.

Хөснүрия чыгып киткәч, җыелышкан халык шым булды. Фал ачтырырга дип бик ниятләнеп килгәннәрнең күңелендә шик сымак бернәрсә үтеп китте. «Булдыра алмый, ахры... Хөснүриягә дә әйтеп бирә алмагач инде... Аңар фал ачар өчен зур күрәзәлек кирәк микәнни...» Шулай дип уйласалар да, фалчыны тыңларга дип бик ныклап җыенып килгәнгә күрә, кузгалучы булмады.

Шул вакыт, өй эчендәге тынлыкны бозып, киерелеп ишек ачылды, авызы колагына җиткән Миңлекәй килеп керде.

— Әллә барысына да борыч кыстырып чыгаралар инде? Хөснүриягә бәхетнең ат башы чаклысын тоттырдыгызмы әллә? Чак

бәреп екмады. Әй, монда мин генә юк икән.Тыңлыйм әле азрак, акыл кермәсме.

— Син генә җитмәгән идең шул,— диде Бәдриҗамал, назлы тавыш белән.— Мин эш белән утырам, өйгә кайтыр идең...

— Бергә кайтырбыз, карчык, култыклашып,— диде Миңлекәй.— Кая, кем чираты, бер тыңлатыгыз инде. Әйдә әле, Шәрифелтти, кунычыңны капшап утырма. Син олы кеше, көттермә кешеләрне, яшьләргә төн дә җитәрлек.

— Юк, юк, мин бернәрсә дә белмим,— диде Шәрифелтти.

— Синнән сорамыйлар, ул үзе әйтә, әнә утыр шул бүкәнгә.

— Юк, юк, әнә Хәбибҗамалдан сорасын, ул зиһенле, ул ир белән торган кеше.

— Фалчы бит бу! Кая килгәнеңне оныттыңмы әллә? Авыл сәвите түгел монда. Бар инде, ялындырма,— диде Миңлекәй, хатыннарга күз кысып.— Нәрсә ишетергә килгән идең соң?

— Нәрсә ишетергә дип инде... дип, мүкәләп урыныннан торды Шәрифелтти.— Ат булып җигелдем, сыер булып савылдым, көпчәк булып тәгәрәдем, дөнья кудым. Дөнья мине тотты, мин дөньяны тота алмадым. Оҗмахлы буласың дисә, башка бернәрсә дә кирәк түгел.

— Оҗмах төбе саклаучы фәрештә дип белдеңме әллә син аны?! Бәлки, хур егетләре турында да сорарга килгәнсеңдер?

— Әстәгафируллаһ!

— Өчлегең бармы?

— Нәрсә дисең?

— Өчлексез туган анасына да ачмыйм, дип әйтә ди.

— Әстәгафируллаһ! Хәзер, хәзер, кая соң үзе...

Шәрифелтти ашыга-ашыга оек кунычын капшарга кereште.

— Күршедән кереп җиткәнче нигә шулкадәр еракка яшердең акчаңны?

— Еракка яшерсәң, якыннан алырсың. Кунычтагы кулда, куендагы юлда... Өчлекме бу?..

— Шул инде, шул, кулына тоттыр.

— Ничек дисең?

Акчага кагылышлы сүз булганда, Шәрифелттине дөм саңгырауга әйләнә дигәннәр иде, дөрес икән.

Ниһаять, кунычта ятып, тасланып беткән өчлек, Шәрифелттинең калтыранган кулларыннан фалчының уч төбенә күчте.

— Бисмилләһир рахмәнир рәхим...

— Исемең ничек?

— Исемне әйтегез әле, оялам,— диде Шәрифелтти, шәл очы белән авызын каплап.

— Бар икән мулла кызы,— диде Миңлекәй шаркылдап.— Шәрифел аның исеме, Шәрифел...

Белмим, нәрсәләр сөйләгәндер фалчы Шәрифелттигә. Аны-

сын мин ишетмәдем, йоклаган идем инде. Ләкин Шәрифелтти турында мин фалчыга караганда да күбрәк беләм. Чөнки безнең күршедә генә яши ул. Мин белә башлаганнан бирле, безнең өебезгә генә орынып, юан кәүсәле шомырт агачы үсә. Шәрифелттиләр шомырты. Безнең киртәнең теге ягындагы бәрәңге бакчасы да аларныкы. Ә заманында шул шомырт агачы кырыенда калай түбәле, әйбәт каралты-куралы бай гына йорт та булган. «Шәех алашасы» дип йөртелә торган авылга бер дан атлары да булган аларның... Бу гаилә турында гыйбрәтле бер вакыйганы онытмый авыл халкы.

Күптән булган бу хәл. Матур, җылы язгы көннәрнең берсендә, әле ул вакытта ябь-яшь сыгылмалы шомырт агачы ап-ак чәчәктә утырган вакытта, бер хәерче керә Шәрифелттиләргә. Аның да яшь, килен чагы. Шәрифелтти мичтән ипи чыгарып йөри икән. Ярты өйне алып, идәнгә орлык бәрәңгесе өелгән, кояшта күзәнәкләрен тутырып ята. Ишек тавышына Шәрифелтти башын күтәреп караса, ишек төбендә бер ир кеше басып тора икән. Ян-ягына капчык аскан.Тез башына кадәр төшеп торган күлмәге киндер билбау белән бәйләнгән, аягында чабата. Бер дә мөселман кешесенә охшамаган була бу хәерче. Шәрифелтти сәке өстенә тезгән ипиләренең өстенә тастымал ташлый да, юклы-барлы русчасы белән кулын селтәп:

— Нету, нету, бар-бар, юлыңны кара,— дип, халыкта гомердә булмаганча, хәерчене буш кул белән куып чыгарган.

Артыннан карап калыйм әле дип, ишегалдына чыга торган тәрәзәгә килсә... ни күрсен! Теге хәерче утын яра торган тумран өстенә утырган да кул аркасы белән бәддога укып утыра, имеш. «Әй Ходаем! Хараплар гына булдым! Хозыр Ильяс булган икән бит!» — дип, Шәрифелтти ипи кисә башлый. Башка берәү булса бөтенен тотып йөгерер иде. Ә инде ул ипи кискән арада, Хозыр Ильяс юкка да чыга.

Бәддога озак көттерми. Шул ук төнне боларның бөтен тирә-якка дан булган атларын, тоякларына чабата кидертеп, урлап чыгалар. Хәерчеләр, Хозыр Ильяслар, ат караклары күп булган заманда булган бу. Ул вакыт аерым хуҗалыклар вакыты, һәркемнең аты үз кулында. Атлары урланып, ике-өч көн ах-вах иткәнче, бик яман ут чыгып, бернәрсәләрен дә коткара алмыйча, үзләре эчке күлмәк-ыштан белән генә калып, яналар болар. Үзләренә дә, аркаларына капчык асып, кешегә өйдәш булып керергә туры килә. Нигезләрендә шау чәчәк аткан шомырт агачы гына кала. Аннан авыр еллар башлана. Өй салырга акчаны берничек тә юнәтә алмыйлар. Кызы кияүгә чыгып, малай табып, әйбәт кенә яши башладык дигәндә, сугыш башланып китә. Шәрифелттинең кияве сугышта ятып кала. Карты да гүр иясе була. Болар өч кисәк, аналы-кызлы һәм кызының улы белән тормышның ачысын да, төчесен дә татыйлар. Башка

урамдагы кешенең мунчасын өй итеп, оныгы үсеп кеше булганчы, шунда гомер уткәрәләр. Ләкин шомыртлы бакчаларын ташламыйлар. Әле болары мин туганчы булган хәлләр. Ә менә мин белә-белгәннән бирле, шул бакчаларына бәрәңге утырттылар, ә Шәрифелтти шомырт агачын саклады. Һәр яз саен шомырт чәчәк атуга, күрше урамда яшәгән Шәрифелтти, таякка таянып, чайкала-чайкала килә торган иде дә шомырт төбенә утыра торган иде. Шомырт агачына бала-чаганы якын да җибәрмәде. Чәчәген генә түгел, яфрагын да өздертми иде. Ә инде шомырт өлгерә башлагач, әйткән дә юк. Нәрсәгә дип саклады микән ул шомыртны, дисәм дә, хәзер инде, нишләп сакламасын әле ул аны, дип куям. Яшь чагының, матур тормышының бердәнбер истәлеге булган бит аңар шомырт. Бәлки, ул, аның төбендә утырган чакта, фани дөньяны гына түгел, ахирәтне дә уйлагандыр. Бала-чагалардан шул шомыртны саклауны саваплы эшкә санагандыр. Торган өенең шушы шомырттан ерак булганы өчен, үз-үзен ачуланып, үз кайгысына үзе күмелеп утыргандыр. Кем белә бит. Шомырт аның бердәнбер куанычы, иң соңгы байлыгы булгандыр. Курка идек без Шәрифелттидән. Ул югында шомыртка үрмәләсәк тә, аны күрүгә, кычытканнарга чагыла-чагыла, бәрәңге бакчасы буйлап, бәладән ераккарак йөгерә торган идек.

Белмим, фалчы нәрсә әйткәндер Шәрифелттигә. «Оҗмахлы буласың, дисә, бернәрсә дә кирәкми»,— дигән иде. Урыны оҗмахта булсын. Шәрифелтти дөньяда юк инде.

Оныгы үсеп җитеп тернәкләнгәч, яңадан китереп, безнең кырыебызга йорт салды ул. Тик өй саласы булгач, шомырт агачына урын калмады. Төбеннән кыркып, кисеп аттылар шомырт агачын. Ярый иртә язда кистеләр. Яфраклары юк иде. Әгәр дә шаулаган җәй булса, аның гөрселдәп авып төшүләре йөрәкләрне әрнетер иде. Ярый әле иртә язда кистеләр. Шәрә шомырт авып төште. Шәрифелттинең оныгы, чаж-чож иттереп, утынга турап өйде аны. Бик кызганыч булды шул чакта. Шомырт аларныкы булса да, безнең өйгә терәлеп үсте, ел саен безнең өйгә терәлеп чәчәк атты бит ул.

Турыбызны бизәп торган икән шул шомырт. Тик яңа салынган, усал тәрәзәле яңа йорт матурлык өстәмәде урамыбызга... Шулай да барыбер тату яшибез күршеләребез белән. Күршеләр Ходайдан, диләр бит. Без әйбәт булмасак, ничә еллар башка урамда яшәргә мәҗбүр булганнан соң да, яңадан безнең янга килеп оя кормаслар иде. Оныгы да әбисе төсе итеп бер шомырт утыртыр әле, утыртмый калмас...

Лампада керосин бетеп, ялкыны сикерә башлагач кына таралганнар фалчыга килүчеләр.

Бүген мәктәптә мин дә фалчы булдым. Тәнәфес вакытында класс журналын алып, барысына да фал ачтым. Шуның

аркасында әләкте дә соң үземә. Башта фал ачу бик шома барган иде. Берсенә укытучы буласың, дидем, икенчесенә читкә китәсең, дидем. Сөендердем барысын да. Тик менә Рәфкатнең журналдагы икелеләрен күреп, күземне классның сөремләнеп беткән түшәменә терәп, фалчының тавышына охшатырга тырышып:

— Быел кучми каласың икән... Икелеләрең җибәрми сине бишенче класска... Эчке тәртип кагыйдәләрен бер дә белмисең икән...— дип кенә башлаган идем, ул:

— Менә сиңа эчке тәртип, менә сиңа тышкы тәртип! — дип салып җибәрде.

Авыртса да, тамчы да еламадым. Мин дә җавапсыз калмадым, журнал белән бәрдем башына. Икеле капчыгы! Әйтерсең аның икелегә укыганлыгына мин гаепле. Яратмыйлар фалчыларны. Үзләре белергә телиләр, дөресен әйтсәң, үпкәлиләр. Җитмәсә, укытучы апа да безнең сугышканны күреп алды да, икебезне дә янәшә куеп, «эчке тәртип кагыйдәләре» язып эленгән такта янына бастырды. Дәрес буе басып тордык шул.

Шулай да рәхәт миңа бүген. Фалчылар әле бүген дә бездә. Бала карау да кулдан китте. Фалчы хатыны көне буе бала тирбәтә. Тау шуарга чанам да бар...

Мәктәптән кайтканда, фалчы хатыны белән әни өстәл артында сөйләшеп утыралар иде. Эченә җылы керү белән бергә, күңеле дә йомшаган иде, ахры, бу апаның. Кичә, авызын ачып, бер генә сүз дә әйтмәгән иде.

Мин дәресләремә утырган булдым, колакларым аларда.

— Үзең әйтмисең, китеп барсагыз исемеңне дә белми калырбыз инде,— диде әни.

— Исемемме... Ноябрина исемле мин...

— Ничек дидең?

— Ноябрина. Кызык бит, әйеме?

— Кызык дип инде, — диде әни.— Исем булгач, яраткан да ябышкан инде. Исем дигәннән, минем үземә исемем бер дә ошамый иде яшь чакта. Мәүҗидә! Шул да булдымы исем. Бервакыт шулай бер хатын белән таныштым базар юлында. Исемемне сорагач, «Гүзәл» дигән булдым. Исемегез бигрәк матур икән, ди теге хатын. Ә минем исемем Мәүҗидә, ди. Аптырап калдым.И-и, адашлар икәнбез, дидем дә әйтеп бирдем инде Мәүҗидә икәнлегемне. Әнә шул хатын акылга утыртты үземне. Исемем ямьсез булганга күрә генә «Гүзәл» дип әйткән идем дигәч: «И Мәүҗидә җаным, безнең исем Коръәнгә язылган бит ул, нишләп ямьсез булсын!» — диде.

— Ә минем исемне әни кушкан. Җиденче ноябрь көнне туганмын мин. Әни партия эшендә эшләгән ул вакытта. Әби үлгәнче әйтте: «Исемеңне генә күтәрә алмадың, шуңа күрә чирләшкә булдың»,— диде. Минем чирләү исемнән генә түгел

инде, тумыштан. Күзеңдә миң бар, дип, әби Миңленоябрина дип йөрсә дә, файдасы тимәде. Чәчемне күрсәтим әле мин сиңа.

Ул безгә кергәннән бирле салмаган яулыгын чишеп җибәрде дә курчак чәче кебек ике ап-ак толымын түшенә салындырды.

— Нәрсәдән агарды бу чәчләрең? — диде әни шаккатып. — Шундый ак чәч буламыни яшь кешедә. Юләр кеше әйтмешли, әллә үз толымың түгелме?

— Үземнеке, Мәүҗидә апа. Тумыштан шундый. Альбинос чире, диләр аны. Минем тәндә кара төсне күрсәтә торган матдә юк икән. Күзләрем дә начар күрә минем шуның өчен. Ул, менә карагыз, дигән кебек, күзләрен зур ачып, кечкенә сәдәф кебек төссез күзләрен тутырып әнигә карады.

— Ак каргалар турында ишеткәнең бармы синең? Бәлки, күргәнең дә бардыр?

— Әллә инде...

— Әнә шул ак карга инде мин. Исемем белән дә, җисемем белән дә дигәндәй...

— Ә бу фалчыны каян таптың соң?

— Сукырлар клубында танышкан идек. Шулай кызлар белән симәнке чиртеп тора идек клуб каршында, килде дә, кызлар, сыйлагыз әле, дигән булды. Симәнке соравы бер сәбәп кенә булгандыр инде. Ноябрина, ди миңа, шушы адрес белән илтеп куй әле мине, ди. Кара әле, мин әйтәм, сезнең якта гел икенче икән. Сый да кызлардан, озату да кызлардан, дим. «Күрмим бит мин» дигән булды, мескенкәй. Ә мин һаман шаяртам: «Моңарчы озатучың кая китте соң?» дигән булам. Озата киттем инде. Гел елмаеп сөйләшә, йомшак тавышлы. Начар кеше түгелдер, дип уйладым. Миннән күпкә олы булса да, өйләнешик, дигәч, риза булдым да куйдым.

— Әти-әниең бармы соң синең? Алар турында бернәрсә дә сөйләмисең. Алар нәрсә диделәр?

Ноябрина беркавым дәшми торды да:

— Утыз җиденче елда икесе дә бер-бер артлы үлеп киткәннәр. Шулайдырмы инде... Сыеныр кешем картаеп беткән бер әбием иде. Авыр туфраклары җиңел булсын. Язмышны сынау иде инде бу. Язмышны сынамыйлар икән аны. Күпме сайласаң да, язмыштан узмыш юк, дигәннәре дөрес ул. Кайчагында үкенәм, кайчагында сөенәм моңар ияргәнгә. Әйбәт кеше ул. Аның да беркеме дә юк. Яраткан кешесе булган аның. Ә сукырайгач, беркемгә дә кирәге калмаган. Әби дә аны «сукыр» дип карады. «Сукырга таяк булганчы, күзлегә маяк бул» ди торган иде. Үзе сукыр булса да, күңел күзе бар аның. Сабыр кеше. Исеме дә Сабирҗан бит. Миннән башка ияртер кеше тапмас идемени?.. Менә күпме йөрим инде мин аның белән фал ачтырып, инде ничә ел бергә яшибез, бер генә тапкыр да

миңа фал ачканы юк анын. Әллә ташлап китәр дип курка инде. Нишләп ташлап китим инде мин аны. Беркем дә көчләп бирмәде бит, үзем теләп бардым.

— Анын сукырлыгы нәрсәдән соң? Синең кебек тумыштанмы, әллә чәчәктән калганмы?

— Юк, тумыштан да, чәчәктән дә түгел. Донбасс якларында шахтада эшләп йөргән ул. Шунда ниндидер бер фаҗигa булып, ташкүмер астында калган. Өч көннән соң гына казып чыгарганнар. Шунда сукырайган да. Әнә шул вакытта барлыкка килгән инде анда фал ачу сәләте. Яраткан кешесен дә шул вакытта югалткан булырга тиеш. Сабирҗан бу турыда сөйләргә яратмый.

— Торырга өегез бармы соң? Әллә гел шулай йөреп, кеше өстендәме?

— Почмагыбыз бар инде. Әзрәк акча эшләп булмас микән дип чыккан идек. Кая ул! Анын холкы белән. Күбесен бушка әйтеп йөри. Пенсиясе юк дисәң дә ярый. Тик бу юлы бер дә күңеле тартмый чыкты бу якларга. Очрашмаска ант иткән кешем бар иде, аралар якыная, дип сөйләнгән иде, урманда юл тапмый йөргәндә. Нишлисең бит, яшәргә кирәк. Эшли торган җирдә бик аз түлиләр.

— Нинди эштә эшләде соң ул, күрмәгәч, дим инде? — диде әни.

— Эш бетәмени. Сукырлар өчен дә эш бетми. Чыпта үрә идек. Ул юкә тузаны бөтен үпкәләрне тутырды. Анын үпкәсе болай да таза түгел, ничә ел шахта тузаны йоткан бит ул...

Урам капка келәсе тавышына тәрәзәдән карасам, күршебез Айсылутти кереп килә икән.

— Әйдә, әйдә,— диде әни, өй ишеген ачып.— Әле нишләп керми икән дип тора идем.

— Исәнлектә ятасызмы? — диде Айсылутти.— Әле, Мәүҗидә, кунакларың китмәгән икән. Үземә ала алмадым, шуңа эчем пошып кердем әле. Безгә чәй эчәргә булса да кереп чыксыннар, дигән идем. Шикәрем дә бар, әче камырдан көлчә дә пешергән идем.

— Белмим инде Айсылутти... Фалчы үзе ишегалдында... Минем ашым өлгерергә тора... Кара әле, нигә әле син фал ачтырмыйсың. Үзеңне булмаса, Санияне каратыр идең. Ул торфларда, юл эшләрендә күпме интегәсе бар икән анын.

— Әй Мәүҗидәкәем! Хаты килде әле Саниянең! Кичәдән бирле кулдан төшергәнем юк. Тагы бер укып бир әле.

— Карточкасы юкмы?

— Бу юлы җибәрмәгән. Укы әле, укы.

Әни хатны, кулына алып, шуны гына көткән сымак укып та җибәрде.

*«Сезки, безнең өчен кадерле булган әти белән әнигә, без-*

*ки, сезнең өчен дә кадерле булган кызыгыз Саниядән бик сагынып, бик күп сәлам...»*

Сания апа күрше-күләннәргә дә, туган-тумачаларга да, аны сораучыларга да, хатны укыганда тыңлап торучыларга да, тагы бик күпләргә дә күпдин-күп, чукдин-чук сәламнәр язган иде.

*«Сәлам соңында,* дип укуын дәвам итте әни, *минем хәлләргә килсәк, сезнең хәер-догада, Аллага шөкер. Үземә ялтыравыклы эрҗинкә итек алдым. Сезгә посылка салдым. Эшем авыр түгел, кайгырып ятмагыз...»*

— Эшем җиңел дигән булган... Җиңел буламы соң инде... Авызыннан өзеп пусилкалар салган була, балакаем... Әле ул җибәргән шикәрем дә бар... Мине жәлли инде,— диде Айсылутти, күз яшьләрен сөртеп.

— Әле җыр да язган икән,— диде әни, алга таба укып.

— Хат саен җыр язмый калмый,— диде Айсылутти.— Йә, укы инде, миңа карама... Мин кичәдән бирле елыйм...

*«Әнә килә автомобиль,*
*Төягәннәр торбалар.*
*Үзең монда, анаң кайда,*
*Дип кычкыра торналар...»*

Айсылутти ике куллап хатка чытырдап ябышты.

— И Мәүҗидә! Ник бәгырьләрне телгәли икән бу бала! — диде ул өзелеп.— Миңа бит ул торналар, «үзең монда, балаң кайда-а-а», дип кычкыра. Урман кисүгә йөреп интекте яшь башларыннан... Тагы юл эшенә дип алып киттеләр. Кара кул инде, Хәбри... Үземне төрмәдә череткән иде, хәзер бала интегә. Ул язып бирмәсә, монда эш бетмәс иде ...

— Бетермә үзеңне, Айсылутти,— диде әни, аны юатып.— Ул бит яшь кеше. Рәхәтен дә күрер әле. Бәхетен дә табар. Фал ачтырып кара әле. Үзеңә булмаса, Сания өчен ачтырып кара. Ачтырмасаң, тыңларга кер, ичмасам, күңелләрең ачылып китәр.

— Әй, сөйләмә син... Кеше фалын тыңларга дип, миннән башка да өең тулып килгәннәр, дип ишеттем. Исем сорап, фал ачучыларны күргәнем бар минем. Йөрәгемә ярамый. Әле һаман да колак төбемдә яңгырап тора... «Исемең, фамилияң... Йә, сөйләп җибәр әле, колхозның социалистик мөлкәтенә кулыңны сузарга ничек батырчылык иттең син?» Ул вакытларны искә төшерсәң... Сания үсмер бала. Мин төрмәдә чакта үлгән Шәфигуллам бишектә... Баланы басуга арбага салып алып барам, тартып алып кайтам. Шуның мендәре астына бер генә учлам башак уып салган идем. Ачлыктан бит... Кемдер шуны Хәбригә җиткергән. Эштән кайтуга, тентү белән керделәр. Эзләделәр, эзләделәр, тапмадылар. Инде, Аллага шөкер, Ходай сак-

лады, дип тора идем, аяк башына карап сөйләшә торган Хәбри идәндә бер бөртек арыш күреп алган. Бер бөртек бит ул, бер бөртек! Кайлардан ияреп кермәс! «Берсе булгач, моның иптәшләре дә булырга тиеш!» дип, яңа көч белән эзли башладылар. Бала мендәре астыннан яулыкка төрелгән теге бөртекләрне тартып чыгаргач, сыгылыплар төштем. Үземнең тагы авырлы чак. Ул бала төрмәдә туды да үлде. Хәтерлисеңдер инде. Ике ел утырып кайттым бит. Төрмәдә дә ачлык. «Ерак китә алмассың, бар, тамагыңны туйдырып кайт», — дип хәер сорашырга чыгарып җибәрәләр. Ерак барып буламы соң, аяклар шеш... Соңгы айларымны йөрим... Шулай хәер сорашып йөргәндә, бер өйнең капкасын кактым. Керсәм, хуҗа хатын ишегалдында, ат тизәге кушып, тавыкларга бәрәңге төеп утыра. Минем хәлне күрде дә, рәхмәт төшсен аңар, хәзер ипи алып чыгам, дип, өенә кереп китте. Нинди ипиле йорт булгандыр инде ул заманда, белмим. Ул өенә кереп киткәч, ялгаш кырыена чүгәләдем дә, тегенең тавыкларга дигән бәрәңгесен тизәкләрдән аерып ашарга тотындым. Онытылырлыкмыни ул. Ә син фал ачтыр, дисең. Мин күргәннәрне эт тә күрмәс. Фалчылар дигәч тә, әнә шул хәлләрне тагы бер тапкыр уемнан кичердем дә, ник кертмәдем микән боларны дип, төне буе йокламадым. Керсеннәр әле безгә, көлчә белән чәй эчертермен.

Бик каты чакырып, Айсылутти чыгып киткәч, әни күршеләрне мактарга тотынды:

— Бәхетең булса, әйбәт күршеләр бирә Ходай. Бәхетең булмаса, бер дә үпкәләрлеге юк. Кемгә үпкәлисең, үпкәләп кенә эш бетми бит, дөнья көтәргә кирәк. Мин, үземә калса, Аллага шөкер, уңдым күршеләрдән. Ничә еллар инде, ике як күршеләребез белән дә камь-мәмер, тату яшибез.Тик шунысын гына әйтергә кирәк, дөнья булгач, төрле хәлләр булгалый, кара мәчеләр дә юлны аркылы чыккалый... Тик олы сүз итеп, авыз тутырып, безнең күршеләр «ай-һай» дип әйтерлек түгел. Бер күршемә карап фикер итсәм, икенчесенә карап шөкер итәм. Бер күршеләрем өчен мин алар язмышы, икенче күршеләрем минем өчен Ходай язмышы. Аннан соң мин үзем дә бик талымлы, бик тәфсилле нәрсә түгел, аз белән дә күңелем баеклана минем. Шулай булгач, үзем дә әйбәттер инде, сүзе юк, тату яшибез. Бер күршемә кереп, үзем акыл өйрәнәм, икенче күршемә кереп, түкми-чәчми акылны үзем өйрәтәм. Кешенең бәхете эш белән түгел бит ул. Аркылы аяклы бул, җебегән бул, тик бәхет кошың баш өстеңдә булсын. Гөлсирә турында әйтелгән сүзләр алар. Бәхет кошы баш өстендә булмый, күршесендә мин бит аның. Үзе дә әйтә, ярый әле күршемдә син, син булмасаң, гомердә дә шушы Суык урамда гомер кичермәгән булыр идем, ди. Әтиләр нигезендә әйбәт иде безнең тормыш, ди. Әтиләр тормышында минеке дә әйбәт иде ул. Ә безнең урамга нәрсә

булган. Суык урам дигән булалар да, шул урамның файдасын ник берсе ачып салсын. Бакча артында гына урман, урман белән бакча арасында менә дигән басу. Нинди генә иген чәчмәсеннәр, бакча башында булгач, ничек тә йокмый булмый инде. Бәрәңге чәчсәләр, утау чүбе җыясың, арыш басуы итсәләр, камылын чабасың. Шул басуга бер-ике адым гына кирәрлек итеп, бакча башыңа бозавыңны арканлыйсың. Кайчагында әнә шул бозау аркасында тавышланып алган кебек булабыз Гөлсирә белән. Тавышлану түгел инде, Гөлсирә ирен җәлли. Чөнки Гөлсирәнең ире Касыйм, пләвәй булып эшли. Менә ишеттеңме инде, күршебездә шундый урындагы кешеләр безнең. Урындагы кеше, урамдагы кеше дигәндәй, монысы урында булса да, урыны ат өстендә, мендәре арты астында. «Касыймның бүсере сезнең уҗымга чыккан мал-туарны куып кына чыкты»,— ди Гөлсирә. Әле кереп чыккан иде баягынак, ишегалдында мал караганда, «Синең фалчылар минем Касыймның чире турында берәр нәрсә әйтмәсләрме» дип кергән. Әйтмәсләр, әйтмәсләр, бүлнискә алып бар, дип чыгардым әле. Шулай инде, чирләрсең дә. Бозауның муенына муенчак салсаң да, казларга муенчак салып булмый бит. Ул каз дигән нәрсә синең сүзгә колак саламыни, аларга бүксәләрен туйдыру гына булсын. Бәбкәләренә канат чыгуга, колхоз басуына чабалар шул. Авылның бер башында Касыйм, икенче очында арыш басуы. Казларның чайкала-чайкала басуга менеп барганнарын Касыйм күреп кенә ала да: «Кө-өш! Мур кыргырлары!» — дип, бер-ике чакрымнан күкле-яшелле тавышы белән кычкырып җибәрүе була, тәрәзә пыялалары зеңләп кала. Астындагы аты өркеп, Мунчала күперенә чаклы дулап алып китә үзен. Астындагы мендәре җан-фәрман чапкан шәйли төшеп кала да, урамнарда мамык бураны күтәреп, бөтен дөньяны каплый. Каһәр төшкән казлар, таныйлар бит аның тавышын! Шул минутта, барган юлларыннан кире борылып, мәтәлә-кадала кирегә йөгерәләр дә шыбырдап елгага коелалар. Нинди бүсер чыдасын аңар!

— Әнекәем! Айсылутти тагы кереп килә. Ноябрина, бар инде, Сабирҗан абыйны ал да кереп чыгыгыз, күңеле булыр күршемнең. Ә мин хәзер, Гөлсирә әйтмешли, токмач басып, токмач кисеп, токмач салып аш пешерермен,— диде әни һәм, Ноябринага авыз ачарга да бирмичә, кулына бишмәтен тоттырды.

Күрәзәчеләр килгән, дигән сүз таралгач, бөтен авылга бер хәбәр бит ул, һәр кеше үзенең тормышын, башыннан кичкәнен тагы бер мәртәбә күңеленнән үткәрде. Өмет дигән нәрсәнең гаҗәеп бер изге, ят кул кагылдырмый торган кадерле нәрсә икәнлеген тагы бер мәртәбә күңеленең кайсы төше беләндер сизенде авыл халкы.

Сәетгәрәй абый да өмет белән яши. Өметсез өмет белән, тамыры корыган өмет белән, тик нindидер бер чаткысы сүнмәгәнгә

генә калдырмый аны өмет. Әнә ул бүген дә баскычына чыгып утырган. Әйтерсең ялгызлыкны буш өенә бикләп калдырган да, үзе белән өмет чаткысын алып, көн дә уйлый торган уе белән узган гомеренә кире кайткан. Әгәр дә теге дөньяда, кыямәт көнендә очрашсак, Маһирәдән иң беренче: «Син кайсы көнне вафат булдың соң, мин бит синең хәлеңне белергә килгән идем», — дип сорар идем, дип уйлый ул. Бу дөньяда сорый алмаячак. Маһирә апа юк инде бу дөньяда. Ә бәлки, исәндер, өмет шулай уйландыра. Чөнки Сәетгәрәй абый хатынының чирләп ятканын да, җан биргәнен дә күрмәде. Кабереңең кайда икәнлеген дә белми.Үз гомерендә өч чакрым ераклыктагы күрше авылны да барып күрмәгән Маһирәнең сөякләре кайсы җир астында ята торгандыр. Белми аны Сәетгәрәй абый. Ходай насыйп итмәде шул. Бер кеше язмышына төшсә дә төшә икән шундый сынау!

...Сугышның дүртенче елы. Сәетгәрәй абыйның хатыны Маһирә, быел илле биш яшен тутырып, колхоз эше өчен «гудный»дан чыгарга тиеш иде. Көннәрдән бер көнне аны авыл советына чакыртып: «Минимумыңа алты хезмәт көнең тулмаганны беләсеңме?» — дип сорадылар.

— Нишләп тулмасын, бер генә көн дә эштән калганым юк бит, Хәбри балакаем! Закирәне сугышка озатканда да ярты гына көн чыкмый калган идем...

— Военный времендә,— диде Хәбри,— лудырларга юл куйган юк, пнимаетели! Син монда Закирәне китереп кыстырма!

Хәбринең кычкырмаган кешесе юк инде, бөтен сөйләшү шушы булгандыр дип, тынычланып кайтып киткән иде Маһирә. Моның белән генә бетмәгән, әле монысы башы гына булып чыкты. Икенче көнне пүнәтәйләр белән килеп, җилтерәтеп районга дип алып чыгып киттеләр. Сәетгәрәй абый, капканы үзе ачып, артларыннан кул болгап калды. Мәхлук! Ир бул да, авыз ачып бер сүз дә әйтә алма инде! Бәгыреннән күтәрелгән җан ачысы бугазына төер булып капланды. Алты хезмәт көне өчен, дидеме... Пүнәтәйләр белән кереп! Үзләре ялгышкандыр, башкача булмас... Тикшерсеннәр әле... Аннан соң Сәетгәрәй абый үз-үзен тынычландырырга тотынды. Анда да кешеләр утыра бит, дип уйлады ул. Азрак ачуланырлар да җибәрерләр. Шулай тынычланып җиткәч кенә китте Сәетгәрәй абый авыл советына. Шуның өстенә каршысына очраган почта кызы Закирәдән хат та биреп киткәч, күңелләре гел күтәрелде аның. Әнә шулай кулына хат тоткан көе килеп керде ул Кара кул Хәбри янына. Ләкин хат тотып килеп кергән Сәетгәрәй абыйга Хәбри авызын да ачтырмады.

— Аның эше судта,— диде Хәбри, гаҗәеп бер салкын канлылык белән.— Районга хәл итәчәк. Совет влачы лудырларга юл куймаячак!

— Закирәдән хат бар иде...— диде Сәетгәрәй абый. Башка яклаучысы булмаганга, яклаучысына ышыклангандай хатны сузды.

— Кызым сугышта дип иркәләнеп йөрисе түгел! — диде Хәбри, кара бармакчалы кулын селтәп.— Алар сугышта кан түгә, пнимаетели, ә болар, канса канис, җилкә симертә! Барыгызны да бер шалунга төяп озатасы нәрсәләр!

Нәрсә әйтсен Сәетгәрәй абый. Бер сүз дә әйтмәде. Мөлдерәгән күзләре белән кулындагы хатка карап алды да:

— Хатны ничек күрсәтергә соң Мәһирәгә? — дип сорады.

— Күрсәтәсең килсә табарсың, райунда, дим бит! — дип кычкырды Хәбри.

Башка сораулар бирергә коты алынган Сәетгәрәй абый, әкрен генә борылып, буш өенә кайтып китте.

Шушы сөйләшүдән соң, районга барырга карар кыла Сәетгәрәй абый. Уйлана-уйлана, бәлки, кайтып җитәр, дигән өмет белән ике көн әзерләнә ул юлга. Биштәренә бер кием чабата оек сала. Берничә бәрәңге, алабута күмәче пешереп ала. Җомга көнне, иртәнге намаздан соң, Ходайга тапшырып юлга чыга. Районда көнозын буталып йөргәннән соң гына, Мәһирәсен Казанга озатканнарын белә. Казанга! Шултикле җиргә! Алты хезмәт көне өчен!

Сәетгәрәй абыйның Казанда булмаганына инде күпме еллар... Бер кеше гомере үткән... Герман сугышыннан кайтканда, Казан аша кайтырга туры килгән иде. Шул ерак юлга тәвәккәлли Сәетгәрәй абый. Өен күршеләре ташламас әле. Закирәнең хаты да көч өсти аңар. Бу хат белән теләсә кайда кереп булачак, шулай булмый мөмкин түгел, фронтта бит аның кызы! Ил өчен сугышып, кан коеп йөри. Бер атна дигәндә барып җитә Сәетгәрәй абый Казанга. Ходайның рәхмәте, юлда да әйбәт кешеләр генә очрап тора. Шулай да бер кунарга кергән җирендә баш астына салып яткан биштәрен капшап карыйлар каравын. Төне буе йоклый алмый ул төнне Сәетгәрәй абый. Хәер, ул вакытта инде биштәрендә дә кызыгырлык әйбере булмый. Ике күмәч тә тишек чабата.

Йончыгып, ачыгып, хәлсезләнеп килеп керә ул Казанга. Төрмәне дә бик тиз таба. Төрмә ишеге төбендә аның ишеләр байтак була. Ул да шул кешеләр янына баса. Чираты җиткәч, мунча төннегe кадәр генә тәрәзәгә башын тыгып, Мәһирәсен сораша.

«Солтангәрәева Мәһирә» дип кайтарып сорый тәрәзә каршында утыручы. Аннан соң кәгазьләр актаргалап карый да: «Больницада ята ул, сезнең янга чыга алмый»,— дип куя. «Иртәгә терелер микән, җәмәгате мин аның. Закирәдән хат бар иде... Авылдан килдем мин, әйтегез әле үзенә, дип инәлә Сәетгәрәй абый. «Үлмәсә терелер, иртәгә кил!» — ди теге кеше. «Следующий!» — дип кычкыра ул, сүз беткәнлекне аңлатып.

Сәетгәрәй абый кая барсын. Соңгы кисәк алабута күмәчен ашый да шул төрмә капкасы төбендә төн чыга. Икенче көнне

тагы шул тәрәзәгә йөзен тери. «Мәһирә Солтангәрәеваны күрергә мөмкинме?» — ди ул, хәлсез тавыш белән. «Кычкырып әйт, кем дисең?» «Солтангәрәева Мәһирә, җәмәгатем ул минем...»

Тәрәзә артындагы кеше тагы кәгазьләр актарырга керешә. Беркавымнан соң башын да күтәрми: «Юк ул бездә, юк!» — дип җавап бирә. «Бүлнистә дигән идең бит кичә, бүген хәле ничек икән?» — дип сорый Сәетгәрәй абый. «Үлде, бабай, карчыгың, үлде, терелә алмады...» — ди тәрәзә артындагы хәрби киемле. Сәетгәрәй абыйның күз аллары караңгыланып, башы әйләнеп китә. «Ялгыш карыйсыңдыр, ул арада кеше үләмени... Әйбәтләп кара әле... Фронтта безнең кызыбыз, хаты бар... хаты»,— ди ул, тәрәзәдән өчпочмаклы хатны күрсәтеп. «Фронтта» дигән сүздән соң, хәрбинең йөзенә җылылык иңгән кебек күренсә дә, кырыслыгы кимеми. «Үлде, бабай, карчыгың үлде, — ди ул ышандырырлык итеп.— Менә бирегә,— ул алдындагы кәгазь битен күтәреп күрсәтә,— шулай дип язылган...»

Сәетгәрәй абый тәрәзә яныннан китә дә, төрмә стенасына ябышып бераз атлаганнан соң, аркасын терәп, җиргә чүмәли. Ничек инде... Ясинсыз-нисез... Хәле авыр булган икән... Тукта әле, кайчан күмәләр икән соң. Ходай шулай язган икән, нәрсә эшләмәк кирәк... Тукта әле, нигә сорамады соң... Сәетгәрәй абый, көч — хәл белән урынынан торып, яңадан чиратка баса. Теге кеше шунда ук таный картны. «Бабай, әйттек бит инде, үлде карчыгың!» — ди ул, нигә юк белән борчыйсың дигән кыяфәттә. «Үлүе дөрес инде, алайса,— ди Сәетгәрәй абый үзалдына.— Күмешергә мине дә алыгыз әле»,— ди ул, ялварулы тавышы белән. «Рөхсәт ителми, аңлыйсыңмы, рөхсәт ителми...» — дигән сүзләр колагында яңгырый аның. «Ә Закирәгә нәрсә дип әйтермен? — ди ул, кулындагы хатын күрсәтеп.— Истәлеккә бирәр нәрсәсе калмадымы? Күлмәген, яулыгын бирегез, ичмасам». «Үзе белән алып китте, күлмәген дә, яулыгын да... Тиле карт, кит әле тәрәзәдән. Анда чират җыелган. Синең хатының гына дип белдеңме әллә монда!» — дип кычкыра төрмә кешесе.

Үкереп елар иде, кеше күп. Аунап, җир тырмап кычкырыр иде, халык карый. Ә кызына нәрсә дип җавап бирер ул. «Әниеңне саклый алмадым», диярме... Их замана...

Хәер сораша-сораша, ун көн дигәндә кайтып җитә Сәетгәрәй абый. Сугыш тикле сугыштан Закирәсе дә исән-имин кайта. Тик әнисе генә булмый ул кайтуга.

Әнә шул уйлары белән утырды Сәетгәрәй абый баскычында. Бармаска булды күрәзәчегә. Хатынының каберен генә сорамакчы иде, бармады. «Очрашырга күп калмады инде, дип уйлады ул. Түзәрмен. Күпкә түзгәнне, монысына гына түзәрмен».

Сирәк эләгә торган бәхет — чана шуып рәхәтләндем бүген. Бишек янында Ноябрина апа бәйләп куйгандай утыра.

Кич булып килгәндә генә, киез итекләр бозланып катып, суык тырнакларга киткәч кенә кайттым өйгә. Никадәр өшегәнемне өйгә кергәч кенә белдем. Туңдым дип, урамнан елап кергәнне әнинең җене сөйми. «Мин куштыммы!» дияр. Җитмәсә, өйдә кешеләр бар. Үзеннән-үзе коелган күз яшьләремне тыярга тырышып, шакыраеп каткан киез итекләремне кочаклап, мышкылдый-мышкылдый мич башына менеп киттем. Газапларымны күрмәсеннәр, ичмасам. Минем болай туңып кайту беренче тапкыр гына түгел инде. Андый чакларда әни туңган кулларымны карлы итекләрем өстенә куйдыртып тора торган иде. Шуңа күрә дә карлары эрегәнче дип, үзем белән мич башына алдым да инде мин аны. Туңу җелегемә төшкән, ахры, итекләрнең дә файдасы тимәде. Мин аларны аралыкка атып бәрдем, инде үкереп еларга тотындым. Күшеккән кулларым орынмаслык булып авырта башлады.

— Иркәм, ни булды? — дигән тавышка борылып карасам, янымда гына, кулларын сузып, Ноябрина апа басып тора. Мин дәшмәдем, инде тавышсыз гына мышкылдавымны дәвам иттем.

— Иркәм, берәр җирең авырта мәллә? — диде ул, ягымлы тавыш белән.

Аның миңа «иркәм» дип эндәшүенә шунда ук игътибар иттем. Безнең авылда алай сөйләшмиләр.

— Туңдым-м...— дидем мин яшь аралаш.

— Хәзер җылынасың,— диде Ноябрина апа.— Мин аның серен беләм. Сал әле яулыгыңны.

Ул яулыгымны салдырды да, минем кызышып янган кулларымны үзенең салкынча куллары белән тотып, чәчләрем арасына күмде.

— Кыймылда, кыймылда,— диде ул.— Кашы башыңны. Беләсеңме чәчтә җылылык күпме. Кыймылдат бармакларыңны, кыймылдат... Җылынамы... Әйттем бит... Тырнагыңа киткән салкын...

Ул минем кулларымны ике учына алды да битләренә куйды. Аның бите салкынча, ә минем кулларым ут кебек яна.

— Җылынганнар бит, иркәм,— диде Ноябрина апа.

Кулларым җылы булса да, әрнүе басылмады. Күпме утырырга була инде мич башында. Мин әкрен генә төштем дә, букчамны эзләп алып, тәрәзә төбенә дәрес әзерләргә утырдым. Өстәл өстенә фалчы абыйның китаплары тезелеп куелган булганга, өстәл ягына барырга кыймадым. Фалчы абый белән әти ишегалдына чыгып киткәннәр, ахры...

Ноябрина апа балалар белән кайнашты. Бишектәге энем белән дә нидер сөйләште. Аннан, кулына алып, аны мактыймактый сикертергә тотынды. Без барыбыз да ияләнеп беттек инде аңа. Бәләкәйләр дә үз итеп, бер дә ятсынмыйлар, уйныйлар, чөкердәшәләр.

Мин дәрес әзерлим. Тик кулларым гына тыңламый үземне.

Җитмәсә, шул вакыт кулларымның да сызлавын оныттырырлык итеп башым авыртырга тотынды. Әни әйтмешли, бер рәхәтнең бер михнәте шушы була торгандыр инде. Чамасыз чана шууның рәхәте шулай китереп бәрде. Китаптагы хәрефләр сикерешә башлады, күз алларым әлҗе-мөлҗе килде. Тик дәресләрне хәзерләми ярамый. Икеле алсам, фалчыларга сылтарлар тагы. Мин чана шуугa алар гаепле түгел бит.

Беркавымнан соң ишегалдыннан фалчы абый, кереп, үз урынына утырды. Өйгә кешеләр җыелыша башлады. Язмышларын белергә теләп тә, кичә өлгерә алмаганнар күп икән әле.

Барысыннан да алдан килгән Фаягөл белән Бәдриҗамал кичәге урыннарына урнаштылар да берсе шәл бәйләргә, икенчесе кичәдән бирле кунычын да бәйләп бетерә алмаган оекбашына тотынды.

— И Фаягөл! Ничекләр җитешәсең син барысына да,— диде Бәдриҗамал, Фаягөлнең бәйләгән саен күпереп барган мамык шәлен сыйпап.— Кара әле минекен, кичә башлаган оекбаш, кунычын бәйләгән көе, бүген бер күзәнәк тә алганым юк. Әллә нишләдем әле бу арада, кичтән кичлегем юк, иртә белән тора алмыйм.

— Әй, җитешмәгән ягы җитешмәгән көе тора инде аның Бәдриҗамал,— диде Фаягөл.— Әле бу шәл бәйләүләр белән бер эш тә карый алмыйм. Иртән торып, балаларны мәктәпкә озатканнан соң, эшнең кайсы ягыннан тотынырга белми аптырап бетәм. Җитмәсә, тәрәзә артында бригадиры кычкыра башлый. Җәй көне эшләп җан чыга, кыш көнендә ял булырмы дисең, кая ул! Әле өйдәгесе генә күпме! Мал карыйсы, ипи саласы, су ташыйсы... Сөйли китсәң, тавык та чүпләп бетермәс... Кайдан башларга белми «уф» дип бер кычкырып куям да ятам да йоклыйм. Кич буе шәл бәйләгәч йокы кала бит, көне буе кеше түгел аннары.

— Минем дә шулай, Фаягөл,— диде Бәдриҗамал.— Гел генә йокым килеп йөрим. Тамагым ачса, хәлем бетә, тамагым туйса, йокы килә...

— Тамак дигәннән, тәмлегә талымым юк, тәмсезгә комсызлыгым юк,— диде Фаягөл,— үлчик әле, ничә чирек булды икән. Читен башларга вакыт җитте бугай.

Болар кырыена Фәгыйлә, Нәсимә, тагы берничә хатын килеп урнаштылар. Болары кичәгеләр. Болары фал ачтыручылар түгел. Болары фал тыңлаучылар. Инде бу хатыннарга язга кадәр сөйләп, кышның озын төннәрен уздырырга ризык булды.

Мин өебезгә җыелып килгән бу апаларның сүзләрен тыңласам да тыңладым, тыңламасам да тыңладым. Яратам мин өй тулып кеше килгәнне. Дәресләрне әзерләп бетерсәм дә, һаман тәрәзә төбендә әле мин.Тәрәзә пыяласында салкын бизәкләп

ясаган «урманда» минем күзләр. Бүген әле әнинең минем якка карарга вакыты юк. Башка вакытта ул «кит, тәрәзәне ватарсың» дип, тәрәзә төбеннән бик тиз куа торган иде. Бүген рәхәтләндем генә... Болай игътибар белән караганым юк иде әле, бигрәк матур икән бу рәсем. Киң яфраклы агачлар берсе өстенә берсе авып төшкән, бәскә төренгән әкият урманына «кереп киттем». Агачлар арасында тырнагым белән сызып юл салдым.

Кинәт шул вакыт ишек ачылуга борылып карасам, минем генә түгел, барысының да муеннары шул якка каерылды, ишектә, кояштай балкып, үз өенә кергән кебек бер дә тартынып тормыйча, кәрә-керешкә пәлтә сәдәфләрен җибәреп, Мәликә апа күренде.

Хатыннар аны килмәс, дигәннәр иде. Алар кемнең киләсен, кемнең килмәсен күптән юрап куйганнар иде инде. Килде Мәликә. Нишләп килмәсен ул. Кешеләргә кирәк бәхет аңар кирәк түгелмени. Аңа башкаларга караганда да кирәгрәк әле ул. Сугышка ирен озатып кулына кара хәбәр алган бер ул гына булмаса да, Мәликәнең мәхәббәткә тансык йөрәге башкаларныкына караганда ярсурак булып чыкты.

Мәликә килеп кергәч, хатыннар утырган почмакта чыш-пыш китте. Аларга бер генә дә исе китмәде Мәликәнең. Кеше сүзенә ах итә торган булса, Мәликә дә булмас иде ул. Хатыннар ягына кызык өчен булса да борылып та карамады Мәликә. Гәүдәсе зифа, карашы горур, ә елмаюы — әйтерсең тумыштан ук елмаеп туган. Бер генә мизгел дә туктамый елмаюдан. Аның ачык чыраен күреп, тәмле сүзен ишетеп, ирләр генә түгел, хатын, кызлар да эреп китәләр. Аңа ачу саклаган берәр кеше бар микән авылда, юктыр. Үзенең затлы нәселдән булуына ишарә итеп, «Без бит әле, иске булсак та, постау кисәге!» дип йөргән Мәликәнең әйтсә дә хакы бар. Курчактай киенгән ул бүген. Башында чуклы ефәк шәл... Элекке заманнардан калган шәл. Күпләрнең сандыгын ачтырган, ахры, бу фалчы. Мәликәдәге шәл авылда башка беркемдә дә юк. Анда гына. Өстендә җиңнәренә чаклы кама куеп тегелгән киң якалы пәлтә... Үзе әйтмешли, постау пәлтә. Иске дип тә әйтерлек түгел. Әллә ничә елга бер мәртәбә генә чыга торгандыр сандыктан, чыкса да. Әллә йөзгә иннек-кершән дә тигән инде. Юктыр, Мәликә аларсыз да матур. Кайберәүләр кебек, кача-поса ике бит очын чеметеп йөргәне юк. Бит урталары болай да алсуланып тора. Мәликә турында миләүшә чәчәген ләйсән яңгыры тамчыларына кушып, ислемай ясый, дигәннәр иде, дөрес, ахры... Ул кергә, язгы урманда гына була торган хушлы миләүшә исе таралды өйгә.

Мәликә барысы белән дә исәнләште дә фалчы янындагы буш утыргычка килеп утырды.

— Җүнкәчләрем! Утырасызмы? — диде ул, ниһаять, кул

эшләре белән утырган хатыннар ягына җиңелчә генә күз сирпеп.— Миңа да бер җыелышып төшегез әле шулай!

— Син кешесез тормыйсың бит, Мәликә апа...— диде Фаягөл, төче тавыш белән.— Әле монтер егетләр синдә, әле зелпе җыючылар.

— Миндә монтерларга да урын җитәрлек, сезгә дә, күңелең киң булсын.

— Синең күңеленә, Мәликә апа, бөтен авыл сыя инде, анысын беләбез,— диде Фаягөл, төче тавышына азрак зәһәр өстәп.

— Ярар инде, кызлар, алай каты төрттермәгез,— диде хатыннарның берсе.

Фаягөл Бәдриҗамалның колагына нидер пышылдап алды, тегесе пырхылдап көлеп тә җибәрде.

— Фаягөл! Ничә кешенең язмышы керде шәлеңә? — дип сорады Мәликә, хатыннарның көнләшүле мыскыллы карашларын күрмәмешкә салышып.

— Керде инде монда...— диде Фаягөл, бәйли торган шәлен лампа каршысына күтәреп. Шәл артыннан аның: «Синең язмыштан читен бәйләрмен, Мәликә апа»,— дигән тавышы ишетелде. Хатыннар тагы бер көлешеп алдылар. Бер-берсенә төртешеп куйдылар.

— Уф, җүнкәчем, телең,— диде Мәликә апа.

— Синнән өйрәнәбез, Мәликә апа!

— Миннән өйрәнмә, җүнкәч, минем көнгә Ходай калдырмасын!

Хатыннар шып итте. Берсенең дә аның көненә каласы килми. Тик нәрсә булган аның көненә? Типтереп яши ләбаса! Бәхет сорап күршеләренә кергәне юк. Үзенеке үзенә җиткән. Җитмәсә, китереп бирәләр. Артып та китә кайчагында. Артып киткәне сүз булып авылда йөри. «Сөйләсеннәр! Арыгач туктарлар әле,— ди Мәликә. — Тел сөйләр өчен бирелгән ул. Әгәр дә мин булмасам, бик күңелсез булыр иде авылда».

Фалчы әлегә дәшми. Мәликә апаның әйтеп бетергәнен көтә. Кем килеп кергәнен ул шунда ук сизенде. Күзе күрмәгәнгә гомере буе үкенеп йөри торгандыр бу фалчы. Ә менә Мәликә апаны бер күреп алып, яңадан сукырайса да, гомердә дә үкенмәс иде. Әгәр дә күзе күрсә, шушындый матур хатынның ни өчен болай «Ходай күрсәтмәслек» тормышта яшәгәнен аңлап та бетермәс иде. Тик ул бит фалчы. Ул аңлый. Күзе күрмәсә дә, фалчылыгы күрсәтә аңар.

— Абый, тыңлама алар сүзен,— диде Мәликә.— Китабыңны ачып кына әйт әле, әйбәт кешеме мин, начар кешеме?

— Исемең?

— Мәликә...

— Исемеңнең мәгънәсен беләсеңме?

— Әй абый җаным! Кая инде безгә! Исме әгъзәмнәрне ишеткән булсам да, укыганым юк шул!

— Патшабикә дигән сүз ул...

Болай да колакларын торгызып утырган хатыннар, фалның шулай башлануын ишетеп, кул эшләрен ташлап, күзләрен боларга текәделәр.

«Нинди сихер микән бу Мәликәдә. Шушы сукырны да үзенеке итте бит!»

— Патшабикәләрдәй булып туган идек... тормыш кына бирә кирәкне! — диде Мәликә апа.

Фалчы китабын ачты. Мәликәгә кирәк җирен бик тиз тапты ул.

— Син бөтен кешеләргә яхшылык белән ярарга тырышасың икән. Тик кешеләр синең яхшылыгыңны аңламыйлар.

— Аңламыйлар, җүнкәч, аңламыйлар, абый җаным! Кайлардан килеп чыктың син безнең якларга! Бик дөрес әйтә, дигәч, ышанмаган идем, ышаныч бирдең бит әле бу сүзләрең белән.

— Синең миңа ышанмаганлыгыңны мин инде син монда килгәнче үк белгән идем,— диде фалчы.— Күңеле белән ышанмаган кешеләргә фал ачмыйм мин. Тик сиңа ачам. Чөнки синең күңелеңдә усаллык та, мәкер дә, көнчелек тә юк. Якты синең күңелең ... Үзе фал китабы кебек.

— Күңелем фал китабы кебек булса да, иртәге көнемнең ничек башланасын, ничек бетәсен белмим мин. Бер башлагач әйтеп бир инде, абый җаным, теге монтерлар озак торырлар микән безнең авылда.

— Аларның юлы бу китапта түгел... Биредә синең язмыш кына. Тик синең язмыш бер дә алар белән бәйле күренми.

— Үземә генә сөйлә әле шул китабыңның сүзләрен, җүнкәч,— диде Мәликә апа, фалчыга якыная төшеп.— Минем күңелдәгене әйтеп бирә башласаң... күземне дә ачырмаслар аннары... Үзем шушындый булсам да, күңелем тулы сагыш, хәсрәт минем. Ахирәт дустым бул, абый җаным...

Ачы-ачы сүз әйткәләсәләр дә, Мәликәне яраталар авылда. Ни өчен, дисезме? Мин дә шулай дигән идем элек. Ә хәзер белдем ни өчен ратканнарын. Авылның ир-атлары гына түгел, хәтта хатын-кызлары да, үзләрендә булмаган, бар кешене яраттыра торган сихри дәрт бөркелеп торганга, көнләшү катыш хөрмәт итәләр аны. Аннан соң Мәликәнең ихласлыгы яраттыра. Үзендә бер кич уздырып чыккан ирләрнең бала-чагаларын, хатынын, әти-әнисен дә чынлап ярата башлый Мәликә. Үзе әйтмешли, өе турыннан узган барлык ирләргә дә гашыйк ул. Сөйләгән кешеләргә әйткәне бар икән аның. «Ул ирләр бит миңа бәйрәмгә килгән кебек киләләр. Әгәр дә өйләрендә миндәге кебек бәйрәм булса, килмәсләр иде. Ә гомер буе башкаларга бәйрәм ясаган кешегә бик авыр яшәве, шуны белмиләр. Шушы ярату булмаса, ничек яшәргә кирәк бу дөньяда. Шушы яраттыру яшәтә дә мине...»

Әллә инде сөйләгән, әллә инде сөйләмәгән бу сүзләрне... Бәлки, уйлап чыгарганнардыр. Кем белсен...

— Әллә үземә генә төшәсеңме, абый, җүнкәч! — диде Мәликә апа өзгәләнеп.— Төне буе укыр идең китабыңны. Бәхет дигән сүз һаман чыкмады бит әле... Өметеңне өзмә, дисең... Өмете өзелми аның, бәхетсезлектән үзәге өзелә. Әнә алар минем бәхеткә көнләшеп утыралар. Көнләшәсез бит, кызлар, көнләшәсез... Оясы туздырылган тол хатыннан көнләшмәгез, кызлар... Тормышымны башлап җибәргәндә, әллә мин бүгенге бәхетемне күз алдымда тоттыммы? Бүгенге бәхетемне юрадыммы? Әгәр дә бу тормыш мин уйлаганча барып чыкса, барыгыздан да бәхетле булачагымны мин ул вакытта ук белә идем. Көнләшмәгез, кызлар, бәхетегезне сакларга өйрәнегез. Мин әле кеше өлешеннән төшеп калган валчыкларны да бәхет бөртекләре дип йөрим бит. Алдыйм үземне. Башны ташка бәреп булмый икән... Җан изге...

Мәликәнең күзеннән аккан яшьләре бите буйлап төште дә алсу иреннәре өстендә тукталып калды.

— Абый җаным, әллә алып кына китимме үземә...— диде Мәликә, яшь аралаш елмаеп.— Ә-ә, монда көтеп утыручылар да бар икән. Рәхмәт, абый җаным, сиңа, гомердә дә онытмам,— диде дә, кояштай елмаеп кергән Мәликә апа коелып елап чыгып китте.

...Мин әле һаман тәрәзә төбеннән киткәнем юк. Өйдәгеләргә аркамны куеп, суык бизәк ясаган урман эчендә йөрим кебек. Бармакларым белән эретеп, тәрәзәдәге киң «яфраклы» «агачларга» «алмалар» эләргә тотындым. Хәзер инде кулымның туңуы беткән, тәрәзә салкынлыгыннан аларга рәхәт кенә... Бер алма, ике алма...

Мәликә апа чыгып киткәч, аның урынына, бер төргәк тотып, Гайниҗамал җиңәчәй килеп утырды. Мин аптырап киттем, җиңәчәйгә нәрсә кирәк инде бу фалчыдан, дип уйлап куйдым.

— Улымның хатлары,— диде Гайниҗамал җиңәчәй.— Ә менә боларын командиры язган. Бик әйбәт хезмәт итә, дигән, мондый ул үстергәнегез өчен рәхмәт сезгә, дигән. Тик менә күптәннән улымның хаты килгәне юк. Кайчан гына кайтыр микән, шуны әйтеп бирсәң иде...— Гайниҗамал җиңәчәй, кабалана-кабалана, фалчының кулына төргәге белән хатларын тоттырды. Фалчы нигәдер җиңәчәйнең дә, улының исемен дә сорап тормады бу юлы. Китабын да ачмады, хатларны да кире җиңәчәйгә суzды.

— Улың бик якында, апа... юлга чыккан...— диде. Фалчы шушы сүзләрне әйткәндә, тәрәзәдәге «урманым» «алмалар» белән тулган иде инде. Кинәт... куе зәңгәр генә түгел, (урамга

төн караңгылыгы төшкән иде) кап-кара «алмамның» берсендә нидер ялтырап китте. Абау! Нәрсә булды бу! Мин аңларга теләп «алмама» өрдем дә, шул арада бозлана башлаган тәрәзә пыяласын эреттем.... «алма» уртасыннан чекерәеп зәп-зәңгәр күз карап тора иде миңа. «Әни!» дип кычкырып җибәрүемне сизми дә калдым. Тик башкасын хәтерләмим. Әллә куркудан, әллә чирләп китүдән аңымны югалтып, тәрәзә төбеннән сәкегә авып төшкәнмен. Күтәреп урынга салгач та, күпмедер һушыма килә алмый ятканмын. Күземне ачканда, янымда куркынган йөзле әни белән Ноябрина апа утыра иде.

Ноябрина апа калтыранган куллары белән маңгаемны сыйпады.

— Ут яна...— диде ул пышылдап.

Өйдә башка кеше калмаган дисәм... Өйнең уртасында, аякларын киң җәеп басып, зәп-зәңгәр күзләре белән барыбызны да йотарга әзерләнгәндәй, Кара кул Хәбри тора иде. Менә кемнең күзләре булган икән тәрәзәдә!

— Районнан килгән полномоченныйларны кертергә берсе дә риза түгел, пнимаетели! Ә монда җыен килмешәккә урын табалар!

— Хәбри балакаем, Хәбри балакаем... Җиңәчәй дә чыгып китмәгән икән, бу аның тавышы.— Алла бәндәләре алар, мосафирлар...

— Беләбез нинди Алла бәндәләре икәнен! Налог түләминитми генә халык сыртын кимереп йөрүче килмешәкләр алар!

— Түгел, Хәбри балакаем, түгел, гөнаһлы булма,— диде Гайнинҗамал җиңәчәй.— Әнә бит, улың кайта, диде миңа.

— Кайтмый кая барсын! — дип акырды аңар Кара кул.— Әллә сугышка озаткан идеңме, ә!

Гайнинҗамал җиңәчәй рәнҗеп авызын йомды да улының хатларын кочагына алды.

— Син хөкүмәт кешесе инде, без надан халык. Ни әйтсәң дә, синеке дөрес...— диде ул, чыгып китәр алдыннан.

Каты итеп ишек ябылуга, мин тагы караңгылыкка чумдым. Әллә төштә, әллә өндә булды... Баздан чыккан кебек гөрелдәп чыккан тавышлар белән төне буе саташып чыктым.

...— Кунаклар! — диде Хәбринең мыскыллы тавышы.— Беләбез аларның нинди кунаклар икәнен... Бу ниткән законсызлык бу, пнимаетели! Налог, заем, дисәң, акчалары юк, ә боларга табалар! Мосафирлар, имеш! Районда алар артыннан күптән күзәтү билгеләнгән инде. Шпионнар алар! Нимес шпионнары! Фал ачарга түгел, мәгълүмат җыярга чыккан алар.

— Кычкырма, Хәбри! — диде фалчы абый тавышы.— Документлар чиста минем. Таныдың бит син мине, нигә һаман кычкырасың. Куркытма кешеләрне. Балалар йоклый...

— Син! — диде Хәбринең гыжлаган тавышы.

— Үлде дип сөенгән идеңме. Үлмәдем мин ул чакта... Син бит ул вакытта миңа ярдәм итә ала идең... Куркак җан син... Таптылар мине забойдан, өч көн үткәч казып чыгардылар... Шуны гына әйт әле, Сәгыйдәне нигә дип алып киттең син?!

— Анысы минем эш! Әллә миннән сорау алмакчы буласыңмы?!

— Калсын... тик бәхетле генә булсын... кешегә бәхет бирүче кеше түгел шул син... Авылдашларыңның фалында да син күрсәткән җәберлекләр... Биредә дә синең зәхмәтең тими калмаган. Син бит...

— Молчать! Мин сезне егерме дүрт сәгать эчендә урнаштырыр урын табармын! — дип кычкырды Хәбри.

— Табасыңны беләм... син бер сәгатьтә дә табарсың, синең кул озын. Тик көчәнмә, син рәхәт яшәгән сугыш заманалары узды инде. Телисеңме, фал ачам үзеңә? Теләмисең, әлбәттә. Тик барыбер тыңла, бәлки, үлем белән тартышканда исеңә төшәр,— диде фалчы абый тавышы.

— Син миннән алданрак катырсың әле, сукыр тычкан! — диде Хәбри.

— Әлбәттә, үләрмен, тик бит син дә дөньяга гомергә килмәгән. Халык өстендә селтәгән кара йодрыкка төйнәп булмый ул гомерне. Курыкмыйм бит мин синнән. Ә син миннән куркасың. Миннән курыкма, уттан курык син. Әҗәлең уттан синең... уттан... Картаеп гөнаһларыңнан тәүбә китереп торырга вакытың булмаячак синең... Үлгәндә дә, үлгәч тә утта син. Тәмуг уты фани дөньяда ук башланачак синең өчен... Утта...

— Ут яна бу бала... — монысы әни тавышы... — Нишләргә соң, һаман саташа.

...— Каргышың карга башына! Иртәгә үк сыпырт авылдан, атлы милиция чакырткanchы! — диде Хәбри тавышы.

Кемдер елый. Ә нигә соң минем күзләремдә дә яшь? Бер сүз әйтергә дә авызым ачылмый, телемне әйләндерергә дә хәлем юк. Кем елый соң анда...

— Елама, Ноябрина, елама.

Бу бит фалчы тавышы.

— Шушы очрашуны сизеп чыкканмын мин юлга. Ә хәзер кайтып китсәк тә була. Кем белә, атлы милиция җибәртсә, немец шпионнары дип ябып та куярлар. Ә без синең белән немецча бер сүз дә белмибез... Елама...

...Кабат мин аларның тавышларын ишетмәдем. Мин әле тагы өч көн башымны күтәрә алмый саташып ятканмын. Ә чирдән терелеп, торып утырганда, фалчылар бездә юк иде инде. Алар шул кичтән соң, икенче көнне таң белән киткәннәр безнең авылдан. Үзләре генә китмәгәннәр, бу хәлне ишеткәч, авыл халкы ах иткән, аларга ияреп, Хәбринең хатыны Сәгыйдә дә

киткән авылдан. Мин аларны озатып калмасам да, алар һаман минем күз алдымда. Ишегалдына чыгып, бакча артындагы урманга караган саен, һаман алар исемә төшә. Мин, күз алдыма китерергә тырышып, алар турында уйлыйм. Күз камаштырырлык җемелдәгән кар өстеннән бәскә төрелгән ап-ак урманга таба өч кеше бара... Икесе алда, бер-берсенә ябышып диярлек атлыйлар... ә өченчесе артта... Куып җитәрме ул аларны? Белмим. Фалчы абыйның кеме иде ул Кара кул хатыны Сәгыйдә? Аларның очрашуы, язмышы ничек башланган булды микән? Бу минем өчен гомергә ачылмаган сер булып калды.

...Күпме еллар үтте инде ул вакыйгаларга... Авылда күптән оныттылар инде ул фалчылар турында. Авылда да, авылдашларда да үзгәрешләр күп соңгы елларда. Берничә ел инде «мин туып килүче пролетариат» дип йөргән Миңлекәй абый да үз сүзләренә үзе тәмам ышанып җиткәч, бөтен оясын алып, авылны ташлап китте. Еракка түгел түгелен, район үзәгенә генә, ләкин барыбер авылда түгел. Шуннан башланып, авыл халкы берәм-берәм, бәхет эзләп, төрлесе төрле җиргә тарала башлады. Анысы безнең халыкның чиредер инде ул. Заманында күрше авылларны да барып күрмәгән авылдашларга да йокты ул чир...

Ә Хәбри... Мин авырып ятканда, әллә төштә, әллә өндә ишетелгән фалчының сүзләре чынга чыкты. Фалчылар киткән елны аны авыл советыннан алдылар. Безнең авыл белән күрше авылны кушып, бер авыл советы ясадылар. Хәбрине үзебезнең авылга бригадир итеп калдырдылар. Тик бригадирлыкны алып бара алмады Кара кул. Үзе хакимлек иткән вакытта, бигрәк тә сугыш елларында, һәр көн саен тентү белән кереп, көннәр буе яшь балаларын тартып басуда эшләгән хатыннарның эштән кайтканда чабата олтыраклары асларына кадәр тикшереп, үзеннән тәмам гайрәтен чиктергән халык аны хөрмәт итмәде. Ферма мөдире итеп куйгач та, эшенең рәте чыкмады. Сыерлары сөт бирмәде, бозауларга үләт чыкты. Бу хәлгә ул үзе дә аптырады. Фермадагыларның эшен тикшерергә дип, ферма өендә куна калган бер кичендә, тәмәкесеннән төшепме, ут чыгып, янып үлде Хәбри. Әллә фалчы сүзе рас килде, әллә инде чынлап та язмыш дигән нәрсә килеп тотты аны. Утны төрткәннәрдер дип әйтүче булса да, тәфсилләп тикшереп тормадылар. Ут башка каралты-кураларга җәелмәде.

Фалчыларның безнең якларга килеп чыкканы булмады яңадан. Хәбри хатыны да авылга кире әйләнеп кайтмады. Ә балачагымның серле һәм гыйбрәтле бу вакыйгасы минем күңелемнән һич китмәде.

*1990–1991*

# Хикаялар



# Сагынасыңмы, дип сорыйлар...

Елның кайсы гына вакыты булмасын, салкын кышларымы, яңгырлы юеш көзләреме, җәй көннәрен әйтеп тә торасы юк инде, минем һәрвакытта да авылга кайтасым килә. Чит җирләрдә яшәп, күпме еллар узса да, сагынуларым кимеми. Авыл кешесе күңеле белән шәһәргә төпләнә алмый, күрәсең. Авылдан читтә укып йөргән елларда да, мин әти белән әнине, туганнарымны, үзебезнең өйне, бәрәңге бакчасын сагына идем. Арабызда авылдашлар да булгач, яшьтәшләрне сагыну алай каты булмагандыр инде. Ә менә өйгә кайтасы килү теләге бер генә минутка да күңелдән чыкмый торган иде. Каникулга, мәсәлән, бер ай алдан әзерләнә башлый идек. Алай гынамы, кечкенә чемоданнарыбызны күтәреп, иптәш кызлар белән тулай торак ишегалларын урамштырып та керә идек әле. Шушы сагынулар инде безне буранына, яңгырына карамый, алтмыш чакрымлы җәяүле юлга алып чыга торган иде. Шагыйрьнең «Юлларын кар баскан Мамадышның, үзе белә микән Мамадыш...» дигән юлларын кычкырып сөйли-сөйли атлыйбыз. Димәк, көрт ерып туган өйләренә кайтучылар бер без генә түгел. Әгәр дә шушы кышкы юлларда берәр машина да очрап куйса, бәхет күккә аша.

Еллар уза, тормыш үзгәрә, тормыш белән без дә үзгәрәбез икән. Хәзер инде күңел өйдәгеләрне генә түгел, урман буйларын, су юлларын, урамнарны, шул урамда йөргән һәр кешесен юксына. Ә авыл... авыл инде, без үскәндәге авыл түгел, кешеләр дә икенчерәк. Хәер, алар да үзгәргән, соңгы елларда ярты авыл бушап калган. Кайчагында, сагынуларым көчәйгәндә, күңелем белән өйдән өйгә кереп, авылдашларымны барлыйм, хәлләрен белеп чыгам. Тик уйларым белән бушлыкка әйләнгән нигез ташларына орынам. Өйләргә караганда буш нигезләр күп икән авылда. Авылны ятим итеп күпләребез таралган икән шул. Ләкин кайталар алар авылга, хәл белергә булса да, барыбер кайталар. Хәтта хәзер инде нәсел-нәсәбеннән бер генә исән туганнары калмаганнар да кайтып төшә икән. Читтән кайтучыларга да авыл халкының артык исе китми шикелле. «Җәй җитсә, кунак белән чебеннән күп нәрсә юк» дип тә җибәрә кайберләре. Кайсы гына өйнең ишеген шакыма, йә улы, йә кызы читтә ләбаса. Без авылга озакка кайтмыйбыз, вакыт юк.

Күрешәбез, исәнлек хәбәрләрен беләбез дә яңадан үз дөньябызга, үз тормышыбызга ашыгабыз. Читтән кайтучыларга ис китмәү, бәлки, шуннан килә торгандыр, узгынчылар!

Авыл — безнең туган җиребез. Кеше өчен туган җирдән дә кадерлерәк тагы ни бар? Шуңа күрә без авылны сагынмыйча яши алмыйбыз. Чөнки без атап йөрткән юллары, без үскәндә генә барлыкка килгән, без исем кушкан ерганаклары бар бит аның. Алар безгә, безнең балачак тарихына, без тарткан «уфалла» арбаларының эзләренә барып тоташкан.

Мин үзем сагынуларга чыдап яши торган кеше түгел, түземсез мин. Менә быел да, кыш өсте дип тә, озак юл дип тә, җәй көне генә күрешкән идек бит дип тә тормадым, җай чыгу белән, азга булса да, авылга кайту ягын карадым. Кайттым да үзем өчен зур бер ачыш ясадым. Менә кайсы вакытта кайтырга кирәк икән ул авылга! Бу юлы мин эти белән энинең генә түгел, урамыбызның, күршеләребезнең кадерле кешесенә әверелдем. Кайтуым озакка түгел, сәгатьләрем дә санаулы югыйсә, әмма ераграк урамнардагы әбиләргә кадәр килеп җиткән. Алар да инде без бәләкәй чактагы әбиләр түгел. Утырыр урындыкларына бияләйләрен салып, «Ходай хәерле бәрәкәт бирсен йортка» дип, дога кылып тормыйлар. Дога кылу дигәннән, миңа бик кызык булып тоела иде бу хәл. Өйгә олы яшьтәге берәр кеше кердеме, ни өчендер кыш көне булуы истә калган, эни, ул кеше утырасы урындыкка салыр өчен, өй бетереп, йомшак әйбер эзли башлый, йә булмаса, җыйган урынны ишеп, берәр бәләкәй мендәр алып сала торган иде. Әгәр инде ишектән кергән кеше итекләрендәге карларын себереп, бияләйләрен салып, шәлен чишеп җибәргән вакытка урындыкка әйбер салынып өлгермәсә, кунак җәһәт кенә үзенең бияләйләрен урындыкка сала да үзе шулар өстенә утырып дога кыла торган иде. Мондый чакларда эни, кунакның утыруын күрүгә, әйбер эзләвен ташлый да, туктап торган җирендә утырырга урын булмаса, аркасын стенага терәп булса, кергән кеше белән дога кыла торган иде.

Бервакыт энидән:

— Эни, нигә шулай кабаланасың, урындыкка болай гына утырса нәрсә була? — дип сорадым.

— Кызым, бу синең эш булырга тиеш,— диде эни шелтәләп.— Синең ишегеңне ачып өеңә кергән кешегә хөрмәт күрсәтү билгесе ул. Якын күршең булса да.

— Ә нигә соң ул бияләе өстенә утыра?

— Анысы да юктан гына эшләнми аның. Кунагың үз бияләенә утырып дога кылса, аның «Ходай хәерле бәрәкәт бирсен йортка» дигән теләге безнең өй өчен түгел, үз өе өчен була, белдеңме?

Менә эни шулай дип әйтмәгән булса, каян белер идек ку-

накчыллыкның шундый нечкәлекләре дә барлыгын. Һәм бу хәлнең олы тәрбия мизгеле икәнлеген дә. Хәзер инде алай ук бик тәфсилләп тормыйлар... Ул яктан гадирәк халык...

...Кайтуыма озак та үтмәде, күршеләр белән өебез тулды.

Иң беренче булып әнинең апасы Фәгыйлә апа кереп җитте.

— Синңа охшаган берәү китте дип карап калдым артыңнан, чынлап та, синме соң? — диде ул, мине кочагына алып.

Аның артыннан Җәмилә апа да кереп җитте.

— Кунак бар икән, белмәгән идем... Җиде яшьлек ил йөреп кайтса, җитмеш яшьлек хәл белергә керер, ди... Бик дөрес кергәнмен икән әле,— диде ул, үзен-үзе дөресләп.

Ул арада әнинең самавыры да кайнап чыкты. Барыбыз да өстәл артына җыелыштык.

Шул вакыт урам капкасының каты итеп ябылганы ишетелде.

— Тагы бер хәл белүче, аягым җиңел булды,— диде Фәгыйлә апа.

Безнең авылда ир-ат турыдан-туры өйгә керми. Ишегалдыннан гына тавыш биреп, хуҗаны чакырып чыгара. Сөйләшәсе сүзен дә шунда гына сөйләшә. Ләкин бу юлы әлеге гадәтне бозып, үзалдына сөйләнә-сөйләнә, күршебез Кыям абый өйгә үк килеп керде.

— Әссәләмәгаләйкүм, кордый! (Әти белән аерым исәнләште әле бу.)

Хатын-кызларга борылып, ул:

— Нихәлләр, гөл бакчалары! — дип сәлам бирде.— Ашларыгыз тәмле булсын!

— Бергә-бергә булсын, утыр, күрше!

— Чәй яныннан гына, рәхмәт...

— И-и, аштан олы түгелсеңдер әле, әйдә, әйдә, аш—ашка, урыны башка,— диде әни кыстап.

— Нәрсә, Мәскәү, кайттыңмы? Ничә көнгә, болай кыш уртасында дип әйтүем, отпус-мотбус түгелдер бит?

— Юк, Кыям абый, болай гына, бер генә көнгә булса да хәл белергә дип кайттым әле менә.

— Вәйт, егетләр! — Кыям абыйның сап-сары кашлары дугаланып өскә күтәрелде, җете зәңгәр күзләренә очкын кабынды.— Бер көнгә! Кайттым түгел, кереп чыгарга булдым диген инде.

— Алай дисәң дә була. Тик сагыну менә шулай йөртә икән, Кыям абый. Менә ничек җыелыштык. Барыгызны да күреп китәм бу юлы.

— Бәндәне ризык йөртә,— диде Фәгыйлә апа. — Язган ризык теш сындырып булса да керә, ди.

— Чәйгә манчып кап,— диде Кыям абый.— Соңгы тешеңнән дә яза күрмә тагын, күчтәнәч күрдем дигәч тә...

Барысы да көлешергә тотындылар, табын гөрләп китте.

Кыям абыйның йомышы миндә иде, күрәсең. Ул, чынаягын каплап куйса да, чыгып китәргә ашыкмады. Бары тик «борчылма» дигән сымак әнигә кул селтәп куйды да, урындыгын алып, өстәл кырыеннан читкәрәк күчеп утырды. Кыям абый да картайган. Картаерсың шул. Гомер үтә бит. Аның да биш кызы биш якта яшәп ята. Ичмасам, терсәк буе гына бер малай булса дигән өмет белән яшәгән Кыям абыйга хатыны бер-бер артлы кызлар гына алып кайтып торды. Кызлар күбәйгән саен, этиләренең күңелендәге малайга дигән урынны алар биләп алды. Гаиләсендә бердәнбер малай булып үскән Кыям абый, эти кеше булгач та, төпчек малай кебек кадер-хөрмәт эчендә кала бирде. Хатыны аны хәтта кызларыннан аерым ашатты. Ир кеше, хуҗа кеше, эти кеше! Хуҗалыктагы эшнең авыррагын да хатыны үзе эшләде. Ат җигеп урманга, басуга барасы булсалар, Кыям абый ишегалдыннан ук арбага утырып чыга, капка ябып калган хатынын да көтеп тормый, барасы юлына юырта тора. Ә кайтканда... хатыны аттан да алданрак чабып кайта да, киереп капканы ачып, йөк өстендә кырын ятып, дилбегәсен тоткан ирен каршы ала иде.

Без бәләкәй чактагы хәлләр инде болар. Үткәннәрне уйлап, табындагыларның сүзләрен дә ишетми утырам икән. Кыям абыйга карап куйдым, ясап куйгандай түгәрәк сакаллы бабайга әйләнгән.

— Әллә мулла булырга инде ниятең, сакал җибәргәнсең,— дидем.

— Әй Дәлифә! Күз күрми минем хәзер, сакал төзәтергә дә куркып торам,— диде Кыям абый.

Минем исемне гомер буе дөрес әйтмәде инде ул.

— Менә, Дәлифә, мин синең янга ни өчен керде дисең син. Минем Мәскәүдәге Әндрүшкәнең хәле ничек микән? Шуны сорашмакчы идем. Хаты да юк. Үзе дә югалды. Яшь кеше түгел бит инде. Хәзер кем бар да кем юк дигәндәй. Хатыны да үзебезнең кеше булмады бит инде... Әндрүшкә дигәнгә әллә нәрсә уйлама, шаяртам анысын, хатыны Мәрүскә шулай дип дәшә аңар... Әгъләм абыеңнарга барганың юкмы?

Мәскәүдә яшәүче Әгъләм абый аның туганнан туган абыйсы туры килә бугай.

— Ничек дип әйтим инде, Кыям абый... Бер-ике тапкыр барган идем, гел салган вакытына туры киләм. Дөресен әйткәндә, күптән күрешкән юк.

— Вәйт егетләр! Үзгәрмәсә үзгәрми икән кеше, ә! Ничә ел буе Мәскәүдә яшәп, һаман ташламасын әле диген шул эчүен! Мәскәү тикле Мәскәүдә кырык ел яши бит ул! Менә мин үзем ике атна гына бүлнистә ятып чыктым, шуннан гел икенче кешегә әйләнеп кайттым бит. Әле бит Мәскәү бүлнисе дә түгел, районныкы гына.

Табын артындагылар көлешеп алдылар. Ләкин Кыям абый беркемгә дә сүз кушарга ирек бирми, һаман үзенекен сүтте.

— Менә шулай дип кенә кергән идем, күрешкән юк, дисең алайса... Вәйт егетләр, әйтсәм әйтим инде, ничек оялмый диген. Шушы яшенә җитеп тә инде, тьфү, билләһи!

— Кемнән оялсын? Туган-тумачасы янында түгел... Шәһәр җирендә кемдә кемнең эше бар,— диде Җәмилә апа.

— Хатыныннан оялсын, ичмасам. Аның хатыны афтарититлы кеше, урында. Сезнең ише генә түгел. Ул анда лифтеләр эшләгәнне тикшереп утыра. Ул сиңа баскыч сөяп сәндерәгә тавык оясына менү түгел, кешеләр йөртә ул лифте, бишек инде, бишек!

— И-и, сөйләп торган була тагы! Син үзең ояласың инде хатыныңнан! Бик белеп әйткәннәр: иргә ышанма, Иделгә таянма, ир — денсез, Идел — төпсез! Әнә теге вакытта, алтынчы малаемны тапкан көнне ни булды минем ир белән? Әз генә авызына керсә, җен булып чыга бит. Мин бәбәйләп ятам, шул сөенечтән төшереп алган да, күршеләргә кереп, әллә ниләр кыланып, самавырларын имгәтеп чыккан.

— Сез монда субрәнҗә ачып утырмагыз әле. Бер көнгә кайткан кешенең авызын да ачарга ирек бирмисез,— диде Фәгыйлә апа.

— Кыям абый, больница да больница, дисең, кай төшең авыртып кергән идең соң?..

— Мәскәүдә ишетелмәдемени? Бөтен авыл гына түгел, тирә-як гөжләде бит монда. Елан чакты бит мине быел...

— Чынлапмы? Ничекләр исән калдың?

— Барысына да үземнең беркатлылык гаепле инде. Юләрлек димме... (Табын артындагылар бер-берсенә карашып, тыела алмый көлә башладылар.) Тыңлаган кешегә көлке, минем хәл мөшкел иде ул вакытта. Колхоз идарәсе, хуҗалыкларга да өлеш чыгарып, урманда печәнлекләр бүлеп бирде быел. Урманда шау-гөр, куак төбе саен кеше. Кайсы печән чаба, кайсы әйләндерә. Мин дә үз көемә генә кыштырдап, кипкән печәннәрне күбәләп йөрим, мин сиңа әйтим... Бер пакусны әйләндереп җибәрүем булды, каратаякларның оясына юлыкканмын икән. Каратаяк дип кенә әйтү аз булыр монда, аждаһа оясына туры килдем мин. Менә шул мәлне бәләкәй чакта ишеткән бернәрсә искә төшеп китте бит. Имеш, елан патшасының мөгезе була икән, әгәр дә шул мөгезне табып, акча янчыгына салсаң, акчаң бер дә кимеми, гел артып торасы, ди. Шушындый хәтәр чакта башны алып кына качасы бит инде, юк, мин сәнәк белән тегеләрне төрткәли-төрткәли патша мөгезен эзли башладым... Берсе орынып кына киткәндәй иткән иде...

Шул вакыт агачлар арасыннан күрше Садрый атылып чыкты:

— Нәрсә шулай күкле-яшелле тавышлар белән кычкырасың? — ди.

— Чакты! Чакты!

— Шаяртма,— ди бу.

Ул арада урманга сибелгән бөтен авыл җыелып өлгерде. Кая, кая, күрсәт тә күрсәт, диләр. Чалбар балагын күтәреп карасак... тешләгән урыны беленеп тора, прәме. Нәрсә эшләргә дә белмим. Төрле яктан кычкырышып киңәш бирә башладылар:

— Агуы таралмасын, бау белән бәйләргә кирәк! Бау китерегез, бау! — ди берсе.

— Нинди бау?! — ди икенчесе.— Агуын суырып төкерергә кирәк! Бетәсең бит!

Үзем бернинди авырту да сизмим, каушатты бераз, печән күбәсенә утырдым да аякны авызга турылыйм хәзер, агуын суырып төкерергә исәп. Шул вакыт чүп өстенә чүмәлә дигәндәй, китереп тотты теге бил өянәге, кәкрәйдем дә каттым.

Шунда берәү әйтә:

— Азапланма инде, синең тешләр белән тагы... Авызыңнан да агуланырга уйлыйсыңмы? Бүлнискә озатырга кирәк,— ди.

Бил җибәрсә, торып китәрмен дә кебек. Шул арада күңел болгана башлады, укшып, җиргә авып төштем. Рәхмәт инде Садрыйга, матае белән очыртты гына районга. Ул күңел уйный, ул укшыта, мин сиңа әйтим... Менә шулай, гөл бакчалары. Хәзер көлеп утырсаң да була. Ә бит бүлнистән гел икенче кеше булып кайттым мин.

Икенче кеше мин хәзер. Иң шаккатырганы — чирләр бетте. Ашказаны да сау минем, касык чәнчеп торулар да онытылды. Әллә дарулардан файда булды, әллә теге каратаякның агуы дәвалады... Бер-ике елдан тагы шулай чактырып аласы булыр дип торам әле. Өйдә чакта бернәрсә дә күрмисең дә, сизмисең дә икән. Гомердә дә уйга батып утыра торган кеше түгел идем мин. Уйландым бүлнистә... Авылны, басуны, урманнарны сагындым. Тазнарат тавын, Бурсык елгасын, урмандагы Нурлы юлын... Барысы турында да аерым-аерым уйладым. Менә, мин әйтәм, без әле бу исемнәрне беләбез, шушы җирләргә басып йөрибез. Менә сезнең дә балалар үсә. Кунакка кайтсалар, минем дә оныклар йөри шул җирләрдә. Ә бит аларга урман— урман, басу-басу. Яфрак та җиләк. Безнең бабайлар кушкан исемнәрне онытмаслармы икән? Шул исемнәрне үз балаларына өйрәтә алырлар микән? Ә син, сеңлем, зинһар, тагы бер генә тапкыр булса да барып кайт абыйларга. Хат язарга беребез дә махир түгел. Бу тикле хәлләрне, күңелдә булганнарның барысын да хатка да язып бетерә алмассың. Кайтсын әле. Көтәләр сине, диген. Урман буендагы куаклыклар да, умарталык артындагы җиләклекләр дә, Мунчала күперендәге салкын чишмәләр дә — барысы да көтәләр, диген. Әнә тау башындагы каенлыкта безнең дә урыннар әзер... Җир астыннан юллар булмас... Исәнлектә бер күрешеп сөйләшергә иде. Менә шулай итеп, эчләр бушаганчы.

# Май кырмыскасы

Май аеның үләне дә, чәчәге дә, кояшы да файдалы, диләр. Шуңамы, әбиләр, хәстәрле апалар бу айда көлтә-көлтә үлән киптерәләр, чабыныргa себеркесен җыялар. Ә менә киптереп куеп та, җыеп алып та булмый торган тагы бер сихәте бар икән әле май ае табигатенең. Ул да булса — май кырмыскасы. Ничә ел инде авылга май аенда кайтырга тырышсам да, һич туры китереп булмады. Быел да июнь башларында гына кайтырга туры килде. Хәл-әхвәл сорашкач, әни һәрвакыттагыча ничә көнгә кайтуымны сорады.

— Иртәгә көн әйбәт вакытта урманга менеп төшәрбез. Май кырмыскасын да иснәрбез.

— Әни, май бетте бит инде.

— Искечә май уртасы гына әле. Быел яз соң килде. Май себеркесе дә җыярбыз. Яфраклары калынайсын дип тора идем, бер мунчалык та себеркем юк әле быел.

Әнинең олы апасы Фәгыйлә апа белән дә кичтән үк сөйләшеп куйган идек, иртә белән ул да кереп җитте.

— Йә, ничек йокладың, шәһәр кешесе? Машина тавышыннан колакларың тонадыр анда? Колакларың ял иттеме бераз?

— Шәһәр тавышына күнегелгән инде, Фәгыйлә апа. Бүген әле мин, авылда тавыш күбрәк икән, дигән фикергә килдем.

— Китче, монда нинди тавыш булсын.

— Мин шәһәр тавышына ияләнгән кебек, сез дә ишетмисез инде аны. Йокыга гына китә башлаган идем, озак утырдык бит кичә, тотынды әтәчләр!.. Берсе башлый, икенчесе элеп ала... алар гына туктаган иде, сыер мөгрәп куйды, аңар бозавы кушылды. Гел шушы тәрәзә янына гына килеп кычкыралармыни! Җитмәсә, бер чебен кереп калган... тәрәзәдән яктылык пәрдәсе ачыла башлауга, анысы уянды... Бераздан Рифатың тракторын кабызып җибәрде, әнә һаман пырылдатып тора. Ни кузгалып китми, ни сүндерми шуны...

— И-и.. Син бигрәк инде!.. Чебен тимәс чер итәргә әйләнгәнсең. Трактор тавышы минем өчен бер җыр шикелле генә ул. Иртәнге концерт тыңлыйсы урынга, шул трактор тавышын тыңлыйм мин,— диде Фәгыйлә апа көлеп.

Фәгыйлә апа, дүрт малай белән ирennән тол калып, берсеннән-берсе эшчән дүрт егет үстергән кеше. Нинди генә авырлыклар белән яшәмәсен, җорлыгын ташламады. Хәзер ул кече улы, килене, оныклары белән яши.

Фәгыйлә апа керү белән, әни дә әзерләнә башлады.

— Урман тамакны тиз ачтыра ул. Капкаларга берәр нәрсә алырга кирәк,— диде әни.— Аппак түти, син шикәр алдыңмы?

— Нигә шикәр, чәй алсагыз, конфетлар да бар бит,— дидем мин.

— Алдым, алдым,— диде Фәгыйлә апа.— Шикәре кырмыскаларга аның.

— Кырмыскаларга?..

— Әйдә, әйдә, урманга менгәч күрерсең әле...

Урман авылдан ерак түгел. Әзрәк күпертеп әйтсәң, бакча артында гына дисәң дә була.

— Сезнең бакча башында кукы үсә торган иде. Карыйк әле, быел кукыдан авыз да иткәнем юк,— диде Фәгыйлә апа.

Чынлап та, кукы шәп үскән быел. Бакча башындагы иске баз өстендә гөрләп үсеп утыра.

— Кара, монда кәҗә сакалы да бар икән, йолкыйбызмы?

— Юк, юк, тия күрмә, иренең чабырыр. Кукысын да зәңгелә качырырга гына ашыйбыз. Зәңгелә, кач, кач, Идел кич, кич...

Әни белән Фәгыйлә апа такмаклый-такмаклый кукы ашадылар. Мин дә алардан калышмадым, әлбәттә.

— Кайсы юлдан менәбез урманга, туры юлданмы, әллә елгаданмы,— диде әни.

— Елга буйлап чирәмнән меник әле, аякка йомшак булыр. Туры юлны сөргәннәр. Аның юлы юл гына идеме сиңа, ике машина кара-каршы үтәрлек иде, ярар, басу иткәннәр инде,— диде Фәгыйлә апа. — Җирне бер дә җәлләмиләр инде — басу уртасында да олы юл, басу кырыенда да... Нәрсә уйлап болай эшлиләрдер. Элек ат белән йөри торган тар гына юл булыр иде. Як-ягында ямь-яшел чирәм үсә торган иде. Кирәкмәс җирдән сукмак саба башласалар, йә бүрәнә сала торган идек, йә казык кагып куя торган иделәр. Юк инде ул элекке чаклар... Дөньясы машина белән тулган.

— Заманасы шундый,— диде әни.— Элеккене сөйләп кенә кайтара торган түгел. Урманга да машина, басуга да машина. Дүрт малаең дүртесе дә механизатор.

— Андый-мондый гына түгел, универсальный механизаторлар! — диде Фәгыйлә апа. — Тракторда да эшлиләр. Комбайнда да, Аллага шөкер.

— Фәгыйлә апа, ничек шулай дөрес итеп әйтергә өйрәндең ул «универсальный» дигән сүзне.

— Онысыгым өйрәтте. Улларымны мактый торган сүз булгач өйрәндем шул. Универмагка да охшап тора, анысы да бик таныш сүз инде. Районга гел барып торабыз бит. Ә теге «сал» дигәне анысы татарча инде. Әтиләре дә тракторист иде бит. Тракторда дүрт тәгәрмәч булган кебек, минем дә дүрт малаем булачак, ди торган иде мәрхүмем. Дүрт малае булды булуын, тик кечесенең тәпи йөргәнен күрмичә безне ятим итте шул... Фәгыйлә апа яулык почмагын күзенә тидереп алды.

...Елга буйлап бару бигрәк тә күңелле икән. Елга дигәч тә, сусыз елга ул. Бары тик урманнан агып чыккан кечкенә чиш-

мәләрдән җыелган суы гына урыны-урыны белән челтерәп ага. Кырыена ук килеп, үләннәрен ачып карамый торып, күренми дә.

— Карагыз әле бу елгадагы печәнне быел,— диде Фәгыйлә апа.

— Көтү кертмәсәләр, моннан бер кышлык печән әзерләргә була,— диде әни сузып, тау битләренә карап алганнан соң.

Кояш та шактый гына кыздыра башлады. Көн матур бүген. Урман чишмәсенең суы белән кулларны юдык, елга кырыеннан үги ана яфраклары җыйдык.

— Беләсезме, бу яфракны нигә үги ана яфрагы диләр? — дип сорады әни.

— Юк, ә нигә?

— Тотып кара әле. Бер ягы сап-салкын, ә икенче ягы җыпҗылы. Үги ана кәефе кебек.

— И күрде инде башлар! — диде Фәгыйлә апа, үги ана яфрагын капшап.— Ятимлекне дә, үги ана белән үсүне дә, ачлыкны да, сугышны да, өй тулы бала-чага белән таянычсыз калуны да күрдек...

Мин аны юатыр сүзләр таба алмыйм. Тик еламасын гына иде. Шуңа күрә мин нәрсәдер әйтергә дип авыз ачканчы, Фәгыйлә апа үзе үк сүзне икенчегә борды да куйды:

— Ходай бирде саулыкны! Син минем сүзләргә бик исең китеп карама. Шулай кердели дә чыктылы икәнлегемне беләсең бит. Аяк кына менә харап итеп куя шул... Апирасия кирәк моңа дигәннәр иде бүлнистә, риза булмадым әле. Анысына йөрәк җитми. Җәй җиттеме, бөтен им-том кырмыска, җир мае, бал корты... Файдасы тигән шикелле була тагы үзе...

Шулай сөйләнә-сөйләнә урманга менеп җиткәнебезне сизми дә калганбыз.

И урман! Бигрәк рәхәт шул һаваларың. Без үскәндә арасыннан җиләк җыеп йөргән яшь наратлар куе, чытырманлы урманга әйләнгән. Урман эченә керә торган сукмак кына ялтырап ята.

Беренче кырмыска оясына шушы сукмак белән барасы икән.

Әни белән Фәгыйлә апа өйдән алып чыккан шикәрләрен пышылдый-пышылдый кырмыска оясына куйдылар. Тик алар шикәренең кирәге дә юк монда, болай да кырмыскаларның алларыннан калганчы булган — оя өсте ап-ак шикәр!

— Карагыз әле, нигә шултикле шикәр монда? — дидем мин исем китеп.— Мондый хәлне күргәнем юк иде әле.

— Көненә ничә кеше, җәенә күпме кунак килә монда. Карчыкларның да савап аласы килә. Әгәр дә кырмыска оясына бер шакмак шикәр салсаң, туксан кешене туйдырганлык савабы була, ди.

Ай-һай дип уйладым мин, болай булгач бу рафинадның тарихыерактан башлана икән...

Фәгыйлә апа оекларын тиз-тиз салып, итәкләрен кыстырып куйды да авырта торган аягын кырмыска оясына күмәргә тотынды.

— Әнекәйләрем, ничек чыдыйсың? — дидем мин исләрем китеп.

— Мине тешләмиләр алар, хәерсезлер! Шикәр ашап бозылып беткәннәр. Исләре дә китми. Кара әле, ничек әкрен кыймылдыйлар!

Гадәттә, оясына килеп кагылдыңмы, кырмыскалар, мәш килеп, арлы-бирле йөгерә торган иделәр. Ә боларда шулхәтле сүлпәнлек, әйтерсең яннарына килүче де, ояларына кагылучы да юк.

— Нишләп тик торасың? — диде әни, кулың белән бәргәлә дә иснә! Шуның өчен мендек бит урманга!

— Берәрсен ялгыш үтерсәм, жәл бит...

— Үлмиләр алар, ияләнгәннәр инде. Аркаларыннан сөйгән кебек итеп кенә суккала син.

Мин кулымны кырмыска оясында әни әйткәнчә тоттым да, исним дип борыныма китерсәм...

— Бер дә исе юк бит моның! Ду китереп мактыйсыз...

— Кит лә,— диде әни. Өрәңге яфрагын өзеп алып ояга салды. Олы сары кырмыскалар, әрле-бирле килеп, ашыкмый гына бик эре кыяфәт белән яфракны сырып алган булдылар.

— Йә, хәзер иснә инде, бәлки, мин ис сизми башлаганмындыр,— дидем.

Әни дә аптырап калды. Әлеге яфракны Фәгыйлә апага сузды. Без өчәүләшеп бер-беребезгә карашып калдык.

— Исе беткән бит моның! Иснәп бетергәннәр! Кичә бер көтү Югары оч карчыклары менеп бара иде, шулар гына бозган бу кырмыскаларны!

— Кырмыскада да ис бетә икән,— диде Фәгыйлә апа, аягы буйлап югары үрмәләгән кырмыскаларны сыпыргалап.— Кая үрмәлисез, табанны тешләгез, табанны...

Фәгыйлә апа үзе бик җитди, ә кыяфәтенә карасаң... көлми түзәрлек түгел.

— Йә, булдымы инде, процедураң ничә минут булырга тиеш?

— Аны минутлап кем чутлаган! Чыдамым беткәнче тота идем башка чакта. Тешләмиләр бит! Тәмле тормыш бозган боларны. Кырмыска да ялкаулана икән. Кабат боларга дип шикәр алып мендем юк. Нәселләрен генә бозмасак ярар иде.

— Киттек болай булгач иске умарталыкка,— диде әни.— Анда мин генә белә торган бер урын бар.

Иске умарталыктагы кечкенә кырмыска оясында шикәрләр күренми. Кояш нурларына чумып утырган бу ояда безнең урманның барлык эшчән кырмыскалары җыелган, ахры. Оя янына килеп басуга тотындылар кайнашырга, әйтерсең ояларын икенче урынга күчерергә җыенганнар.

— Нинди зур аерма,— дидем мин.— Менә сиңа табигать!

— Шәп дәрес булды бу безгә,— диде әни.

Кырмыскалар белән эшне төгәлләгәннән соң, чирәмгә утырып алып тамак ялгыйк, дисәк, кырыебыздан гына бер кош пырылдап очып китте дә, якындагы агачка кунып, борчулы тавыш белән кычкырырга тотынды.

— Ялгыш утырдык, ахры, монда. Оясы бар мәллә, кара әле,— диде әни.

Үләннәрне ачып карасам, учка сыярлык кына бик матур кош оясы килеп чыкты. Эчендә дүрт күкәе дә бар.

— Күчеп утырыйк,— диештеләр әни белән Фәгыйлә апа.— Кошны куркытмыйк, суынмасын оясы. Йә ташлап китәр.

— Нинди кош микән бу, сандугач түгел микән? — дип сорадым.

— Юк, бу сандугач оясы түгел,— диде әни, ояга карап алганнан соң.— Сандугач күкәе язулы була.

— Ничек инде ул, язулы?

— Гарәпчә язулы. Иске китаплардагы кебек. Ә менә без наданнар булып чыктык әле. Кырмыскаларны бозганбыз, җирдәге ояның кайсы кошныкы икәнлеген белмибез. Менә кайда ул мәктәп-табигать!

Без икенче урынга күчеп утырдык. Тик минем тынгысыз карчыкларым, утырган җирләрен йолкып печән җыя башладылар.

— Күр әле быелгы печәнне, уңган да соң!

— И-и, урман! Элек бигрәк тә кадерле иде ул. Бер учма печән җыйдыртмыйлар иде, бер ягарлык утынга тилмергән чаклар бар иде. Уйласаң шаккатырлык инде, өеңә авып торырдай урман булсын да утынга тилмер инде. Менә нинди заманалар бар иде. Хәзер әнә өрлеккә салырдай бүрәнәләрне утынга турыйбыз. Юк, юк, кадерен белми башладык урманның... Син безнең печән йолкыганга карама. Эшсез утыра белмәү гадәте ул,— диде әни.— Монысын да урман артыбыздан, һәй, буш кул белән киттеләр, дип көлеп калмасын дип кенә җыябыз.Ул безне кадерли бит, безгә дә аның кадерен белергә кирәк...

Әйе шул, «кадер» төшенчәсен югалтып барабыз шикелле. Кая карама кадергә мохтаҗлык. Сирәкләнгән урман, яшелләгән югалткан авыл урамнары, юлыннан адашкан чишмәләр кадер көтеп, мөлдерәп карап торалар сыман.

# Кода килде

— Әй кызым, кода килеп китте бит әле безгә быел!

— И әни, ничәнче кат сөйлисең инде син аны миңа.

— Сөйләрсең дә! Кодаң шундый кеше булсын да, шаккатып сөйләрлек кенә итеп очраш инде гомереңдә...

— Тормыш шундый булгач...

— Ярый, анысына үпкәләрлек түгел, Аллага шөкер! Әле сөйлисем килгәнен синең ишеткәнең юк. Син бит коданың килүен дә китүен генә беләсең, бер тамаша булды бит ул! Ул көнне... юк, нишләп ул көнне генә булсын, бер ел алдан башланды ул көн... Бер ел алдан... Апрель аенда әтиеңне җирләдек...

— Әни!

— Шулхәтле ятимлекне, шулхәтле ялгызлыкны тоярга Ходай язмасын... Әтиеңне җирләгәч, дөнья тарайды, караңгыланды минем өчен... Авызымда — аш, күземдә — яшь ... Ятсам да күз алдымда, торсам да... кайтып тордыгыз берәм-берәм, рәхмәт анысына... Авырган чагында барыгыз да кайтып бигрәк тә сөендергән идегез әтиегезне. Хәтерлисеңме, сез кайткач, урыныннан торып та утырган иде.

— Хәтерлим... беләсеңме, әни, ул нәрсә дигән иде безгә ул вакытта?

— Тагы бер кат сөйлә әле...

— Балалар... бәләкәй чагыгыздагы кебек өй уртасында барыгыз да, әүмәкләшеп, бер уйнагыз әле, дигән иде.

— Сирәк җыелышасыз шул, сирәк. Тәрәзәдән күзен алмый көтә иде. Ә монда бөтенегез бергә бит, алтыгыз да!

— Без бәләкәй чакта сыек чыбык матчадан төшмәде инде. Талаша башласак, барыбызны да почмак саен өләшә иде.

— Ул чыбык истә калган синең, ә сукканын хәтерлисеңме соң?

— Юк, бер тапкыр да кул күтәреп сукканы булмады.

— Тәрбия чыбыгы иде ул, тәрбия! Әтиегез әүмәкләшеп уйнагыз, дигәч, нәрсә эшләдегез, оныттым да инде?

— Син нәрсә, әни! Миңа кырык яшь, Әлфиягә утыз сигез, Миңнуллага утыз биш, Илфатка егерме тугыз, Хәлимгә егерме җиде, Алфирага егерме! Әнә шулар әүмәкләшә башласа!

— Әтиегезнең сезне балалар итеп күрәсе килгәндер шул.

— Көлештек барыбыз да әйткән сүзеннән, ул да елмайгандай итте.

— Хәле авыр иде шул. Үләр, үзелер, күрми калырсыз дип, барыгызны да чакырган идек ул чакта. Сез кайтып китү дәва булып, тагы ике ай торды бит.

— Нәкъ ике ай, көнгә көн.

— Озатырга бөтен авыл килгән иде...

— Әнә кода килгәч тә, әтиегез кайткан кебек булды. Анда да бөтен авыл җыелган иде. Ул елны печән бик күп булган иде урманда.

— Әни, нишләп әле берсен башлыйсың, берсен ташлыйсың дигәндәй...

— Һаман шул бер сүз инде ул, очына гына чыга алмыйм. Печән өешергә дип, күрше Сәвия дә барган иде. Җәйге эш кайнап торган чакта вакыт табып барды, рәхмәт төшсен.

— Соң?

— Ә инде Сәвиягә утынга турарга дип, капка төпләренә каен керәҗе кайтарып аудардылар. Хәлимгә әйттем, улым, турап бир әле Сәвиягә шул утынны, дидем. Бәйрәм ашы каракаршы бит.

— Соң?

— Нәрсә дисен, тураса да турый, турамаса да турый. «Дружба»сы бар бит аның. Бер-береңә ярдәм итеп яшәмәсәң, күршелекнең ни хаҗәте бар. Юк икән, ул көнне генә турый алмады, әллә яңгыр яуды, әллә башка эш булды. Ул көнне, бөтен урамны каплап, калды теге ботаклары чатаклы өрлеккә салырдай каен керәҗләре Сәвияләр турында. Әле икенче көнне дә Хәлимнең кулы җитмәс иде, болай булды... Төнлә белән Рәшит тракторында олы юлга малаен каршы алырга чыккан чакта, теге утынга дигән агачның берсен эләктереп, байтак кына өстерәгән, караңгы бит, күрмәгән инде... Ул агач өстерәлү бер нәрсә, аңар ияреп, өй каршысындагы рәшәткә дә киткән, рәшәткәгә ияреп, ничә еллар буе балаларның авыз суын китереп, ел саен манчыгандай кызыл алма сырып ала торган алмагач та төбе-тамыры белән килеп чыккан. Ярый әле абайлап калган, шушы өемгә Сәвиянең өе дә эләккән булса, Рәшиткә өй салып бирәсе була иде, Ходай саклаган.

Икенче көнне таң белән бу хәлне күрдек тә, әйтәм Хәлимгә, улым, кисеп бир Сәвиянең утыннарын, эш олыга киткәнче, дим. Хәлим әйтә, мин как раз шунда чыгарга гына тора идем, эшләпәмне таба алмыйм, кая микән, ди. Мин әйтәм, нәрсәгә сиңа ул эшләпә, атаңның кәләпүшен ки әле, синнән башка аны кияр кеше юк бит, дим. Хәлим көзге каршысына килеп, менә шул кәләпүшне генә киям дип торганда, күзләрен тасырайтып килен килеп керде ишегалдыннан.

— Хәлим! Бар әле, ишегалдына перси белән әллә нинди кешеләр керде, тагы сиңа штраф салырга йөриләр микән,— ди.

— Калхуз персидәтелен шулай «перси» дип йөртәләр алар. Штраф дигәннән, Хәлим колхозда түгел бит хәзер. Шуңа күрә бакча сукалатырга булса, аларча, сука чираты безгә иң соңыннан җитәргә тиеш. Атаң мескен дә, колхозда бер генә көн калдырмыйча эшләсә дә, сука чиратын көтеп алырга түземлеге

җитмичә, бакчаны көрәк белән казый иде. Шул авырлыклар алып киткәндер инде... Хәлим колхоз сукасына ялынып тормады, суканы үзе ясады да кеше чиратында сукалап та чыкты. Шуңа персинең ачуы чыккан ди, шуңа штраф салам, дип йөри дип әйттеләр анысын. Мин әйтәм, туктагыз әле, бакча кайгысы түгелдер, колхоз бәрәңгесен утыртырга, бәрәңге ярырга дип, миңа эшкә әйтергә килгәндер дип, үзем чыктым алар каршысына. Чыксам, ике-өч чибәр кеше басып тора, өсләрендә парачкы кәчтүм, муеннарында гластук, атаң башы, киенеп куя инде урындагы кеше, карап туя алмассың.

— Апа, ни хәлең бар?— ди персидәтел.

— Аллага шөкер, мин әйтәм. Үзем эчемнән генә, шулай ул, безнең ише пенсионерларсыз барыбер эшегез бармый, өйгә чаклы килеп җиттеңме, дип уйлап куйдым.

— Апа,— ди бу,— сезнең Мостафа дигән кодагыз бар икән Уфада, безгә хәбәр иттеләр, бүген ул сезгә килергә тиеш икән, шуны беләсезме? — ди.

— Бик әйбәт, мин әйтәм, килсен! Нишләп соң аны сезнең аша әйттерәләр, туры үземә генә килмәгәннәр, эш вакытында сезне йөртәләр дим.

— Апа,— ди,— зур кеше икән сезнең кода, нишләп аны башта ук әйтмәгән идегез? — ди бу.

— Кайсы баштан? — мин әйтәм.

— Бакча сукалаткан чакта и таки дали,— ди бу.

— Шулай инде, мин әйтәм, ятим карчыкка яклаучысыз булмый икән, дим, минем ирем дә шушы колхозда эшләп, яшәп, шушы өйдә торган кеше, дим.

— Апа, ярар инде, биредә ят кешеләр дә бар бит, безне гел бетереп ташлама,— ди.— Кунак каршы алырлык хәстәрләрегез бармы соң? — ди.

— Аллага шөкер, бар нәрсәм дә бар, килсен генә, мин әйтәм, күптән очрашканыбыз юк иде, дим.

— Итең бармы? Маең бармы?

— Коданы сыйларлык та сый тапмагач, ничу яшәргә бу дөнья йөзендә тере кешегә сан булып. Кайчан киләсе ди?

— Бер-ике сәгатьтән...

— Алай булгач, аш салыйм... озын сүз бозау имезә...

— Ярдәмчеләр кирәкме? − дип сорый бу.

— Булса, килсеннәр, эш җитәрлек булыр, болай булгач...

— Шул сөйләшүдән соң аш салдым. Табын әзерләргә тотындык. Хәлим тагы кисә алмый калды теге бүрәнәне. Анысы ишегалды себерергә тотынды. Һаман шул Сәвия инде, рәхмәт төшкере! Йөгереп килеп керде. Бигрәк илгәзәк җан инде. Нинди эш бар, дип керә тора. Персидәтел аны, урам буйлап карап кайт әле, урам ямен җибәреп берәрсенең ыштан балагы коймада эленеп тормый микән, дип йөгертте. Сәвия койма башларын

карап кайтканчы, Рәшит абыең бульдозеры белән урамны тигезләп чыкты. Язгы пычрактан урам кантар-кантар, кеше генәме сиңа, ат та йөри алмаслык хәлгә килгән иде. Инде, мин әйтәм, шушы урамны тигезләтер өчен авылга кунак килүен көтәргә кирәк микәнни? дим. Урамыбыз чирәм генә иде сез үскәндә. Тракторлар белән бетерделәр урамны. Шул арада Кирмән очлары менеп җиткән. «Мәүҗидә, Суык урамда торсаң да, туган урамың Кирмән очы бит, әйт әле персидәтелгә, безнең урамны да тигезләсеннәр әле», дип. Килен йөгерде үзләренең киленнәренә. Аны да ярдәмгә алып менде. Мәш киләбез. Өй тулы хатын кыз! Киленнең энесе дә менеп җитте. «Җизни, нәрсә эшлим?» — дип уаланып тора. Хәлим әллә кайчаннан бирле яңа болдыр ясыйм дип тора иде, кода килү сәбәп белән, Хәлим каенише белән икесе иске болдырны төбе-тамыры белән куптарып алдылар да утынлыкка илтеп ыргыттылар. Ул арада болдыр ясамадылар инде. Кода киткәч ясалды бу яңасы. Кода килмәгән булса, булмый иде! Уен эш түгел бит, ни гомердә яраткан кодаң бусагаңны атлап керә икән, без дә сынатмаска кирәк!

Озын итеп табын кордык олы якка. Килен мунча ягып җибәрде. Сәвия салат-малат ясый башлады. Урамга тулып халык чыкты. Бервакытны асфальт кебек тип-тигез урамнан, мин сиңа әйтим, кара «Волга» машинасы, тузаннар туздырып, капка төбенә килеп туктамасынмы! Өскә менә шушы күлмәкне кигән идем. Үзе атлас, үзе ялтыравыклы, бу кияү бүләге иде, әллә ничә еллар сандык төбендә яткырып саклаган идем. Кода алдында да кияргә насыйп булды. Калган эшне киленгә тапшырдым. Табын тирәсенә җыелыштык. Кода әйтә, кодагый белән рәттән утырам, ди. Тәки утыртты шул. Ул үзе генә булса бер хәл, кара машина эче тулы кеше булды анда. Барысы да ят кешеләр дисәм, авызын ерып, кулын сузып, үзебезнең авылныкы язучы Шаһинур да килеп чыкты. Ашарга утыргач, авызым бик оялган иде, коданың тәмләп ашавын күргәч, үзем дә берике кашык кабып куйдым. Шул аш белән страмга да калдым бит кода алдында. Токмач ягын киленгә тапшырган идем. Ашыгыч дип, ул токмач басып тормаган, син җибәргән теге импыртный шүре токмачны гына салган да җибәргән. Кода бер-ике кашык капты да:

— Кодагый, синең килен минекенә караганда уңганрак икән, токмач саен тишек тә тишеп чыгарга өлгергән,— ди.

Көлештеләр барысы да, аның шаяртканын аңладылар инде, укыган кешеләр бит. Мин генә көләргәме, көлмәскәме дип торам. Шултикле кеше алдында авыз күтәреп көлеп утыруы да уңайсыз бит. Безнең кода шикелле дөньяда юк! Дөресен дә әйтте, үпкәләтмәде дә. Килен ясамаган икәнен күреп тора бит ул. Күрмәгән нәрсәсе түгел. Киленгә дә әйбәт дәрес булды,

олы кунак алдына кибет токмачыннан аш куярга кирәкми, димәк. Шулай көлеп утырганда, берсе кәртечкәгә дә төшереп алган. Хат белән безгә килеп төште ул кәртечкәләр. Ничек туры китергән диген! Шул кәртечкәгә карасам, коданың сүзләре искә төшә дә рәхәтләнеп көләм, ул чакта оялган булсам да. Ашлар ашап, чәйләр эчкәннән соң, кода әйтә, коданың каберен дә зиярәт итеп кайтыйк, ди. Шул сүзне ишетүгә, персидәтелнең авызы бер карыш ачылып калды. Нәрсә булды микән дисәм: «Ул урамны тигезләтмәгән идек!»— дип пышылдый бу миңа. Ничек кенә матурлап күрсәтергә тырышса да, барып чыкмады бит. Кода аның урамына карыймы инде. Колхозга тикшерүче булып килмәгән бит ул, безгә кунак булып килгән.

Аларны анда Хәлим белән Шаһинур алып китте. Мин иярмәдем. Елап калдым артларыннан.

Аннан соң яңадан өйгә кайттылар. Мунчалар җитешкән булса да, мунча кереп тормады кода. Тагы да барасы җирләре бар икән. Менә шушы китабын безгә истәлеккә дип, бик матур сүзләр язып калдырды. Ә менә бу шәлне бүләк итеп бирде. Ничәмә айлар кайгы белән йөргән җаныма коданың килеп китүе бер җан азыгы булды. Ходай Тәгалә озын гомер насыйп итсен үзенә. Балаларының рәхәтен күрсен, матур-матур китаплар язсын дип теләп торам. Мәңге хәер-фатыйха аңар.

## Каз утырттым

Берничә ел инде каз нәселен йортыма керткәнем булмады. Бәхет сынап карыйсым килде быел. Каз өмәләре ясармын дип, кызышып кына тотынган идем. Бәхет латарый, диләр, дөрес сүз ул. Латарый дигәннән, бөтен гәзитенә бер нумиры уйный, анысына да күршеләр рәхәтләнә. Каздан бәхет юк минем, Ходаның хикмәте. Быелгысын әйтәм әле, ике оя иткән булдым җәфаларны! Ике ояга биш бәбкә чыкты. Аның да бәбкәләре бәбкә кебек кенәме сиңа, чистый иза чиктем мин алар белән. Өлешеңә тигән картаң, тешли-тешли тартасың дигәндәй, нишлисең? Мал иясенә охшамаса, харам була, диләр, шушы икән ул. Ата казы яман усал булды быел! Нәрсәдән килә микән ул усаллык, малайкаем? Кояш ахтифлыгы да, кояш ахтифлыгы, диләр, казларга да тиде, ахры, быел. Ахтиф нәрсә шундый инде ул, белеп сөйлим мин аны, белмәсәм әйтмәс идем. Әнә безнең «ахтиф» Һаҗәр катнашкан нәрсәнең бөтенесе дә усаллык белән бетә. Шуның күзе төштеме, йә бакчаңны кисәләр, йә печәнеңне алып чыгалар, йә штраф түләтәләр. Ну, түлке инде Һаҗәрне ата каз турыдан үткәрми! Ыжгырып барып ябыша!

«Сезнең ата казыгыз этегез белән бертуган, ахрысы, бик ахтифланып киткән, чылбырга утыртырга кирәк!» — ди Һаҗәр. «И-и, Һаҗәр! Ахтиф, ахтиф дип, чылбырга утыртырга дисәң, ата каздан башка да ахтифлар җитәрлек безнең авылда! — мин әйтәм.— Син үзең дә ата каздан кимен куймыйсың бит!» «Мин хөкүмәт кешесе, закунчылыкны түкми-чәчми саклап, халыкка төгәл җиткергәндә дә аңлап бетермисез әле. Яз җиттеме, хуҗалык бакчаларын киңәйтәләр, сутый агачы күтәреп йөреп, хәл калмый. Ел саен бакча үлчибез, ел саен кисәбез, коймасын күчертәбез, тагы үлчибез, әпәт нурмыдан артык!» «Син аптырыйсыңмы аңар, мин гаҗәпләнимме! Әле син үлчәгән кеше булып шаккаткансың. Ә мин синең артыңнан йөреп, син санаган сутыйларны дөресләгән, нәрсә уйларга тиеш. Җир үсми бит инде ул! Син кисә торгач, бакча башына салган мунчам басуга килеп чыкты инде. Мунчасы да колхозныкы хәзер дип әйтерсең әле син! Быел теләсә нишләтегез! Читәнемне күчерәсем юк! Каз бәбкәләре йөртергә урын кирәк, каз утырттым быел. Трактор белән урам чирәмен бетердегез, бәбкә үләне үсәрлек тә урын калмады урамда!» Әнә шулай дип сөйләштем тегенең белән. Теләсә нәрсә дисен!

Каз үстерү авырайды бу елларда, авырайды.

Каздан болай да бәхетем юк минем. Кул арты китте. Бер елны шулай бер казымны Югары оч хатынына саткан идем. Кем икәнлеген сорама да, әйтмим, сүзе булмасын, иллә дә кул арты әшәке икән. Шуннан соң ничә еллар каздан уңмадым. И-и, уңмадым да соң! Ярар инде анысы. Миндә инде җыен кеше ышанмаслык хәлләр. Бер генә тамчы да уйлап чыгарганым юк минем. Кеше ышанмаслык хәлне чын булса да сөйләмә, диләр, сөйләми ничек түзәргә кирәк ди! Бер башлагач сөйлим инде, ышанмасагыз ышанмассыз, кем белә, бәлки, дөнья булгач бар да була, ник булмасын дип, минем сүзне җөпләүчеләр дә табылыр.

Шулай каз утырттым бер елны. Кайсы елда икәнлеге дә бик истә, кибетне яшен суккан иде ул елны. Шуннан бирле кибетне ел саен яшен суга башлады, Ходайның хикмәте! Тик ул елны агитбригада белән артистлар да килгән иде. Хәтерлисең, син дә хәтерлисең аны! Онытылырлык булмады бит ул! Агитбригада башлыгы мәрхүм Юныс Фарсин да исән иде әле ул чакта. Кич белән клубта яшен тизлегендә җыр чыгарып, сәхнәдән җырлаган иде Фарсин.

Урак өсләре булса да,
Яңгыр каты йоклата.
Яшен суккан кибетләрдә
Булмый ырастырата!

Әнә шул ел инде. Кибет яна башлагач, артистларның берсе, кибет тәрәзәсен тибеп ватып, акчаларны коткарып калган иде.

Аягын пыяла кисеп, аксаклап уйнады сәхнәдә. Әнә шул ел! Шуннан соң, Ходайның хикмәте, кибетне ел саен яшен суга, туктаганы юк әле, тик менә артистлар гына килми башлады. Безнең авылны уратып узалар хәзер. Соң, Галиятти нахак бәла таккан аларга, яшенне сез генә алып килдегез, дип, сәхнәгә менеп кычкырган бит! Тиле карчык! Ул вакытта беләсең бит инде. Агитбригадада басуда да концерт күрсәтә иде, «Яшен» дип аталган гәзит тә чыгарып эләләр иде. Шул инде, артистлар амбарлар янына «Яшен» дигән гәзит чыгарып элгәннәр иде, «Көн батырлары»н мактап. Артистлар «Яшен» чыгарганны ишетеп калган Галиятти, кибетне дә шул яшен суккан дип аңлаган. Менә наданлык кая илтә! Үпкәләп киткәннәр артистлар. Шуннан бирле ник берсе күренсен. «Үзәк хуҗалыкта», «үзәк хуҗалыкта» диләр дә безнең бәләкәй авылга кереп тору юк. Шәп уйныйлар иде. Шәһәрдән булсалар да белеп сөйлиләр иде. Хәзер артистлар да бетте, кешеләр дә бетте, җир дә картайды... Күңел юаткычы ярый әле мал-туар арасында кайнашырга җегәр калды азрак. Әнә шул елны утырткан идем ул казларны. И-и, без картаймый кем картайсын! Ярый әле хәтер бар. Утырасың да уйлыйсың, елыйсың да көләсең. Дөньяны алып баруы авыр булса да, гомер тиз үтә шул. Көннәре ел кебек озын булганы бар, тик еллар минутлар кебек үтә дә китә, үтә дә китә...

Тукта әле, бер тотынгач, казлар маҗарасын сөйләп бетерми булмас. Беренче тапкыр каз утыртуым әнә шул елны булды. Әле утыртканчы кемнән генә алыйм микән дип, байтак кына белештем ул казны. Сатучы юк. Кеше кул арты китүдән курка, шуңа күрә ишле оя үстергән кеше сатмый бездә казны. Ике-өч бәбкә үстергәннәр генә сата. Уйлаган идем аны, үз өендә ике бәбкә үстергәнне, мине мантытамы соң бу каз дип, уйлаганым алдыма килде, дөрес икән бу сүзләр! Каз үзе матур иде. Башындагы тупыйгы, муенындагы алкалары гына ни тора! Без белгән казларга да охшамаган нәрсә иде бу каз.

Саткан чакта ук әйтеп бирде сатучысы. Сорама, сорама, исемен дә әйтмим, күптән гүр иясе, авыр туфрагы җиңел булсын, рәнҗеп ятмасын, узган-беткән, ахирәт гамәле түгел, гыйбрәт өчен генә сөйлим. Саткан чакта әйтеп бирде, Мәүҗидә, диде, казың төрле-төрле зурлыктагы күкәйләр салыр, берсе дә каз күкәенә охшамас, аптырама, бер көтү бәбкәң булыр, тик, зинһар өчен, кешегә күрсәтә күрмә, күз тидерерсең, диде. Күз тиюнең нәрсә икәнлеген бик беләм дә бит, тик сер саклаучысы мин түгел шул. Каз беренче күкәен салды, карыйм — зур да түгел, кечкенә дә түгел. Шаккатырлык бернәрсәсе дә юк, нишләп күрсәтим, күрсәтмәдем бер кешегә дә. Ходайның рәхмәте, икенчесен дә салды, күрәсекәйләрең булса!

Менә шушылай яшь бала башыдай, аз булмас, беренче кү-

кәе үрдәкнеке кебек кенә калды да куйды монысы янында. Йөгердем күршем Айсылуттигә. Яшь чагым, үземә күрә, минем кызым кияү күргән нәрсәме дигәндәй, каз утыртканым юк иде әле ул вакытка чаклы.

— Айсылутти! Кереп кенә кара әле, бездә бер хәтәр бар! — дим.

— Ай Аллам, нәрсә булды, әллә берәрсе пештеме? — ди бу.

— Юк ла, мин әйтәм, сөйләп кенә аңлата торган нәрсә түгел, әйдә әле безгә!

Казны ашатырга чыгарган мәл иде, оясын каплаштырып чыгып киткән булган, саламнарын ачтым да күрсәттем моңар теге күкәйне.

— Мондый хәлне күргәнең бар идеме?

— Нинди хәлне, Мәүҗидә?

— Күкәйләрне кара әле, күкәйләрне...

— Нәрсә булган? Бик әйбәт күкәйләр. Ике генә икән, әллә өзелеп йөриме?

— Айсылутти! Икесе ике төрле бит! Нишләп аермасын күрмисең!

— Нәрсә сөйлисең, Мәүҗидә, нишләп ике төрле булсын? Оясы да аулак урында икән...

— Айсылуттикәем! Берсе олы, берсе бәләкәй бит!

— Олы да түгел, бәләкәй дә түгел, тап-таман, каз күкәе шундый була инде ул.

— Әстәгафируллаһ! Тотып кына кара әле, күзең күрмәсә кулың тояр, икесе ике төрле бит!

— Тотмыйм да, нитмим дә! Икесе дә бертөрле! Бер аермасы да юк. Юк-бар белән эчеңне пошырма. Каз оясын гел кармалап тормыйлар аны, йә казның гайрәтен чигерерсең. Кая, чыгыйм әле, эшем кала...

Менә сиңа олы кеше! Менә сиңа күрше-киңәшче! Ачуым килде, тагы кемгә күрсәтим, күңел суынды. Чынлап та бертигезләр мәллә соң. Һай, башны бутады бу карчык. Әй, нәрсә аңласын соң ул! Көненә биш тапкыр намазлыгын күтәреп, «Кыйбла кайсы якта бүген?» дип кергән кешедән киңәш сораган, мин юләр!

Шулай итеп, су буендагы чуерташлар сыман, төрле-төрле зурлыктагы биш-алты күкәй салды да утырды бу каз. Көтәбез, көтәбез... Бөтен өй эчебез белән җан атып көтсәк тә, бәбкәләр чыкмады теге күкәйләрдән. Казның хуҗасына бардым, шулай, шулай, мин әйтәм, нишлим микән, синең дә шулай булган идеме, дим.

— Булмаса әйтеп бирмәс идем, кешегә генә күрсәткәнсең, хараплар гына иткәнсең, интекмә инде, эш узган,— диде Миңсылу карчык. Әй, исемен дә әйттердегез инде. Нишлим, тукта мин әйтәм, көткән өлешлек, бу күкәйләрнең эчендә нәрсә барын мин белергә тиеш бит инде дип ватып карадым тегеләр-

не. Күрәсекәйләрең булса! Син сөйләсәң, мин ышанмас идем, үз күзләрем белән күрдем шул: һәрбер күкәйдә икешәр, өчәр бәбкә буласы булган икән. Теге, мескен каз, өч сарылы, ике сарылы күкәйләр салып азапланган икән. Шулай итеп, бишалты күкәйдән унбишкә якын бәбкә чыгасы иде дә бит, күз тиеп кенә харап булдылар. Менә нинди хәлләр була ул дөньяда. Ул вакытта кояш та болай ук ахтиф түгел иде, кешеләр генә «ахтиф» кушаматы белән йөриләр иде. Ә менә быелгысы, бер башлагач сөйләп бетерим инде, болай булды. Мендәрләрем дә искереп бара, оныкларым да туып тора, каз өмәләре дә сагындыра дип, ике оя каз калдырдым. Ике ояга бер ата каз да алдым. Шуның инде бер генә дә миһербаны юк, ыслый да килеп ябыша, ыслый да килеп ябыша! Ана казлар утыра башлагач кына, ничектер моңсуланып, юашланып калган сымак булды. Тегеләре утыралар мескенкәйләр, өйдә бала-чагага көн юк. Бәбкәләрне томаландырасыз, дип, тыннарын да чыгармый шып итеп тотам. Ишегалдында ана казларны көтеп, үрсәләнеп йөри торгач ата каз да ябыгып бетте. Тегеләрнең ашарга чыкканнарын көтеп ала алмый, баскыч яныннан китми. Ялгызлык авыр нәрсә шул ул. Хайван булып хайван да шулай бетәшсен әле. Кешегә ни кала? Ә инде тегеләрен чыгаргач, монысы нишләр микән дип, юри карап торам. Әй муенын сузып, каңгылдап килгән була, әй сөенгән була! Аннан соң тотына тыпыр-тыпыр биергә! Тамаша инде! Ә тегеләре менә бит бала нишләтә, хаптыр-хоптыр бер-ике кабалармы-юкмы, күкәйләр суына торгандыр, керик булмаса дигәндәй, баскыч төбеннән китми, өй ишегеннән күзләрен алмыйлар.

Ләкин тора-бара ана казларны туйдырды бу күкәй өстендә утыру. Берсе гел азды. Ата каз белән нәзакәтле итеп кенә, башын кыеклатып, әкрен генә басып, түбән карап исәнләшә. «Әллә йөреп киләбезме азрак» дигән кыяфәт чыгарып, бакча капкасына ымлый. Тегесе дә аңлап тора бит, каһәр, бии башлаган җиреннән шып туктый да, «Син шулай дисеңме, га-га-га, әйдә булмаса, мунча артларыннан бер әйләнеп төшик» дигән сымак, салмак кына атлап, ана казга иярә. Икенче ана каз канатларын киң итеп җәеп, бер җилпенеп ала да «карагыз аны, озак юанмагыз» дигән шикелле бер генә тапкыр «кый-гак» дип моңсулатып кычкырып куя да, кая, ишекне кайсыгыз ача, күкәйләрем суына торгандыр дип, өй ишегенә килә.

Ә тегеләре җаным, әйтерсең эшләре беткән, әй йөгерәләр бакча башына, әй ашыгалар. Тукта әле, мин әйтәм, сыныйм әле боларны, озак йөрерләр микән, дим. Дөньяларын оныттылар, беләсекәйләрең килсә. Бәбкә кайгылары юк боларда. Чыбыклап куып алып кайттым үзләрен. Аерып ала алмый алҗып беттем. Оясына кертеп утырткач кына, азрак тынычланды. Шулай итеп, башларын чистый җүләрлеккә салдылар.

Инде шул йөремсәк казымның бәбкәләре борынлый алмый гына бит. Пипелдәшкән дә сымак булалар, тавышлары бар, күкәйләрен тишеп чыгарга һич кенә дә көчләре җитми мескенкәйләрнең. Әллә ана җылысы җитмәде инде. Жәлке бит, бисмилламны әйттем дә, әкрен генә күкәйләрне әрчеп, бәбкәләрен якты дөньяга чыгарыйм дисәм... сиңа ялган, миңа чын, күрәсекәйләрең булса, томшыгының өсте гел юк. Кырыйга кәкрәеп чыккан. Кешедә булса куян ирен, диярләр иде. Шуңа күрә күкәй кабыгын тишәргә интегеп ята икән, мескенем. Нәрсәдән була микән шундый гариплек? Кояш ахтифлыгы дисәң инде, каз томшыгына да кагылмый торгандыр дим. Ата-анасы карап җиткерми генә гарип итте шул бәбкәләремне. Ояларында кайгылары булмады. Хайван шундый булганны, кешедә шундый хәл ничек булмасын диген. Тегенең баласы болай булган, моның баласы тегеләй булган, дип сөйлиләр бит радиодан да. Әллә теләгән ашы булды микән бу казның, бакча башына юкка гына йөрмәде микән, дип тә уйлыйм хәзер. Ничек кенә уйласам да, бик заманча булып чыкты безнең ул каз. Шул гарип булып туган ике бәбкәсен яратмый гына бит! Үзенеке итеп күрәсе килми, хәерсез! Җим сипсәм, ашаттырмый, ялгаш яныннан куа, чукый! Менә күрәсең булса. Тегеләрне аерып ашата башладым. Савытны тутырып салсаң гына, ашый алалар ризыкны да. Болай җирдән чемчекләп йөрү юк та юк инде. Үлән дә йолкый алмый мескенкәйләрем. Суны да башларын кыеклатып кына эчәләр. Ничек кенә булмасын, кеше иттем боларны. Канатлар чыгарып, үсеп җитсәләр дә, ятимлекләре күренеп тора шуларның. Анасы һаман да онытмый аларның гарип икәнлеген. Кысрыклап чукый! Шулай итеп, бик чукый торгач, гел канат каурыйлары ныгый башлаган, ашарга өйрәнгән бер бәбкәсен чукып үтерде бит! Күрми калдым шул... Ул кызгануларым, ул җәлләүләрем. Кулыма алдым да еладым. Шуннан соң ата каз янына килдем дә, бәбкәсен аның алдына куеп: «Менә кара, хатының нәрсә эшләде, үз баласының башына үзе җитте»,— дидем. Нишләр микән, мин әйтәм. Күрәсекәйләрең булса! Үле бәбкәсен күрүгә ата каз «ка-ка-ка» дип шаккатып торды да артка таба чүгә-чүгә китте... Монысына нәрсә булды инде дип уйларга өлгермәдем, канатларын сәлперәйтеп, башарканчык авып та төште! Сулар сипкәләп аңына китердем. Көне буе кара кайгы эчендә йөрде ата каз. Усал булса да, йомшак күңелле булып чыкты үзе.

Каз үстерү авыр нәрсә инде. Тик күңеллелеге ни тора! Кеше рәтендә капкаңны киң итеп ачып, «дил-дил-дил» дип, казларыңны урамга чыгарасың, пумала башлы таяк белән куып, су буена әкрен генә озатасың. Каз өмәләреннән соң каурыйларын чишмә юлына сибеп, икенче елга да су юллары тулып өйгә кайтырлык бәбкәләр булсын, дип телисең.

Дөрес, безнең ише карчык-корчыклар чебешләрне инкубатордан алабыз. Хәзер инде үрдәк бәбкәләрен лампочка җылысында чыгаралар. Әле каз бәбкәләрен дә чыгара торган инкубаторлар бар, дип сөйлиләр. Дөрес сүз микән ул? Тик ул каз бәбкәләрен кемгә ияртеп төшерерсең су буена? Үз баласын чукыган казга ияртәсеңме аны, тавыкка ияртәсеңме? Юк инде, каз, каз инде ул, өйдә үзең карап чыгарганга җитми! Хәзер язларны көтәм, тагы ике оя каз калдырдым.

## Әти

Харис абый балаларга каты булды. Беркайчан да алдына утыртып сөймәде, ягымлы сүзләр әйтмәде. Гомумән, аз сүзле кырыс кеше иде. Шулай да аның иң күп сүзле, иң ягымлы, иң йомшак куллы чагын ике кыз бик яхшы хәтерлиләр. Шушы бер көндә булган вакыйга аларга этиләре турында аның бала җанлы, иң якын кеше икәнлеген сөйләү өчен, балачакның бер матур хатирәсе булып калды.

...Ул көнне Харис абыйны өй күтәрү өмәсенә чакырдылар. Язның бер көне елны туйдыра дигән чакларның берсе иде ул. Өйдә бакча эшләренең, басуда басу эшләренең гөрләп торган чагы. Ул көнне Харис абый бригадирдан ат та бирмисез, сука да юк, миңа чират килеп җиткәнче бәрәңге чәчәк атар вакыт килеп җитәчәк дип, бакчасын инде көрәк белән казый башлар өчен бер генә көн эштән сорап калган иде. Аннары ат белән сукалау ат белән сукалау инде ул. Өйрәнмәгән ул аңар. Бу кызыл балчыклы бакчаны кул белән казысаң да бик таманга килә әле. Былтыр күршеләре ат белән сукалатып карадылар да соң, әнә нәрсә килеп чыкты! Әле нинди бакчаны диген! Балчыгын ипигә ягып ашарсың! Гел орынып кына торган бакча булса да, аралары ызан белән генә бүленгән димәссең. Боларда чем-кара балчык, Харис абый бакчасында ике әвәләсәң ташка әйләнә торган кып-кызыл балчык. Юк, юк, Харис абый бик кадерли бакчасын. Тиресен дә чыгара, көлен дә сибә. Тик хикмәт анда түгел. Чөнки Харис абыйларның бакчасы чак кына үрдәрәк, ә күршеләре — Борһан абыйларныкы — уйсурак җирдә. Кар сулары, гөрләвекләр, шәбәеп яуган җәйге яңгырлар Харис абыйның тиресләр белән ашлаган җирен юып кына төшерәләр дә лып итеп Борһан абыйның бакчасына сеңдерәләр. Менә шул ташу сулары да гаепле инде ике бакча арасында буразналар киңәюенә дә, ике күршене ямьсезләнер хәлгә китерүдә дә. Харис абый чарасыз иде. Бер тапкыр ике арага читән дә корып караган булды. Ичмасам, туфрагы ишелмәсен, имеш. Ләкин икенче көнне караса, ике арадагы читән сүтелеп өелгән.

Ә инде аның ишелә башлаган бакчасы, байтак кына күршеләр ягына шуышкан булып чыкты. Җитмәсә, күршесе ишелгән балчыкны көрәкләп түтәлләргә бүлеп йөри.

— Син күрше, ачуланма инде,— диде ул тыныч кына. Сезнең бакча болай да бүсерле, китәсе җирне читән белән генә тотудан күп файда тапмассың. Аның каравы безнең базга су төшә. Бер рәхәтнең бер михнәте дигәндәй. Уйсу җирнең шул бит инде. Алай-болай гына түгел, идән сайгакларын күтәрә шул су! Андый хәл синең төшеңә дә кергәне юк. Төшеңә керсә, идән астында кычкырган гөберле бакалар куркытып уятыр иде.

Харис абыйның мондый «фәнни» аңлатманы гомерендә дә ишеткәне юк иде. Ул сүз куертып тормады, күршесе белән ямьсезләнәсе килмәде. Ике арага берничә төп шомырт, берничә тал агачы утыртты да, бөтен ачуын шулар төбенә күмеп куйды.

Әнә шул бакчаларын былтыр күршеләре ат белән сукалаттылар. Анысына да Харис абыйның теле тик тормаган, җор сүзле хатыны гаепле булды. Күршеләре, Борһан абый белән Нәгыймәтти — карт белән карчык (былтыр булган эш), Харис абыйларга караганда бер-ике көнгә соңлап (бакча юеш бит), бакча казырга дип чыктылар да, көрәкләрен күтәреп бер-ике тапкыр аттылармы, юкмы, Харис абыйның хатыны Мәүҗидә апа тегеләргә:

— Борһан абый, бер җыр әйтимме? — диде.

— Әйттер әйдә, Мәүҗидә!

Мәүҗидә апа, алмагачлары көенә китерергә тырышып, турыдан-туры җырлап та җибәрде.

Үзең актив, үзең бик карт,
Нигә бакча казыйсың?
Рамай дустың бригадир бит!
Бер ат сорап алмыйсың!

Шушы такмактан соң Борһан абый:

— Үтердең, Мәүҗидә! Бер генә көрәк тә алып атасым юк, валлаһи менә! — дип, көрәген җиргә батырды.

— Иллә дә телең, Мәүҗидә! — диде Нәгыймәтти.— Әллә безнең бакчаны казырга да кулың кычытып торамы. Чамала, үзеңә кала бит, мин ярты кеше генә,— диде ул, билен уа-уа.

— Мин тагы бер җыр әйттерәм алайса, Нәгыймәтти.

Мәүҗидә апа такмаклап та җибәрде.

Бакчагызга дуңгыз кергән,
Актара бит балчыкны!
Бакча казытып азаплый
Илле яшьлек карчыкны!

— Киттек, карчык,— диде Борһан абый.

— И-и, Мәүҗидә! Хараплар гына иттең! Ялынып кына алып чыккан идем мин аны! — диде Нәгыйммәтти.

— Нәгыйммәттикәем, бер дә аптырама, хәзер ат алып кайта ул! — диде Мәүҗидә апа аны юатып.

Чынлап та озак та үтмәде, Борһан абый берьюлы ике ат, сука белән кайтып та керде. Ярты көн дигәндә җирнең астын өскә китереп, кантарлардан тау өеп, менә дигән бакчаны танымаслык итеп, ерып та чыктылар. Алар артыннан җир кипкәнче дип, Нәгыйммәтти утын тукмагы белән кантар ватарга тотынды. Бәргән саен күршесен ачуланды.

— Җыр чыгара, имеш! Моның кай төшенә бәрәңге утыртыйм! Мәүҗидә! Ишетәсеңме?!

Җор телле Мәүҗидә апа җиңел сөякле дә иде.

— Үпкәләштән түгел, Нәгыйммәтти! Җырның ертыгы булмый дигән кебек, күрше хакы Тәңре хакы, дип тә әйтәләр. Хәзер өмә ясыйбыз бакчагызга!

Мәүҗидә апа тырмасын күтәреп керде дә, җырлый-җырлый тәки эш итеп чыкты бакчаларын.

Хатыны өйгә кергәч кенә, Харис абый аның бу эшен бик өнәми, ачуланасы килгән сымак итеп:

— Телеңә күрә таман, үзебезнең бакча тора... дип башлаган иде, сүзгә күршегә керми торган Мәүҗидә апа бу юлы да Харис абыйны һәрвакытта да өнсез калдыра торган «Есть, товарищ Молотов!» диде дә самавырга тотынды. Бер яктан, бу сүзләр Харис абыйның авылдагы кушаматы «Чүкеч»кә ишарә булса, икенче яктан, «Сүзләрең бик дөрес, әтисе, барысын да син дигәнчә эшләргә мин һәрвакыт әзер!» дигәнне аңлата иде. Харис абыйның моңа каршы әйтердәй сүзләре һичкайчан табылганы юк. Ул тәмәке янчыгын капшап, «алай булса мин, чәй кайнаганчы...» дип, һәрвакыттагыча әйтәсе сүзен әйтеп бетерми, үзенең елмайганын хатынына күрсәтмәс өчен ишегалдына чыгып китә торган иде...

Ә быел Харис абый бакча эшләренә көздән үк әзерләнде. Әле былтыр ук, бәрәңгеләрне алып бетерү белән, бакчасына тирес чыгарып таратты. Иртә язда да бакчада матур ташаяк кыйпылчыклары эзләргә яраткан кызларын бакчага чыгармады, җирне борчытмады. Шуңа күрә бакча казу эшен көтеп алгандай, тәмен белеп эшләде. Балаң ишле булгач, җир яраттыра икән үзен. Көрәген сабына кадәр батырып кертте, тирес белән буташтырып, кантарларын бәргәләп, вак ташлар чыкса, иренмичә иелеп алып, ызан ягына таба аткалады. «Их, малай өйдә булса!..» Харис абый беренче хатыныннан туган олы улын искә төшерде. «Еракта шул... Нишләп йөри микән бу минутларда. Мине дә исенә төшерә микән...»

Менә шундый уйлар белән бакча казыган чагында, өмәгә килеп дәштеләр аны. Көн әрәм була инде. Мондый кызу эш

вакытында тагы бер көн сорап эштән калырга гомердә дә батырчылыгы да, ояты да җитмәячәк аның. Ә өмә эше изге эш. Бармыйча булмас. Харис абый кешене өеннән буш кул белән, буш сүз белән озатканнардан түгел. Юк дип әйтә белми. Бүген дә «булмас» димәде, «ярар» дип калды.

Харис абыйның гомердә дә аракыга исе китмәде. Олы бәйрәмнәрдә бик сыйлап бирсәләр генә авыз иткәне бар хәмер дигән ул нәрсәне. Ә менә өмәдән ул шактый кызмача кайтты. Яңа өйле булу шатлыгыннан түбәсе күккә тигән Сәмигулла егып салды авызына. Өмә ансыз булмый икән хәзер. Гел авызына да алмаган кешегә җитә калды. Харис абый күзгә күренеп үзгәрде. Күңеле йомшады, бакча казулар да онытылып китте, кешегә иткән игелеге рәхәт булып бөтен тәнен, җанын урап алды. Бүген ул ел буе запаста саклаган сүзләрен сөйләп бетерде. Җырларга дип тә талпынган иде, «Уф—фа чиләге, пешә кура җиләге...» диде дә туктап калды. Әйе, әйе, «Чиләбе» дип түгел, «чиләге» дип җырлый, шулай дип белә иде ул җырны. Монысы инде җырның еллык кына түгел, гомерлек запасы иде. Йөзенә елмаю чыкты, бит очлары кызарып китте. Шул арада танымаслык, ягымлы, үзенә күрә күп сүзле кешегә әйләнде. Өйгә дә әнә шул кәеф белән кайтып керде. Көн иртә иде әле. Хатыны эштә, балалар урамда. Ул ватык йозак эленгән өйгә керә тормады, бакча ягындагы имән торлыкка сөялгән көзге кебек көрәкләрнең саллырагын сайлап алды да эшкә кереште. Бакча казу аны иртән бүленгән уйларына алып кайтты. «Их, малай өйдә булса, бер ике көндә эш итәр идек бу бакчаны!»

Ул берничә көрәк каерып атты да, тураеп көрәгенә таянган көе, фуражкасын артка җибәреп, маңгаен сөрткәндәй итте, артына борылып казыйсы җиргә күз ташлап алды һәм кесәсеннән тәмәке янчыгын чыгарды. Иң башта янчыктан бер төрерлек итеп кенә ертылырга әзерләнеп, пөхтәләнеп салган гәзит кәгазен алды. Караса, гәзитнең бу өлешенә, бөтен җирен тутырып, кемнеңдер рәсеме эләккән булып чыкты. Харис абый рәсемле җиренә тәмәке төрергә яратмый иде. Рәсемдә кургаш күп була икән, зарарлы, дип сөйләгәннәрен исендә тотыпмы, әллә кемнеңдер рәсеме янганны күрәсе килмичәме, тәмәкесен икенче битенә төрде. Үзалдына елмаеп куйды... Тигән җиргә тиеп, тимәгән җиренә тимичә, түмгәкле юлдан тәгәрәгән арба тәгәрмәчләре кебек, бәреләсугыла, башыннан берничә уй йөгереп үтте. Ә бәлки шушы гәзиттәге рәсем сәбәпледер, Түбән оч Хәйрулла исенә төште. Рәсем дигәннән, ул да, ураза аенда стеналарына ябыштырылган гәзитләрнең рәсемнәренә ак кәгазь ябыштырып, каршында бер сурәт тә калдырмыйча намаз укый торган иде. Ә инде ураза беткәч, шул стена уртасында эленеп торган чәчәкләп чуклап ясалган шәмаил өстенә тастымал ташлап, аракы эчә иде. Кызык бу кеше дигәнең, кызык...

Харис абый ызанга чүгәләде. Тәмләп тәмәке төрде дә тирән итеп суырды. Шул вакыт бакча ягына Харис абыйның сапсары бөдрә чәчле, әнисенеке кебек сипкелгә манчылган чуар битле уртанчы кызы йөгереп чыкты да ашыга-ашыга нидер сөйләргә тотынды. Харис абый кулындагы төпчеген җиргә күмде. Кызын кулына алып, итәгенә утыртты. Баланың аркасыннан кагып, «Бөдрә чәчле кызым бит минем, зәңгәр күзле кызым бит минем, үскән кызым бит минем» дип, гомердә әйтмәгән тагы әллә нинди ягымлы сүзләр белән сөйде дә өмәдән соң сыйланганда кесәсенә салган конфетларның берсен алып кызына тотырды. Кызы исе китеп, аптырап, әтисенең йөзенә карады. Әтисенең битен болай якыннан бер тапкыр да күргәне юк иде әле аның. Ләкин ул әтисенең елмаю тулган зәп-зәңгәр күзләреннән башка бернәрсә дә күрмәде бугай. Нинди ягымлы иде бүген әтисенең күзләре... Менә безнең әти якыннан нинди икән... дип уйлап алды ул. Кызның әтисе яныннан гел китәсе килмәде. Менә шулай, уенга да чыкмый, кич булганчы әтисе янында утырырга әзер иде ул. Тик әтисе генә утырган җиреннән үк көрәк сабына тотынды, урыныннан торып басты.

— Бар, кызым, апаңа әйт, чәй куя торсын...

Кыз шунда гына оныткан дөньясына кайтты. Кулындагы конфетына карап алды да, ат тоттыргандай, урамга атылды.

Бергә уйный торган иптәшләренә генә түгел, урамнан үткән һәр кешегә башта конфетын, анысы авызда эреп югалгач, конфет кәгазен күрсәтеп мактанды кыз.

— Әти мине алдына утыртып сөйде! Матур кызым, дип әйтте! Менә күрдегезме, конфет та бирде! Менә!

Туп-тулы сулы чиләкләр авырлыгыннан калтырана-калтырана атлап судан кайтучы апасын күргәч, сеңлесе аның каршына йөгерде.

— Кайда йөрисең син! Әти өмәдән кайтты, бакча ягында! Бик беләсекәйләрең килсә, мине алдына утыртып сөйде. Ышанмыйсыңмы, менә конфет та бирде!

Ул апасына ялый-ялый юешләнеп беткән конфет кәгазен күрсәтте.

— Бар тизрәк! Өмәдән кайтканлыгы бетмәсә, сине дә яратыр! Куй инде чиләкләреңне!

Апасы, баскан урынында чиләкләрен куеп, көянтәсен болдырга атты да, бакча ягына чапты. Әтисе башын да күтәрми, кызып-кызып бакча казый. «Өмәдән кайтканы беткән, ахры, апаны яратмас микәнни!» дип уйлады аның артыннан ияргән сеңлесе. Харис абыйның олы кызы, сеңлесеннән бары тик ике яшькә генә зуррак булса да, аның исемен дә өйдәгеләр үзара «Олык» дип йөртәләр иде, әтисе каршысына килеп басты. Көрәк янына ук килеп җиткән кызының чебиләп беткән яланаякларын күрүгә, Харис абый елмаеп куйды, башын күтәрде.

Аннары очкындай җиңел, ябык кызын кулына алды да һавага чөйде: «И-и, олы кызым минем, олы ярдәмчем минем...» Менә бу көн балалар өчен иң бәхетле көн иде.

...Бу хәлләрдән соң бик күп еллар үтеп китте. Кызлары, малайлары үсеп, үз тормышларын кордылар, үзләре хәзер балалар үстерә.

Еллар үткән саен, шушы аз сүзле, бөтен уйларын гомер буе эчендә саклаган Харис абыйны бер сагыш кимерде. Бу сагыш аны әле балалар да дөньяга килмәгән тормышның иң беренче көннәренә алып кайта. Күптән булып үткән бу вакыйгаларны нык итеп күңеленә кертеп уйламаса да (алай булса акылдан язарга кирәк), башыннан бер дә китеп тормады ул уйлар. Менә тормыш, башыңа ормыш, шушыдыр язмыш дип кенә уйлый торган иде. Уйларсың шул... Харис абыйның беренче хатыны, җиде яшьлек улын әтисенә калдырып, башка берәүгә тормышка чыкты да китте. Әше буенча чит җирләргә еш китәргә туры килгән вакытлар иде. Башта Харис абыйның моңа бик исе китмәде. Әйдә, шулай да булсын ди... Сугыштан соңгы еллар... Авылда хатын-кыз буа буарлык... Теләсә кайсысын сайла. Тик ачу катыш гарьлек йөрәген ашады. Малай бар бит... Нәрсә малай! Әтисе янында, әбисе бар, ятим булмас... дип уйлады ул. Сайланды да бераз... Үзенә хатын, малаена әни булырлык кызга өйләнгәнче берничә ел вакыт та үтеп китте. Шаян сүзле, гел елмаюлы, бер дә ачу килүне белми торган Мәүҗидәгә өйләнгәч кенә, тормышы түгәрәкләнде кебек. Малай үскәндә ятимлек сизмәде. Мәүҗидә Тәвисне какмады, бала аңа тиз ияләште. Икенче көнне үк «әни» дип йөри башлады. Ә Тәвис дигән исемне улына Харис абый үзе сайлаган иде. Авылда шулай бит инде ул, исемнең мәгънәсен уйлап тормыйлар, яңгырашы гына туры килсен. Харис Тәвис... Бу исемнең тутый кош дигәнне аңлатканын белсә, бәлки, куйдырмаган да булыр иде. Ләкин гомерендә бер генә мәртәбә дә ул исемнең икенче мәгънәсе турында уйлап та караганы булмады Харис абыйның. Бу исем аңар бары тик Тәвисне, аның улын гына хәтерләтә иде.

Тәвис шук малай булып үсте. Авыл мәктәбенә бик теләп йөрмәде. Укытучыларын да йөдәтеп бетерде. Шуңа күрә 1952 елны, Тәвискә 14 яшь иде ул вакытта, ФЗӨга укырга китәм, дигәч, аңа каршы килмәделәр. Җитмәсә, авылга килеп җыеп та йөрделәр әле аларны. Үзеише тагы берничә малай да аның белән китте укырга. Укыр, кеше булыр, дип уйлады Харис абый. Башта сирәк булса да хатлары килгәләде Тәвиснең. Хат килгән вакытта сүз гел аның турында гына була торган иде. Хатны укып бетергәч тә, Харис абый беренче сүз итеп:

— Әнисе, кара әле, киткән чакта Тәвискә ничә ипи биргән идек без? Дүртме, әллә биш идеме?

Мәүҗидә апа дәшми. Чөнки бу сорауга соңгы елларда әллә ничә тапкыр җавап бирде инде ул. Менә бу юлы да, әллә ирен җәлләде, әллә инде онытканда бер хат язып, әтисен сагышка салган үги малаена ачуы килде, дәшми калды. Харис абый сорауны да җавап көткәннән түгел, болай гына биргән иде.

— Бишне бирдек бугай... Биш иде шул... Ач түгелдер әле. Юлга ризык белән китте.

— Ничә ел үтте бит инде... Үзең дә хас бала-чага...

«Үтсен. Ризыклы ат арымас. Юл башы ничек башлана бит. Менә бүләкләр белән кайтып та төшәр әле» дигән сүзләрне кычкырып әйтмәде, эченнән генә уйлап куйды.

Башта хатлар Казаннан, аннары Себер якларыннан килде. Ниндидер заводта эшлим, дигән. Тик Тәвис бер генә хатка да кайту турында язмады. Шул ук заводтан армиягә алынды. Ул чакта гел әйбәт булып торды, хатлары ешайды. Харис абый горурланып йөрде.

«Сәламәтлеге әйбәт, болай булгач, армиягә юк-барны алмыйлар» дип юанды.

Тавис армиядән өйгә кайтып тормады. Дөнья читендәге Себер шәһәрләренең берсендә төпләнеп калды. Хат килүләр гел сирәгәйде, берзаман гел югалды Тәвис, хатларга каршы җавап язмас булды. Харис абый кич саен капка төбенә чыгып почта кызны көтте. Тик ул йөзен җиргә терәп гәзит тоттырды да китте, гәзит тоттырды да китте. Харис абый почта кыз белән очрашырга ояла башлады. Шуңа күрә капка артына почта салырга дип, бер тартма ясап элде. Җыелган сагышларын шул тартмага сөйли торган булды. Кешегә ишеттереп түгел, әлбәттә, эченнән генә сөйләде ул аны.

«Нәрсә, син дә көтәсеңме хат... Сиңа да читендер буш тору... Гәзитләр белән генә юанасыңмы... Ә мин бит аларны укыганым да юк... Көтик инде, көтә башлагач...»

Ләкин хатлар килмәде.

Инде язып-язып җаваплар алмагач, беркөнне Харис абый, улының соңгы адресын алып, авыл укытучысына киңәшкә килде.

«Югалды бит малай, мин әйтәм... Исәнлек хәбәрен генә беләсе иде... Нишләргә...»

Укытучы үз кулы белән адрестагы шәһәрнең милиция бүлегенә хат язып җибәрде. *«Шундый, шундый кеше бармы ул сезнең шәһәрдә, исәнме ул, хәбәр бирсәгез иде...»*

Менә бу хатка җавап озак көттермәде. Тәвистән түгел, милиция бүлегеннән килеп төште хат. *«Исән, яши. Адресы менә шушы»* дип, тулысы белән Тәвиснең адресы да язылган иде.

Ул көнне Харис абый шатлыгының чиге булмады. Әйтерсең улы үзе кайтып төште. Хатны кат-кат укытты ул.

— Әнисе, бүген үк хат языйк. Инде адресы да билгеле булгач, милиция ялганламас, пусилка да әмәллик әле.

Харис абый ел саен Тәвискә дип итек бастыра иде. Быел да күптән бастырып куйды. Себер җире бит, салкын яклар...

Теге почта тартмасын тиз генә кубарып алып керде дә посылка тартмасы ясап куйды. Хәзер бу тартманың почта өчен кирәге юк иде. Хатлары килсә, почта кыз каршысына да чыгарга оят түгел. Посылка эченә бер кием киез итек, ике пар йон оек, бер кисәк туң май, калган ягына тартма тулганчы көздән суелган сарык ите салды. Кыш өсте, бозылмас әле...

Бер-ике сүз белән генә булса да, үз кулы белән дә хат язасы килде аның. Әйтәсе килгән сүзләрен хатынына әйтеп торып яздырырга оялды. Балаларның дәфтәреннән бер бит ертып алды да, карандаш эләктереп сиздерми генә мал өенә чыгып китте. Тик «улым» дигән сүзне язуга туктап калды. Харис абый бары тик гарәп хәрефләре белән генә яза белә иде. Укый алмаячак бит улы... Ләкин эти кешенең бу минутларда улы белән сөйләшәсе, эчен бушатасы килде. Мин язганны белсен, ичмасам, дип уйлады ул. Һәр җөмләсен ул бары тик бер сүз «улым» дигән сүздән башлады. *«Улым, кайт, улым, картайдым инде, улым, хәзер монда да авыр яшәмибез, улым, улым...»* Менә шундый сүзләр белән бетерде ул улы беркайчан да укый алмаячак хатны. Шушы эч серләрен язган дәфтәр битен хатынына гына күрсәтми, инде посылка эчендә яткан киез итекнең кунычына кыстырды.

Бу посылкага каршы хаты килде Тәвиснең. Бары тик бер генә хаты килде. Харис абый кабат милиция белән эзләтмәде улын. Тик кайтыр әле дигән өметен өзмичә һаман көтеп, көн артыннан көн, ел артыннан ел уздырды...

...Тәвис һич көтмәгәндә кайтып төште. Өйдән чыгып китүенә утыз ел тулганда, салкын көзге кичләрнең берсендә кайтып төште ул авылга.

...Урамнан кемнендер кычкырган тавышына ишегалдында эт өрә башлады. Харис абый, кабалана-кабалана галошларын эләктерде дә «тими ул, тими» дип, капка янына ашыкты.

Капка төбендә Кирмән оч Маһинур белән бер ят ир кеше басып тора иде.

— Харис абый, менә бу кеше сезнең өйне эзләп йөри... Үзем озатып куям дигән идем дә, этегездән курыктым.

— Тими ул, тими. Бәйдә бит ул... Әйдәгез, әйдә... Караңгы бит, берни күренми, өйгә кереп сөйләшик,— диде Харис абый.

— Мин кереп тормыйм, бер сарык бәрәнем кайтмый калган иде. Сездә ят бәрән юктыр бит?..

— Нәрсә? Ә-ә, юк, Маһинур, юк. Малларны ябып кердем инде.

— Бер дә аерылып калмый торган иде, кая булыр бу...

Шул сүзләр белән Маһинур, Харис абыйны ят кеше белән калдырып, «Бәрәч, бәрәч!» дип кычкырып, урам буйлап, югалган сарык бәрәнен эзләп, китеп барды. Эт тә тавышын кисте. Харис абый теге кешене өйгә әйдәде. Өйалдында, аның юеш аяк киемнәрен салдырып, коры ката кидерде. Теге кеше бәләкәй генә чемоданын ишек борысына сөяп куйды да Харис абыйны кочаклап алды. Харис абый да аны-моны аңламый, аның аркасыннан сыйпады. Өй ишеген ачып, эчкә үтәргә ишарә ясады.

Өйдә алар өчәү иде. Кич утырырга дип хатынының күршедә генә яшәгән апасы Фәгыйлә дә кергән иде.

— Здравствуйте ...— диде теге таныш булмаган кеше.

— Драстуй, драстуй ...— диде Мәүҗидә апа.— Кем дип белик сине?..

— Ят кеше булмаска тиеш,— диде Харис абый.— Өйалдында мине кочаклап та алды...

Фәгыйлә апа бу кешенең кояшта каралып янган йөзенә карап торды да:

— Ком гарәбенә әйләнгән бу! Күр әле йөзен! Чуенның ундүртенче кичәсе! Тәвис бит бу! — дип кычкырып җибәрде.

Әйе, бу кеше чынлап та Тәвис иде. Ләкин ул ни өчендер һаман да үзен танытмаска маташты. Ни өчен? Нәрсә уйлап? Ана телендә бер сүз ычкындырмый, «не понимаю» дигән булды.

Харис абый белән Мәүҗидә апа да утыз ел буе күрмәгән улларын танып алдылар. Алар икесе дә гасабиланып, аптырап калдылар. Гомер буе көтеп, бер хәбәре дә килмәгән уллары белән менә шушылай, көзге караңгы кичләрдә очрашырбыз дип уйламаган иде алар. Ул көн җылы да, якты да, сөенечле дә булырга тиеш иде. Ләкин ничәмә еллар хәбәрсезлектән күңелендә нәрсәдер сынган иде Харис абыйның. Ул гомере буе көтеп алалмаган, хәзер инде ят телдә сөйләшкән улына текәлеп сүзсез калды.

— Знаш! Знаш! Четери кәмин дүрт таш! — диде Фәгыйлә апа, бар булган русчасын чатнатып.— Тәвис бит син! Йә, сөйләшегез инде! Берсе телен йоткан, икенчесе оныткан! Менә аталы-уллы!

Тәвис фуражкасын битенә төшереп каплады да дәшмәде, тик аның калтыранган иңнәренә карап, бу очрашу аның өчен дә җиңел түгеллеген аңлап була иде.

Харис абый исә улының җилкәсеннән кочып алды да үзенә тартты.

# Мәскәүдә милли «перестройка»

*(Әдәби фельетон)*

Клуб фойесы. Стенада төрле плакатлар, гарәпчә-татарча транспорантлар. Өч җирдә өч өстәл. Бер өстәл өстенә «Татарский культурный центр» дип, икенчесенә «Туган тел җәмгыяте» дип, өченчесенә «Общество любителей татарской культуры» дигән сүзләр язып эленгән. Өстәлләр янында мәш киләләр. «Туган тел җәмгыяте» дигән өстәл артындагылар «Бөтен галәмдә бер тел — татар теле!» дигән плакатны кадаклап маташа. «Татарский культурный центр» дигән өстәл артындагы ике ханым «За международное сотрудничество: венгерская салями на основе конского мяса!» дигән плакатны кадаклый алмый интегә. Ябыштырдык дигәндә генә, плакатлары ычкынып китә дә яңадан болар өстенә килеп төшә. «Общество любителей татарской культуры» дип язылган өстәл янындагылар «В каждой республике по одной татарской автономии» дигән плакатларын ике яктан сузып тотканнар, эләргә урыннары юк.

Кабаланмыйча, бер кая ашыкмый вәкарь генә, башка кеше белмәгән сергә ия булгандай утыручы да бар, анысы «Болгар» оешмасы икән. «Болгарча–татарча» сүзлек тә язып алып килгән. Кулдан гына язылган булса да, бер генә бит ул. Шуларны килгән бер кешегә сүзсез генә таратып тора. «Болгар» оешмасыннан булмаса да, Мәскәүдә күптән түгел генә «Болгар» театрын оештырдым, дип, чат саен сөйләгән Гөлфирә бүген дә шушы өстәлләр тирәсендә бөтерелә. Җилпәгеч сымак итеп бер кочак билетлар күтәргән.

— Театр сөюче иптәшләр! «Болгар» студиясе! Мәскәүдә беренче мәртәбә Галиәсгар Камал! «Беренче театр»! Билетлар алыгыз! «Болгар» студиясе!

— Әй йөрәк маем! Болгариядәнме? Болгарская розаны үлеп яратам!

— Ниткән роза? Нинди Болгария? «Болгар» студиясе! Театр «Булгар»! Аңладыңмы инде?

— Дай поцелую! Үлеп яратам Болгарияне! Дай поцелую!

— Үпсәң үп инде, үп! Болгариянең катнашы юк түлке монда! Театрның исеме «Болгар»! Аңладыңмы! «Болгар». Кара әле, Роберт, болгарның нәрсә икәнлеген аңлат әле боларга, сүзсез утырма! Сүзлек ясап килгәнсең бит!

— Менә болгарлар! Театр да ясаганнар, монда да килеп җиткәннәр! Болгарчамы, татарчамы?

— Вәйт җанга тиде! Аңламаса аңламый икән кеше. Театрның исемен үзгәртми булмас, ахры. Буталчык нәрсә икән бу Болгар. Галиәсгар Камалның «Беренче театр» әсәрен куйдык! «Болгар» студиясе куйды! Билетлар! Билетлар алыгыз!

Гөлфирә янына тагы берничә кеше килә.

— Казаннан ведь, ниткән Болгариядән булсын... «Зәңгәр шәл»ме?

— Уф, үләм икән! Менә халык күчәнләнеп каткан! Җәмәгать! Мәскәүдә «Беренче театр!» Билетлар алыгыз...

— Ничәнче театр ди?

— Беренче, ди. «Зәңгәр шәл», йә булмаса «Галиябану» инде. Шәп театр, кызганыч, Галиябану җүләрләнә дә үлә... Алыгыз инде билетларын, бик интегә бит. Кая, үземә ике билет сат әле.

— Кем әйтте аны Галиябану үлә дип?! Хәлил үлә, Хәлил! Тик безнең спектакль «Беренче театр»! Әле яңа ачтык! Мәскәүдә яңа «Болгар» студиясе!

— Галиәсгар Камал давнонықы бит! Свежийраклары юкмы?

— Менә җаным! Колбаса түгел бит ул сиңа. Галиәсгар Камал! Безнең үлмәс драматургыбыз.

— Атәм ведь давнонықы, дип. Әллә кацан үлгән Галиәсгар Камалны свежий, дип тора.

— Үләм, җаным! Үләм! Менә ул «Әйдә халыкка хезмәткә: шунда газап, хәсрәт күрмәккә!» И-и, безнең Тукаебыз юкка гына әйтмәгән шул!

«Гөлфирә, юл бир әле!» дип, икәү, аның берсе Әбдүш, икенчесе әлегә билгеле булмаган түбәтәйле матур гына егет, халыкны аралап, өстәл күтәреп керәләр. Алар артыннан кәгазь тартмалар өстерәп, Әбдүшнең хатыны Бәрия ханым ияргән. Әбдүш дигәне кечкенә буйлы, күпереп торган чаларган чәчле, шушы чәче аркасында халыкта Тузганак кушаматы белән билгеле шәхес. Аның жилет кесәсеннән зур гына мөһер асылынып тора. Бер дә асылынып тормас иде, ул мөһергә «Тел сакчысы Әбдүш» дигән сүзләр язылган шул. Өчәүләшеп мәш килеп каплардан китапларны чыгардылар да өстәлгә тезәргә тотындылар.

Керә-чыга йөри килгән халык. Исәнләшәләр, күрешәләр, кайберәүләр бу яңа куелган өстәл кырыена килеп баса.

Әбдүш китапларны тезеп бетерә дә, кесәсеннән түбәтәй чыгарып, башына киеп куя.

— Иптәшләр! Әй, әфәнделәр, ханымнар! Милли телебездәге китапларга рәхим итегез! Үз акчама китап кибетеннән барып алдым. Шушы очрашу хөрмәтенә дип! Китаплар кызыклы! Сда-

чалар Сабан туе фондына китәчәк. Сабан туе, әфәнделәр, безнең милли бәйрәм!

Китапларны карыйлар, әлегә берсе дә алырга ашыкмый. Өстәл янында теге түбәтәйле егет белән Бәрия ханым кайнаша.

Халык байтак кына җыелган. Табышалар, кочаклашалар, шатланышалар!

— Ахмет Иванович! Откуда син загарың хуат!

— Черный море якларында ял иттек...

— Делалар нищек?

— Шылай ничего...

Әбдүш, бу гөжләүне басып, бөтен тамагына кычкыра.

— Әфәнделәр! Китаплар алыгыз! Китаплар! Бер тәңкә акча түгел безнең заманда. Узган ел да Сабан туе дип күпме сөйләндек! Фондка акча кирәк. Бер тәңкәлек китап ике тәңкәгә сатыла, ике тәңкәлек өч тәңкәгә, и таки дали.

— Дали не дали! Брат, нә сатасың?

— Әфәнде диген, агай-эне! Әфәнде! Әбдүш әфәнде мин. Сатам дигән сүз — зур сүз ул. Монда саттым юк. Мин — татар кешесен культуралы итәргә тырышып йөргән бер мәхлук. Мин — мәгърифәтче, тел сакчысы. Бу китаплар акчасы Сабан туе фондына китәчәк.

— Син Казаннан что ли, аңгармыйм что-то?

— Мәскәүдән, Мәскәүдән! Менә китаплар Казанныкы, татарча!

— Чәкчәк, «Татарстан» торты юкмы?

— Юк, китаплар гына бит! Күреп торасыз! Китаплар!!!

— Ишеттек, брат, ишеттек! Кая, бир булмаса берәрсен...

— Сайлагыз, сайла! Китаплар! Китаплар! Бәясе дә күп түгел, сдачасы да юк түгел! Теле, матур сүзе бар, язучының үзе бар! Кая әле, энекәш, мин пичәт басам, син имзаңны куй. Син бүген автор!

— Нә сүли? Бәя диме?

— Чутла инде, бер тәңкәсе Сабан туена калырлык булсын!

— Мин хәзер безнекеләрне куцасы белән китерәм.

— Кемнәрне?

— Мижгарларны... Үзең кайсы яктан?

— Мин икенче яктан. Китаплар! Китаплар! Татарча китаплар! Фу, баш катты бу китаплар белән.

— Әйттем мин сиңа! Шулхәтле өстерәмәсәң...— диде бу хәлне күзәтеп торган Бәрия ханым. Халыкның китап алырга теләгән күрмәгәч, аның кәефе кырылган иде.

Болар янына кулына театр белдерүе тоткан Гөлфирә килеп баса. Әбдүш конкуренцияне бик өнәп җиткерми, үзалдына: «Килеп җитте! Алтарай! Сару кайнаткыч!»

Гөлфирәгә борылып:

— О-о! Гөлфирә ханым! Театрыгыз ни хәлдә?

— Үземне сора, тел белгече, акча корты. Монда да килеп урнашкан син. Сәүдәләр ничек бара?

— Әллә нәрсәләр сөйләнмә, яме. Тукта, тукта! Бу нинди китаплар синдә?

— Үземнекеләр! Әллә синең өстәлдә генәме китап нәшриятының бөтен тиражы!

— Каян килсен сиңа китап! Әле кулыңда белдерү генә иде бит! Өстәлдән суккансың. Куй урынына!

— Нишлисең син?! Тартма, диләр, ертасың бит, кара! Мәскәүләр әйтмешли, әллә мозгаңа кан кровоизлиять иттеме?

— Итсә итәр, тик китапларны урынына куй, йә булмаса акчасын бир!

— Акча! Биреп куйганың бармы әллә! Татар китабын, Аллага шөкер, син генә сатмыйсың әле.

— Гөл-фи-рә! Башка сүзең булмаса, хатынлы ирләр янында тукталма яме!

— Ә-ә... Бәрия ханым! Сез дә бирedәмени? «Әбдүшеңне так түшеңә» дип, халык җыры чыгарырмын әле, ачуымны китерсәгез! Бар, әнә тегендә акчаларын кая куярга белмәгәннәр бер кочак! Театрга егерме билет алды бер тилесе! Әле артистларын тапмаган. Исеме дә билетлары гына бар.

— Боргаланма! Куй китапларны!

— Фу, туйдырды бит тәки! Күрмисеңме, әллә укый да белмисеңме! Пьесалар китабы бит! Театрыма артистлар эзләп йөргәнне күрмисеңмени?! Бер юньле кеше очрамый, очраганы да тамашачы гына булырга тели. Ни телләре юк, ардым пряме! Әнекәем! Бу нинди егетне күмдегез китап арасына. Түбәтәе дә бар икән! Уф! Коеп куйган герой — любовник!

— Кем любовник, кем?

— Әбдүшең түгел инде, Бәрия! Менә бу егетне әйтәм... Кара, кара, елмая да белә икән. Сөйләшә дә белсә! Безнең сөйләшүне аңладыңмы, матурым! — Әбдүш, җанкисәк, татарча сөйләшә беләме бу егет? Әллә түбәтәйле йөзе белән татарча елмая гына беләме?

— Сөйли белми, яза гына белә. Автор ул.

— Автор! Бөтен авторларны күреп тә беләм, танып та беләм. Ә моны беренче тапкыр күрүем. Шагыйрьме, прозаикмы, әллә минем бәхеткә драматургмы? Фамилиясе ничек? Яшьләр үсә хәзер, җитешеп булмый алар артыннан...

— Автор, дидем бит инде. Аның фамилиясе сиңа нәрсәгә. Бернәрсә аңламаган башың белән татар китабын пропагандалау эшендә комачаулама әле, Гөлфирә!

— Менә, менә әкәмәт! Син белгәнне мин киптереп элгән! Китапларыңны сатарсың, алучы тапсаң! Ә мин аларны телне күреп аңларга өйрәтәчәкмен! Театр аша! Кемнең татарча беләсе килә! Театрга билетлар сатам!

Микрофоннан тавыш яңгырый:

*«Җәмәгать! Без бүген өч җәмгыятькә бүленеп таркалган Мәскәү татарларын берләштерергә җыелдык. Тамаша залына рәхим итегез!»*



# Балалар өчен хикаялар

# Җәнлекләр кайта

— Кайталар! Кайталар! Иң беренче булып мин күрдем! — диде Диләрә ашыга-ашыга.— Куян баласы булса миңа!

— Әйе, сиңа ди! Көтеп тор менә! Син бит башта төлке баласы кирәк, дигән идең! Әле бүген, үскәнем, Илсур чираты,— дидем мин.

Менә ничә көн инде урман эшендә эшләүчеләрне көтеп алабыз. Ни өчен дисезме? Барыбызның да өйдә нинди дә булса җәнлек булдырасы килә. Ә урманда эшләүчеләргә көн саен очрап тора бит ул. Тотасы да алып кына кайтасы.

Беркөнне мин, Диләрә, Сәвия, Фәния, тагы берничә малай, безнең очлар инде, җыелышып, урманда эшләүче Газизҗан абыйларга керергә булдык. Көне буе чана шуып, шакыраеп каткан киез итекләребезне шакылдатмаска тырышып кына кердек тә ишек төбендә туктап калдык.

— Барыгыз да кереп беттеме? Алайса, ишекне ябыгыз инде,— дигән тавыш ишетелде, без алып кергән суык пар артыннан.— Йә, ни йомыш, балалар?

Урамда бик батыраеп сөйләшсәк тә, өйләренә кергәч, син әйт тә, мин әйт дип, бер-беребезне кыстый башладык.

Көн саен алар урманга эшкә киткәндә, «Безгә куян баласы алып кайтыгыз әле!» дип кычкырып калганга, безнең ни йомыш белән кергәнне Газизҗан абый бик тиз аңлап алды.

— Ә-ә, җәнлекләр кирәк инде алайса сезгә,— диде ул сузып.— Кемгә нәрсә алып кайтыйм соң?

Барыбыз да шаулаша башлагач, ул безне туктатты да берәм-берәм сорый башлады.

— Борһан кызы, сиңа нәрсә алып кайтыйм?

— Миңа куян баласы.

— Ә сиңа, Галимулла кызы?

— Миңа төлке булса да ярый,— диде Диләрә.

— Төлке булса да ярыймы? Бик әйбәт. Гел очрап кына тора ул безгә. Кара әле, барысы да истә калмас, язып куй әле, Хисаметдин,— диде ул, пырхылдап көлеп җибәргән малаена карап.

— Ә минем күптәнге хыялым кечкенә генә бер тиен баласы. Әкиятләрдә дә бик матур итеп язалар бит ул тиен турында.

— Яз әле, улым, тиен баласы, диген.

Язды ди шул Хисам! Гомердә дә язмый ул аны. Безгә караган да авызын ерган. Нинди көлке нәрсә күргәндер.

— Ярар,— диде Газизҗан абый,— язмаса аңа ялынып тормабыз, болай да истә калыр.

Шуннан башлап, көн кичкә авыштымы, без Тазнарат тавыннан төшеп килүчеләрне көтә башлыйбыз. Менә бүген дә «Кайталар!» дигән тавыш ишетелүгә, юлны бар дип тә белмичә, кар ерып, мәтәлә-кадала алар каршысына йөгердек.

Безне күргәч, арыган йөзләре ачылып китте боларның. Газизҗан абый белән бергә кайтучы башка абыйлар да тукталып калдылар.

— Бүген кем чираты әле? — диде Газизҗан абый, барыбызны да күзе белән барлап чыкканнан соң.

Ә без, тыннарыбыз кысылып, барыбыз да аның букчасына текәлдек. Олы күренә.

— Тотканнармы?

— Алып кайтканнармы?

— Минем чират! — дип кычкыра-кычкыра артта калган Илсур да килеп җитте.

Ә инде иң беренче урманчылар янына мышнап килеп туктаган Мансур, әле бер нәрсә күрмәсә дә, ишетмәсә, арттагыларга борылып:

— Куян! Куян баласы тотканнар! Әй бүре бугай! — дип кычкырып җибәрде.

— Минем чират! — диде тыны кысылган Илсур.— Ахметшин мин. А хәрефенә. Миңа төлке баласы кирәк иде!

— Менә болайрак бит әле эшләр... — диде Газизҗан абый, бүреген артка җибәреп, сакал үскән битен сыпырып куйды.— Бүген төлке булмады шул. Бүре оясын күрдек. Әнә миңа ышанмасагыз, абыйларыгыздан сорыгыз,— дип, читтән генә көлемсерәп безгә карап торган абыйларга күрсәтте.— Аннары сезнең чират бит, егетләр! Чират! Ничек әле... А, Б, аннан китә В... Аны бозып булмый бит, егетләр! Алфавит! — диде.

— Әй, шуны инде,— диделәр малайлар, үпкәләргә җыенып.

— Юк, егетләр,— диде Газизҗан абый,— сез үпкәләмәгез әле. Иртәгә кем чираты?

— Минеке кала,— диде Илсур.

— Калмыйча торсын әле,— диде Сәвия,— синең чират үтте.— Минеке! — диде ул кычкырып.— Бикмуллина мин!

Сәвия А артыннан Б, диде дә Илсурга телен чыгарып күрсәтте.

— Чиратны бозып булмый,— диде Газизҗан абзый.— Әлифбаны без төземәгән. Аны әллә кайчан язып куйганнар! Менә иртәгә Сәвиягә куян баласы алып кайтырбыз. Барысы да берьюлы булмый бит ул.

Көн артыннан көн үтте, шулай итеп, кыш та узып китте. Ә

Газизҗан абыйның әле беребезгә дә җәнлек алып кайта алганы юк. Булмаса булмас инде, өйдәгеләре дә җиткән. Тиздән каз бәбкәләре чыгарга тора. Шулай да ул безгә ничек итеп куян артыннан йөгергәнен, баласын алам дигәндә генә ана бүренең алар артыннан куганын сөйләп, көлдереп бетерә. Хәзер инде без аны шушы хикәяләре өчен көтеп алабыз.

## Үтмәс товар

Җәнлекләр сорап нихәтле теңкәсенә тисәк тә, урманда эшләүче Газизҗан абый безне сөендерә алмады. Без дә Газизҗан абыйны аптыратмаска булдык. Ә менә беркөнне, агач авып Газизҗан абыйның аягы сынганны белгәч, көн дә хәл белергә йөри башладык. Җәнлек-мазар турында сүз кузгатмаска тырышабыз. Кая инде аңар хәзер авырткан аяк белән куян артыннан йөгерү. Әкияттәге Таңбатыр түгел лә ул. Тизрәк төзәлә генә күрсен инде. Әллә бездән, әллә эшсез ятудан алҗыган Газизҗан абзый:

— Әй балалар! Нигә сез шулай аптырыйсыз кыргый җәнлек дип. Хәер, малай чакта мин үзем дә гел сезнең кебек идем,— диде.— Менә бервакытны, салкын гына кыш көне иде, без, бер төркем малай-шалай, төлке, куян баласы тотып булмас микән дип, сезнең кебек, урманга киттек. Кайсыбызда чаңгы, кайсыбызда чана. Кар тирән чак иде. Нәрсәгә кирәк булгандыр инде ул җәнлекләр безгә? Аның заманы да нинди бит әле... Анысын сөйләп тормыйм, сез аны барыбер аңлый алмассыз. Шулай, ияртмәскә тырышсак та, елый-елый ияргән чаналылар, бәләкәйләр дип әйтүем, авылны чыгып аз гына үтүгә, арый башладылар. Безнең хәлләр дә шәптән түгел, кая куян артыннан йөгерү, чаңгы өстерәрлек тә хәл дә калмады. Өздереп тамак ачты! Шулай да урманга барып җиттек бит. Җәй көне генә ул урман бакча артында, кыш көне озыная икән аның юлы.

— Кайтыйк, кич була ... — диешә башлады малайлар.

— Туктагыз, мин әйтәм, монда чаклы килгәч, бер чабаталык булса да юкә төшерик.

Вәйт! Юләр! Кем инде юкәне кыш көне каезлый... агачларга барып тотынсак, кыш көне бар агач та бертөсле икән безнең өчен. Яфрагы юк бит. Әле берсенә, әле икенчесенә барып тотынабыз, куллар күшеккән, кая ул агач сындыру!

Кайтып киттек без әкрен генә. Бәләкәйләрне утыртып, чаңгыларны, чаналарны өстерәп. Карасак, юл буена талчыбыгы кебек кенә агачлар утыртып чыкканнар.

Күрше Сәмигулла:

— Туктагыз әле, бу юкә агачы бугай,— дип сындыра баш-

лаган иде, бер таяк кардан җиңел генә йолкынды да чыкты. Үзебезчә эш майтарабыз! Шулай итеп, без юл кырыендагы агачларны авылга кадәр җыеп кайттык. Ну соңыннан эләкте дә инде үзебезгә! Кыш көне кар өстенә салынган юлны күрсәтер өчен куелган маякларны җыеп кайтканбыз икән.

Белмим, егетләр, сезнең бәхет булырмы, юкмы, куян тотып бер бәхетле булганым бар минем. Шулай көзге салкыннар башланган чак иде. Бакча башына нигә менгән булганмындыр инде, хәтерләмим, читән арасына кысылган бәләкәй генә бер куян баласын табып алдым. Мескенкәем, гел хәлсезләнгән. Теләккә ирештем бит болай булгач, түбәм күккә тиде. Очтым гына өйгә!

Башта барыбызга да кызык тоелды. Әле бер нәрсә, әле икенче нәрсә биреп карыйбыз, ашамый гына бит! Ияләнгәч кенә, үзен генә калдыргач, капкалый башлады. Ә мин хәзер көне буе куян саклап өйдә утырам. Куян карарга керүчеләр белән өй тула. Куркак булса да тиз ияләште бу. Көндез сәке астында ята, бер тавыш-тыны юк. Ашыйсы килсә чыга да үзе савытыннан ашый. Күрше малайлары керәләр дә кызыгып карап торалар куянга, әйдә, малай, сат әле, диләр. Кайсылары берәр нәрсәгә алыштырыйк, дип, теңкәгә тия башлады. Шул вакытта берәрсенә биргән булсам соң, хәер, барыбер кире кайтарырлар иде. Бер бәла булды ул куян. Көне буе тынын чыгармый ятса да, кичен барыбыз да йокларга яткач кына, тотына аяклары белән ишекне дөмбердәтергә, барабан кага диярсең.

Бер көн түзәбез, ике көн түзәбез. Мин түзәм дә түзәм инде. Беркөнне әти чыдамады:

— Малай, теләсә кая куй куяныңны,— диде.

Ярар, мин әйтәм. Озак уйлап тормый, өй түбәсенә, чардакка менгезеп куйдым моны. Морҗа торбасы чыккан төшкә урын әзерләдем. Җылы да булыр, безгә тавышы да ишетелмәс. Йә, әйтегез әле, кемнең кыр куяныннан файда күргәне бар? Әнә шул өй түбәсендә яшәгән бер атна эчендә, артык тормады ул анда, яңа өйгә дип әзерләп куйган сүсне тураган да бетергән куяныбыз. Барыбыз да аһ иттек. Бигрәк тә әти дуамалланды. Кая куярга инде, беренче кар да яуды, кыш җитте бит. Үземнең дә куянны кулдан ычкындырасым килми. Малайлар арасында дәрәҗә дә күтәрелеп китте. Ни сөйләсәң, шуңа ышаналар, тыңлыйлар, сүзләремне һәрчак хуплап торалар!

Әти өзми дә куймый:

— Малай, теләсә кая куй куяныңны,— ди.

Киләткә урын әзерләдем дә куянны алырга дип өй түбәсенә менсәм, юк куян! Күпме генә эзләсәм дә таба алмадым. Берәр тишек табып төшкәндер дә урманына тайгандыр дип уйлап, эзләмәдек артык.

Туктагыз әле, кузгалмагыз, әле моның белән генә бетмәде

ул куян хәлләре! Югалганнан соң берничә көн үткәч, кайтып керде куяныбыз! Кайтып керде дигәч тә, үзе түгел инде, китереп бирделәр. Әни әйтмешли, язган мал икән! Соңыннан белдек, куян, өй түбәсеннән төшеп, урам аркылы чыгып барганда, Нәҗип тотып ала да моны, миңа да әйтеп тормастан, Миннеәхмәт белән нәрсәгәдер алыштыра. Шатланып, куянны кочаклап очкан гына Миннеәхмәт өйләренә. Өйгә алып кереп, куркудан дер-дер калтыраган куянны идәнгә җибәрүгә, сеңлесе Асия:

— Абый куян алып кайткан! — дип кычкырып җибәрмәсенме!

Тавыштан коты очкан, мескен җәнлек, кая барып бәрелергә белми үрсәләнгән дә, өстәл астына кереп качам дигәндә, эскәтерне эләктереп, өстәлдәге барлык әйберләре-ниләре белән идәнгә өстерәп тә төшергән. Бөтен өй эчләре белән тиз генә куып тотып, йөрәге ярылырга җитешкән куян баласын бишмәтен дә салырга өлгермәгән Миннеәхмәткә тоттырып чыгарып та җибәргәннәр. Һаман шул ук эти сүзе:

— Малай, теләсә кая куй куяныңны!

Миннеәхмәт озак уйлап тормый, беренче очраган кешегә тоттыра да, котылганына сөенеп, өенә йөгерә. Шулай итеп, берике көн эчендә бөтен авылны гизеп, үзебезгә кайтып җитте куяныбыз. Түбән оч Сара апа капчыкка салып алып менгән:

— Сезнеке дип ишеткән идем, Ходай хакы өчен кире алыгыз!

— Менә үтмәс товар мең алтын,— диде әни,— келәткә чыгарыгыз, булмаса...

Икенче көнне ашарына бирергә дип келәткә чыксам, көлсәң көл, еласаң ела! Тычкан тотарга дип корып куйган капкынга эләккән бит мескен куян! Алгы аягы кысылып тора. Бик җәлләдек инде үзен барыбыз да. Әти, ике кабыкны кара каршы куеп, куянның аягын бәйләде. Язга чаклы өйдә тотарга туры килде. Авырткан аяк белән ишекне дөмбердәтә дә алмады, аннан соң язмышына буйсынды бугай.

Сулар китеп, чирәмнәр чыккач, җибәрдек үзен урманга. Менә шулай. Кыш көннәрендә әти урманнан эзен күреп кайткалады берничә тапкыр. Тәки азрак аксак булып калды бит шул эләгүдән.

— Менә шулай, нигә тынып калдыгыз? Кайгырмагыз бер дә. Укый башлагач, мәктәп куяннарын карарсыз. Менә үзем дә шул куян хәлендә калдым бит. Менә төзәлсен генә әле,— диде ул, гипслы аягына суккалап,— куян түгел, төлке баласын да эләктерермен, язган булса.

# Кое чыпчыгы

Минем апам бик зур шәһәрдә яши. Әни әйтә, анда өйләр шундый зур, кемнәр яшәгәнен дә белеп бетерә торган түгел, ди. Кызык та соң, әйе бит? Ничек инде ул үзең яшәгән өйдә кем торганын белмисең ди? Әгәр моны Диләрәгә сөйләсәң, ышанмый да ул, аннары тагы ялганчы булып калам. Каян белсен инде Диләрә, аның апасы да бик бәләкәй шул әле, читкә китәрлек түгел. Югыйсә ул да сөйләр иде Диләрәгә шәһәр турында.

Чынлап та, менә безнең өйдә кыр куянын, песине чутламаганда, әни, әти, абый, мин, сеңлем Әлфия. Әле мин безнең өйдәге кешене генә түгел, безнең урамның барлык, барлык кешеләрен беләм. Зурларны да беләм, кечкенәләрне дә. Исемнәрен дә беләм, кушаматларын да. Безнең авылда Наилләр генә дә җидәү бит! Каян аерасың аларны кушаматын белмәсәң?

Кемдер керен килә, ахрысы, капка тавышы ишетелүгә, урынымнан торып, тәрәзәгә карасам... урам ап-ак булган!

— Әни, әни, кар ява икән бит, нишләп әйтмичә торасың?! — дип, чөйдә эленеп торган бишмәтем янына атылдым.

— Беренче кар! Беренче кар! Ур-ра!

Әллә кайчаннан бирле беренче карны көтеп яткан чанамны эләктереп, Диләрәләргә йөгердем.

Алар турысына килеп җитүгә тәрәзә каршыларына бастым да:

— Диләрә, чык! Кар ява! Беренче кар! Мин беренче күрдем! — дип кычкыра башладым.

Диләрә дә чыкты чанасын өстерәп. Әллә-лә! Моңа яңа чана алганнар икән.

— Нигә шулай акырасың,— диде ул, бер дә сөенгәнен күрсәтмичә.

— Кар яуганны күрми каласың бит!

— Нәрсә дисең?

— Һи, шушының бер! Мактанчык! — дидем мин.— Харап икән, яңа чаналы булган икән. Ишетмәгән дә булып кылана. Бик беләсең килсә, былтыр минем дә чанам өр-яңа иде, шуашуа гына искерде. Үзең дә шуган идең бит!

— Ә минеке өр-яңа, мин бер кешене дә утыртмыйм!

— Утыртма! Үз чанам бар!

— Ә минекенең буявы да уңмаган,— диде Диләрә, чанасын бавыннан күтәреп минем борын төбенә китерде.

— Ярар алайса, карап тор шул чанаңа,— дидем дә, иске чанамны өстерәп, инде кар белән каплана башлаган тау ягына йөгердем.

— Тукта инде, мин дә барам бит,— дип, Диләрә дә минем арттан килә башлады.

Без тауга килеп җитүгә, абыйлар зур итеп кар бабай ясаганнар, борынына кызыл кишер, күзләренә кара күмер куйганнар.

— Әйдә, без дә үзебезнең кар бабайны ясыйбыз!

Кулларның туңуларын да онытып, зур «кар бабай» янына кечкенә «кар бабайлар» ясап куйдык. Алар шулхәтле кечкенә булып чыктылар, без аларга «кар малайлары» дип исем куштык.

Ә абыйлар һаман тәгәрәтәләр дә тәгәрәтәләр карны. Артларыннан җир чыгып кала, карлары да кап-кара булып беткән. Күп яуса да, беренче кар гына шул әле ул.

— Малайлар! Әйдәгез, безнең коега кар тутырабыз. Ну, шапылдап та төшә инде ул кое төбенә,— диде Мансур.

Алар тагы кар тәгәрәтергә тотындылар. Безгә кызык. Карның кое төбенә шапылдап төшкәнен ишетәсе килә. Тик алар безне коега якын да җибәрмиләр. Коелары бик тирән аларның, тирән булса да, бер тамчы да суы юк. Буш кое ул. Җәй көне олы кешеләр күмәргә кирәк, дип йөрсәләр дә, тагы калды шул көе.

Өч малай карны зур итеп тәгәрәтеп алып килделәр дә кое авызына китереп капладылар. Кар кысылды да калды. Төшми дә төшми.

— Менә шапылдады сиңа,— диде Рифат.— Әйттем мин сезгә зур итмәгез, дип!

— Һәй, куркаклар! — диде дә Мансур кое авызындагы кар өстенә менеп басты. Менеп басты да: — Күрдегезме абзагызны! — дип, кое кырыендагы баганага тотынып, тыпырдап та алды.

— Баганага тотынма син, тотынгач кем дә сикерә ала аны! — диде Илсур.

— Әйе, әйе, тотынмыйча сикер, батыр булсаң,— диештеләр малайлар.

— Тотынмыйчамы? Һи! Әллә сикермәс дип беләсезме? Бер, ике, өч...

«Өч» дигән аваз инде кое эченнән килде. Кары-ние белән Мансур да кое төбенә очты.

Кое өстендәге Мансурның кинәт юкка чыкканын күргәч, без шаккатып тордык та, бөтен көчебезгә кычкыра-кычкыра, өйләребезгә йөгердек. Малайлар кое авызына капланып калдылар.

Безнең тавышка чыккан әти-әниләр дә, без дә яңадан курка-курка кое янына җыелыштык. Мансурның әнисе судан кайтып килә икән, ул да, чиләк-көянтәсен ташлап, кое авызына капланды.

Кое эченнән Мансурның «Кар коймагыз...» дигән тонык кына тавышы ишетелде.

— Әй яшьти,— диде Рифат,— нәрсәләр бар анда, кое төбендә?

— Монда әйбер күп. Нурсаматтиның югалган казы да монда икән, малайлар!

Мансурның коега төшү хәбәре бик тиз таралып өлгерде, күрәсең, кое янына кешеләр җыела башлады.

Мансурның озын бау тоткан әтисе, кое баганасына тотынып, хәле бетеп басып торган Мансурның әнисенә инде ничәнче тапкыр бер сорауны бирә:

— Нигә безнең балалар гына коега төшә, нигә башкаларныкы җирдән йөри?!

Әнисенең әйтер сүзе калмаган, ул кулын гына селти, тизрәк чыгарыгыз, янәсе.

Ул арада Мансурны бау белән тартып та чыгардылар. Менә бәхете булгач, ичмасам, бер генә җире дә сыдырылмаган!

Шул көннән башлап Мансурга «Кое чыпчыгы» дигән кушамат тагылды да калды. Үзе гаепле. Мактанмасын иде.

## Яңалык

Безнең авылда көн дә бер яңалык булып тора. Кайсы көнне икәү дә була. Бүген тагы бер яңалык булды. Диләрәләргә читтән кунак кызы кайтты. Бездә аннан шәбрәк яңалыклар да бар ул. Әле кичә генә эти җигеп йөри торган ат колынлады. Аның матурлыгын күрсәгез, исләрегез китәр. Бу да яңалык бит!

Диләрә әйтә, бөтен яңа хәбәр дә яңалык була, ди. Нишләп алай булсын инде? Яңа хәбәрләрнең сөенечлесе дә, көенечлесе дә була. Кайгылы хәбәр яңалыкка кермәсен иде. Кайгы алып килә торган булгач, нинди яңалык була инде ул аннары. Кирмән очында ике ел буе яңа күпер салып бетерә алмыйлар. Салынып беткәч тә яңалык була алмый инде ул. Бар кеше дә белеп бетергәч, шул да булдымы яңалык!

Әле менә авылда иң шәп яңалык булды, Илсурның армиядә хезмәт иткән абыйсы исән-имин өйгә кайтты. Менә, ичмасам, яңалык! Бер кеше көтмәгәндә кайтты да килде.

Рәхәт тә соң авылда яңалык булгач! Иң шәп яңалыкларны клуб янында ишетәсең. Кибеткә әйбер кайтканны да иң беренче кем ишетә? Без, билгеле! Яңалыкны кем тарата? Тагы без инде — вак кызлар. Авылда безне шулай дип йөртәләр.

Менә кибеткә кеше килә башлый, кеше килә башлый... Кибетче җитешеп кенә өлгерсен. Хәер, анысы кибетчегә сүз әйтеп булмый. Шалт-шолт гер сала, ялт-йолт башкасын. Кулы кулга йокмый, ничек чутлап өлгерә дисең. Безнең авылда иң

башлы кешедер ул? Әле үзе барысын да сөендерә, барысының да күңелен күрә. Инде озак та үтми алып кайткан әйберләр дә бетә, кибет тә бушый. Тик соңга калган апалар ашыга-ашыга кибеткә керәләр дә:

— Су чиләкләрең булган икән, Садретдин, калдырмадыңмы? — дип сорыйлар.

— Әй түти! — ди Садретдин абый, әле һаман да китмичә нидер көткән апайларга күз кысып.— Чыгам да карыйм, чыгам да ник килмиләр болар, мин әйтәм, яңалык бит, су чиләкләрем бар иде... менә хәзер бетте шул...

Менә шундый яңалыклар безнең авылда. Аңламассың олыларның яңалыгын. Тик әле мин үзем дә яңалык булырга торам бит. Быел беренче класска укырга керәм. Башка урам кешеләре генә түгел, мине әллә кайчан белгән безнең урамнар да шаккатыр әле, букча күтәреп мәктәпкә барганны күргәч:

— И бу гомернең үтүләре! Сиңа да җиде яшь тулдымыни, үскәнем, менә сиңа яңалык! — диярләр.

## Сөенче

Безнең әти күп сөйләшми. Ә менә бүген төшке ашны ашаганда:

— Кыр башындагы бодайны суктырдык. Без төшкелеккә кайтканда, Габделбәр сарык көтүен Бурсык елгасына төшергән иде инде...— диде.

Габделбәр — безнең авылның көтүчесе ул. Әллә ничә ел көтә инде ул сарык көтүен. Аның шундый озын чыбыркысы бар. Чыбыркының башы авылның бер ягында булса, очы икенче ягында кала. Авылыгыз бәләкәй икән дип уйлый күрмәгез тагы. Чыбыркысы озын Габделбәрнең! Ул аны көн дә озайта әле. Көтүдән кайта да тотына чыбыркысын озайтырга! Көненә ничә мәртәбә шартлата торгандыр ул чыбыркысын, күп инде, мең тапкыр булыр. Ә бит шартлаган саен, очы китә, очы киткән саен, яңадан ишәргә кирәк... Карале, мин әти әйткән сүзне сөйли башлаган идем. Каян килеп керде бу чыбыркы.

Менәтерә шул, Габделбәр абый этигә Әминә җиңгинең сарыгы бәрәнләде, килеп алсыннар әле, дип әйтергә кушкан.

— Әнисе, кызларның берсе барып әйтсен,— диде әти.

Берсе дип, Әлфия бара аламы соң анда? Билгеле, мин барам инде. Чәемне дә эчеп тормадым, шикәрне авызга каптым да ялт өстәл артыннан! Әлфия тагы миңа иярә инде. Каламы соң ул миннән! Кычыткан беләнме? Тиеп кенә кара, бөтен авылынны җыяр.

Өйдән чыгып йөгердек. Арттан капка ябылып беткәнче, без инде ярты юлны үткән идек. Аннары җитәкләшеп йөгердек. Әминә җиңгиләр турына җитәрәк бераз туктап тын алдык та капкаларына атладык. Аларның этләре дә юк, әле безнең ишеләргә капка келәләренә буй җитәрлек итеп бау да асып куйганнар. Баудан тартасың да, капканы этәсең. Арттан капка әкрен генә үзе ябылып кала. Ә чыкканда барыбер ачып чыгаручы кирәк.

Без кергәндә, Әминә җиңги өйалды күләгәсендә май язарга дип, чүлмәктә каймак туглап утыра иде.

— Исәнме, Әминә җиңги! Әти әйткән иде, барып алсыннар, дип. Әти әйткән иде, алып кайтсыннар, дип.

— Нәрсәне алып кайтсыннар дип әйткән иде әтиең?

— Сарыгыгыз бәрәнләгән бит! Көтүче Габделбәр абый әйткән, безнең әтигә әйткән...

Эшен ташлап безне тыңлаган Әминә җиңги бу хәбәргә бик тә шатланып:

— Әй, кара син аны! Кысыр калды дип йөргән идем, менә рәхмәт яугыры! — дип сөйләнә-сөйләнә чоланга кереп китте. Эшне беткәнгә санап, чыгып китәбез дип, Әлфиянең кулыннан тотуга, ул чүлмәк ягына ымлады. Анда сары күзле кап-кара мәче, безне искә дә алмыйча, Әминә җиңгине юкка санап, каравылчысыз калган чүлмәктән каймак ялый иде. Шушы минутта чоланнан Әминә җиңги килеп чыкты. Мәчесенең тәртибен яхшы белгәнгәдер инде, аның күзе иң башта безгә түгел, каймак чүлмәгенә төште.

— Кара син аны, гадәтсезне, прәссс!

Мәче китәргә уйлап та карамады, муенын гына җыерды да, чүлмәкнең икенче ягыннан чыгып, үз эшен дәвам итте.

Җиңги икебезгә дә берәр күкәй тоттырды да елмаеп:

— Мәгез, балакайларым, сөенче сезгә! Рәхмәт яусын, озын гомерле булыгыз, бәхетле булыгыз... — диде.

Без дә рәхмәтләребезне әйтеп күкәйләрне алдык та капкага таба йөгердек. Капканы ачып чыгаргач, Әминә җиңги безнең арттан:

— Вата күрмәгез, пешмәгән алар! — дип кычкырып калды.

Аның шул сүзләреннән соң мин:

— Үскәнем, ялгыш төшереп ватарсың, китер, үзем генә тотып кайтыйм, — дидем Әлфиягә.

Алырсың Әлфиядән әйбер. Саран да соң инде. «Барыбер вата ул аны, менә күрсен дә торсын әле» дип уйлап та бетерә алмадым, үземнең кулымдагы күкәй җиргә төште дә китте. Сеңлем алдында оят булды. Күкәйнең кабыгы икегә бүленеп, ике якта ятса да, ышанмадым, кап-кара җирдә яткан, сөенечкә биргән күкәйнең сарысын кулыма алырга тырыштым. Юк шул, бер ватылгач җыеп булмый икән аны! Әлфиянең иярүенә дә

ачуым килде. Әниләргә кайтып сөйләсә, миннән көләләр дә көләләр инде.

Ләкин сеңлем минем яныма килде дә:

— Елама инде, беркемгә дә әйтмәбез, минекен дә тавык оясына куярбыз, яме,— диде.

## Ипи пешерәбез

— Бездә ипи беткән көнне, күршеләрдә дә шул ук хәл. Ике-өч кадак кына әҗәткә алып торырмын дигән идем, булмады бу,— диде әни, күәс төбендәге әче камырны җебетеп.— Бик вакытсыз була бит әле бу. Хәзер изеп куйсам, төшкелеккә кайткач мичкә салыр идем дә бит, эштән кайтканчы мичтә ятарга калсалар, ике катланып бетәрләр. Нәрсә эшләргә соң? — диде ул, әтигә карап.

— Өй саклаучы олы кызың бар бит синең. Мичтән ипи чыгарырга да ярамагач, нигә ашатабыз аңа ул ипине? Әйеме, кызым? — диде әти.

— И-и-и, әйе шул. Кара әле, алай бергәләп пешерәсе булгач, бер чүмеч сөт тә өстим әле, онны да вак иләктән иләргә кирәк. Тәмлерәк булсын!

Миңа канат үскәндәй булды. Ипи пешерү уен эш түгел ул. Менә пешереп карагыз әле! Мин хәзер кул арасына керә башладым инде, әни шулай ди. Алар мактагач, үземә дә рәхәт. Тизрәк үсәсе килә бит. Ә менә мондый эшләрне бәләкәй кешегә кушмыйлар! Хәзер бәрәңге дә әрчи беләм, идән дә юам. Әни мине өйрәтеп тора. Эшләвең безнең өчен булса, өйрәнүең үзең өчен булыр, ди. Бәрәңге әрчегәндә минем кырыйда утырмаса да, әрчегәнне күрмәсә дә сизә шул калын әрчегәнне:

— Кызым, әллә калын әрчисеңме,— дип куя.

— Каян беләсең,— дим мин кече яктан.— Күрмисең дә бит?

— Әрчүеңнән тураган тавыш килә бит. Башлаганда юка итеп ал, кабыгын өзмәскә тырышып әрчеп кара. Үзеннән-үзе юка әрчелер.

Их, булмый шул юка әрчеп. Бәрәңгеләре шулкадәр эреләр, кулга да сыймыйлар. Аптырагач, сәке йөзлегенә куям да юнам гына. Әрчегәннән соң бәрәңгеләр кечкенә генә, минем кулга сыярдай булып кына калалар.

Ә менә бүген, үз гомеремдә беренче мәртәбә, ипи пешерергә булышачакмын. Бу инде бәрәңге әрчү генә түгел, ипи салу иң олы эш ул безнең өйдә.

Әни алты олы ипи, бер бәләкәй ипи әвәләп куйды. Бәләкәй ипинең уртасына тамга да салды.

— Монысын кендек әбиенә кертерсең, яме, кызым?

Әни ипи пешергән саен шулай итә. Минем кендек әби, минеке генә түгел, безнең очтагы байтак кына балаларның кендек әбисе, күршедә генә яши торган Мөгаллимә карчык. Ул берүзе генә яши. Хәзер картайган инде, күзләре дә начар күрә башлаган. Без, кызлар, аңа чишмәдән су алып кайтабыз, идәнен юабыз, өен җыештырабыз. Аннары ул безнең барыбызга да «тәти кулың» кайсысы, дип сорый-сорый йә чикләвек, йә конфет өләшеп чыга, аннары озын-озын итеп рәхмәтләр укый.

— Юылган идән бигрәк күңелле шул, аякларга йомшак тия,— ди ул, без юган идәнгә баскач.

Ә менә бүген мин ипи пешерүче.

Әни ашыга-ашыга ипиләрне мичкә тыкты да:

— Кабартмыйча да йөдәтте, нәрсә булып чыгар бу ипиләр. Эшкә соңга калам инде. Әй син аны! Морҗа ябылмаган икән бит, әйтәм ипиләрем мичкә тыгуга җәелеп китте! Кызым, бар тизрәк яп морҗаны! Башта тәлинкәләрен капла, аннары гына юшкәсен этәрсең! — диде әни.

Мин әллә кайчан мич башында инде. Боларын әни әйтмәсә дә беләм. Беренче тапкыр морҗа ябу түгел лә! Әгәр дә иң башта юшкәсен этсәң, тәлинкәләрен каплаган чагында мичтән торбага таба чыга торган кайнарлык кулыңны өтеп кенә алыр. Бер-ике тапкыр кул пешсә, бутамаска өйрәнәсең аны. Көне буе өйрәтәләр, көне буе! «Беләсеңме» дип сораучы юк. Бүген дә шунсыз булмады.

— Ярый, мин киттем,— диде әни, алъяпкычын алыштырып. — Йөзен китерергә күмер күп куймадым, шулай да, сәгатьнең минутлыгы дүрткә җиткәч, мич капкачын ач та, күмерләрне кече учакка күчер, яме, кызым. Яңадан мич капкачын ябарга оныта күрмә! Минутлыгы уникегә җиткәч, ипиләрне мичтән чыгар!

Әни йөгереп диярлек өйдән чыгып китте.

— Уф-ф!

— Берүк вакытында чыгарырга оныта күрмә! Ишетсен колагың! Ипиләрне мичтән алмыйча урамга чыкма!

Боларын әни урамнан, ачык тәрәзәдән кычкырды.

— Ярар, ярар!

Тагы бер мәртәбә «уф-ф» дидем дә, сәгать каршысына утырып, минутлыкның уникегә җиткәнен көтә башладым.

Сәгать йөри йөрүен, тик минутлыгы ник кенә урыныннан кузгалсын! Карап тора-тора күзләрем авыртып бетте. «Келт-келт, келт-келт. Чык-кит, чык-кит» дип котырта мине сәгать.

Кинәт кенә урамнан безнең якка таба якынаеп килүче җыр, гармун, кыңгырау тавышлары ишетелде.

Ачык тәрәзәгә тарттырып куйган марляны күтәреп урамга карасам... Әнекәйләрем! Әллә иртәгә сабан туе микән? Сөлгеләр, яулыклар белән бизәлгән атлар! Аларга ияргән бала-чага урам тулы! Атларны күрсәң! Йөгәннәрендә генә дә әллә ничә кулъяулык! Ул сөлгеләр дисеңме, чуклы дилбегәләр! Безнең турыдан аз гына үтүгә арбадан коелып төштеләр дә, кемнедер... ә-ә Хатипның абыйсын икән, һавага чөяргә тотындылар! И-и, бүген бит аны армиягә озаталар! Алар турысындагы кешене күрсәң! Ай-й тәрәзәдән егылып төшә яздым. Күпме генә сузылып карасам да, барысы да күренми шул. Аларның өйләре дә безнең якта, җитмәсә, Сәмигулла абыйның бурасы ярты урамны каплаган. Их, ничек кенә чыгасы урамга! Әй шушы сүз тыңлаулар харап итә кешене!

Ул арада күзләрен тасрайтып, йөгерүдән тыннары беткән Диләрә дә кереп җитте.

— Нишләп өйдә утырасың, тиле! Әйдә Хатиплар турына!

— Килеп керүгә «тиле!» Ипи пешерәм мин бүген!

— Син? Ипи пешерәсеңмени? — диде ул сузып, «тиле» дигән сүзе өчен гафу үтенгән сымак... — Урамда бәйрәм, ә син бу эсседә утырасың, дип кенә әйткән идем.

— Әй, бик чыгар идем дә бит... Әни мичкә ипи салып киткән иде шул, аларны чыгарасым бар! Урамга шундый чыгасым килә!

— Әйдә, чыгар тизрәк ипиләреңне!

— Минутлыгы уникегә җиткәч кенә чыгарасы шул. Ә минутлык урыныннан кузгалырга уйламый да.

Сәгатькә карасам...

— Юк, юк, күчкән икән азрак. Бигрәк әкрен йөри безнең бу сәгать. Ничек кенә тизләтергә инде моны?

— Сәгатьне тиз йөртер өчен нәрсә эшләргә кирәкне дә белмәгәч! Ипи пешерәм дигән була тагы.Сәгать геренә авыррак әйбер асарга кирәк!

— Асты ди менә...

— Беләсең килсә, безнең әбиләрнең сәгатьләрендә ике кадаклы гер, аннары трактор гайкасы, тагы әллә нәрсәләр эленеп тора. Бабай моңа хәзер арба күчәре генә тагарга калды инде, дип көлә, сәгатьләренә карап. Тик менә күрсәң, сәгатьләре йөгереп йөри!

— Йөгерде ди синә. Стена буйлап йөгерәмени? Шулхәтле авыр әйберләр белән.

— Киттем мин, алайса, ышанмасаң...

— И-и, малай, тукта инде! Көт инде мине дә. Әнекәем, минутлыгы дүрткә җиткән бит! Менә әкрен йөри дигән идең!

Урамнан җырлаган, көлгән, гармун уйнаган тавышлар ишетелүдән туктамый.

Диләрә кул гына селтәде дә урамга чыгып йөгерде. Мин, ипи йөзе китерергә дип куйган күмерләрне күчерергә дип, мич янына атылдым. Бәреләсугыла чыгып йөгергән Диләрә артыннан башта шак иттереп ишек, аннары дөңгердәп капка ябылып калды. Әти өйдә булса: «Баганасын аударды!» — дип кычкырыр иде инде.

Мич капкачын ачсам! Ипиләр кызарып чыккан. Ярый әле болары сәгатькә карап тормыйлар, пешүләрен беләләр.

Мин яңадан тәрәзәгә башымны тыктым. Яшь кызлар да җыелган, ахры. Шап-шоп биегән, кул чапкан тавышлар ишетелә. Их, үзләрен күреп булмый шул!

Ул арада Диләрә тагы кереп җитте. Әни әйтмешли, күзләре урыныннан купкан. Үзе сөйли, үзе кабалана:

— Һаман утыра! Хәзер тагы урам әйләнәчәкләр! Күрми каласың бит! Әй, сезнең бу сәгать сәгатьмени! Шуңа ышанып ипи пешерергә. Әйдә әле, ярдәм итик үзенә азрак!

Без икебез сәгатьнең ике ягына бастык та сәгать телен мин Диләрә ягына, Диләрә минем якка атындырырга тотындык. Диләрә сәгать теленә бәргән саен: «Тизрәк, тизрәк!» — дип кабатлый.

— Тегеп куйганнармы әллә моның минутлыгын? Һаман бер урында тора бит бу! Тавышын гына тыңлап кара әле син аның? Аксак-туксак йөри бит сезнең сәгать! Менә болай итсәк... — Диләрә ике куллап сәгать геренә тотынды да аска тартып тора башлады.

— Күрдеңме ничек шәп йөреп китте! Тавышы да гел икенче! «Чык-чык, чык-чык» ди! Рәтле сәгать шулай йөрергә тиеш! Берәр авыр әйбер тап әле, хәзер төзәтәбез аны. Мин болай асылынып торсам, бернәрсә дә күрми калам бит.

Мин йөгерә-йөгерә өй бетереп авыр әйбер эзли башладым.

— Аш чүмече ничек булыр икән?

— Бара, бара! Китер тизрәк! Бусы гына аз шул әле! Тап инде авыррак бернәрсә!

— Самавыр капкачы?

— Китер монда, хәзер бәйләп асабыз!

Сәгать чынлап та кызурак йөргән сымак итә. Тырыша мескенкәем, ул да ипи пешерә бит.

Әй урамда җырлыйлар!

Яшь гомерне үтә, диләр,
Үткәнен күрсәң иде,
Үткән чакта тотып алып,
Кирәген бирсәң иде.

— Их, күрми калабыз бит! Ничек итеп кирәген бирерләр икән! Син ипиләреңә кара, мин тиз генә әйләнеп керим әле!

Диләрә очып диярлек чыгып китте.

Мин кара кайгыда, ә анда җыр, көлеш. Нинди генә әмәл уйлап табасы моңа! Аптырадым бу сәгать белән. Ничек кенә уникегә җиткерәсе моны! Таптым! Таптым! Тиз генә урындыкка бастым да, минутлыкны борып, уникегә җиткердем дә куйдым. Уф! Менә бәхет булгач! Җиңел күчә икән ул. Әни әйткәнчә булды хәзер. Сәгатьне җиткереп куйдым, ипиләр пешкәндер инде. Капкачны ачып, мичтән ипиләрне чыгарырга тотындым. Син ашыкканда, ул кабалана, диләрме әле? Кисәү агачы йә мич төбендәге кирпечкә эләгә, йә ипи эченә кереп китә. Көчкә-көчкә, пешә-пешә ипиләрне сәкегә чыгарып тездем дә урамга йөгердем.

Ә урамда, ә урамда! Сабан туе диярсең! Мин чыгуга, урам тузаннарын туздырып, ике абый биеп тә киттеләр! Яшь кызларны да уртага чакыралар. Ә тегеләре тартынган булалар, үзләре биергә дип килгәннәр бит инде. Шулай да озак ялындырмыйлар, гармун көенә атлап-атлап баралар да пыр туздырып биеп тә китәләр. Калганнары түгәрәккә тезелгәннәр дә урыннарында тыпырдап кул чабып торалар. Чиратларын көтәләр, әни әйтмешли, тояк кыздыралар. Их, ничек кенә тизрәк үсәсе инде!

Бию беткәч, барысы да гөрләшеп, ат җигелгән арбаларга утырдылар да авыл көенә җырлап, тагы бер мәртәбә урам әйләнергә киттеләр. Без алардан калабызмы инде! Бар урамнарны әйләнеп чыкканнан соң, авыл башына чаклы озата бардык үзләрен.

Өйләргә таралганда, авыл тынып калган, кич булган иде. Дөньяны оныту шушы була, ахры... Өйдә нинди хәлләр бар микән. Капкадан әкрен генә кердем дә, өй ишеген шыгырдатмаска тырышып, сак кына ача башладым. Өйдә әни белән кендек әби тавышы. Ишек ярыгыннан гына аларның сүзләрен тыңлыйм. Минем турында сөйлиләр бит...

— Менә монысы сиңа, Мөгәлимәтти,— диде әни, тамгалы ипине кендек әбигә тоттырып.— Кызың пешергән, пешкәне дә шушы, бәләкәй ипи.

— И-и-и, кызың үсте, Мәүҗидә,— диде кендек әби.— Шушындый олы эшкә ярагач...

— Үсте-үсте, үсмәгән кая ди ул. Әнә әрмиягә егетләр озатып йөри... Шуны әйтеп торам бит, бер мич чиле-пешле ипиләрне чыгарган да тезгән! Валчыгын да калдырмый ашатам үзләренә, икенче юлы аң булыр! Нишләтергә инде бу кызны? Әйтеп киттем, минутлыгы уникегә җиткәч кенә ал мичтән ипи-

ләрне, дидем. Сәгатькә генә күз сал әле син! Ничаклы әйбер аскан бит! Ничек кадагы сынып, сәгате идәнгә очмаган диген!

Мин атылып өйгә кердем.

— Әни! Уникегә җиткердем бит мин аның минутлыгын! Бик җиңел күчә икән ул. Ипиләр пешмәгәнмени?

Әни моңа каршы бер сүз дә әйтерлек түгел иде. Аңламассың боларны: мин тырыштым, сәгать тырышты — ипиләр чи калган... Кече яктан кулына ипи тотып, әти килеп чыкты. Ну, эләгә хәзер...

— Ярый инде, әнисе,— диде ул. — Беренче коймак табага ябыша, диләрме әле. Чиерәк булса да, ашамаслык түгел бу. Кыерчыгы бигрәк тә тәмле. Кызым пешергән ипи бит, әйеме, кызым...

## Ярты хәреф

Әле сәгать алты да тулмаган, сумкасын күтәреп Диләрә кереп тә җитте. Мин дә озак йокламадым да бит, Диләрә иртәрәк торган. Әй, әнисе уяткандыр әле, уятсалар, аны мин сәгать өчтә торып утыра алам.

— Тавык кетәклектән төшмәс борын, кеше борчып, кай арада кереп киткән,— дип, урамнан ук сөйләнә-сөйләнә Диләрәнең әнисе Нәсимә апа керде.

— Исәнмесез! Әйдә, балакаем, чыгып тор. Әлфирә тамагына да ашамаган бит әле.

— Чыгып торсам, соңга калабыз, менә күрерсең дә торырсың. Кирмән балалары әллә кайчан китте инде.

Кирмән балалары — безнең авылдан өч чакрым ераклыкта Кирмән урта мәктәбендә укучылар.

Минем әни чәй әзерләп йөри иде.

— Ярар, калсын инде, Нәсимә, бергәләп чәй эчәрләр. Әйдә әле үзең дә утыр өстәл янына,— диде ул.

— Рәхмәт, кая ул утырып тору! Көтү куа башларлар, әле сыерым да савылмаган,— дип, Нәсимә апа чыгып китте.

— Диләрә, утырып тор, мин хәзер булам...

— Син бик иркенләмә инде, дәрескә соңга калсак, бер дә кызык булмас.

Диләрә урындыкка утыру түгел, сумкасын да куймады. Китап тулы сумкасының авырлыгыннан рәхәтләнеп, ул аны әле бер кулына, әле икенче кулына күчереп, сабырсызланып мине көтте.

— И укучы кешегә ишек төбендә басып тору бер дә ки-

лешми инде. Кил әле, утыр өстәлгә якынрак,— диде әни Диләрәгә.

Диләрә сак кына диван кырыена утырды да, кып-кыска күлмәк итәген сыпыргалап:

— Әлфирә, күлмәк итәгемә утыра күрмә, әле яңа гына апа үтүкләп бирде,— диде.

Ул шулай диюгә, әни көлеп җибәрде.

— Соң балакаем, тезеңә дә җитмәгән итәгеңә кем утыра алсын ди! Әй Диләрә, Диләрә! Укучы булдым дисең дә бит, башмакларыңны да кия белмисең икән, карале, уңын сулга кигәнсең.

— Гел онытам шуларның бер сыңарын дөрес кияргә. Берсен дөрес кисәң, икенчесе дөрес киелә инде үзе аның!

Мәктәпкә барырга Диләрә генә түгел, мин дә ашыгам. Ашыксам да, үземнең укучы булуымны истә тотып, сабыррак булырга тырышам. Сумкадагы әйберләрне барлап, китап, дәфтәр, каләм, карандашларны тагы бер мәртәбә тикшердек. Онытып калдырсаң, өйгә йөгерә алмассың.

Безнең урамнан быел беренче класска баручылар бер без генә түгел, Фәния, Хатип, Рифат та бар. Без Диләрә белән җитәкләшеп капкадан чыкканда, Фәния белән Хатип та безнең турыга якынлашып киләләр иде. Күршеләргә чаклы, озатырга дип, безнең капка төбенә җыелганнар.

— Хәерле сәгатьтә, балалар!

— Бишлегә генә укыгыз!

— Укытучыларыгызны тыңлагыз!

Йөгерми генә, олы кешеләр кебек атлап, мәктәп ягына киттек. Азрак баргач борылып карасак, барысы да кул болгыйлар. Әйтерсең армиягә озаталар. Әллә әни елый да инде? Олы каен турысына килеп җиткәндә, Диләрә үзләренең кара тавыгын күреп алды.

— Каракай, нишләп йөрисең монда? Бар кайт, иптәшләрең рәхәтләнеп күкәй салып утыралар,— диде.

Каян барысын да таный бу Диләрә? Ул бүген барысы өчен дә үзен җаваплы дип саный бугай. Ә минем күзгә ак-кара күренми. Тизрәк мәктәпкә кереп парта арасына утырасым килә.

Укытучы апа белән дүртенче класс укучылары мәктәп капкасы төбендә безне каршы алдылар. Кыңгырау чылтырады. Без Диләрә белән беренче партага утырдык. Укытучы апа барыбызга да дәфтәрләр өләшеп чыкты.

Кем нәрсә дип яза белә, шуны языгыз, диде.

Безнең артта утыручы Рифат ручкасын оныткан икән.

Ул урыныннан торып басты да «апа» дип әйтәсе урынга:

— Бабай, әби, әй... әни! — дип кычкырып җибәрде. Бары-

быз да көлә башлагач, оялып нәрсә әйтергә белми торды да аннан парта астына төште дә китте.

— Балалар! Сез хәзер укучылар инде. Мин сезгә укучылар дип эндәшермен. Тәртипле, игътибарлы булыгыз. Ашыкмагыз, әйтәсе сүзегез булса, уң кулыгызны күтәрегез. Чык, чык, Рифат, парта астыннан, анда утырсаң, күп нәрсәгә өйрәнә алмассың,— диде укытучы апа.

Дәресләр бетте. Укучы булганны бөтен кешегә дә белдерәсе килгәнгә, әйләнгечтән юл яхшы дигән булып, өйгә турыдан гына түгел, олы урам аша кайттык.

— Йә, сөйлә, укучы,— диде әти,— бик авыр түгелме укулар?

— Укулары ничектер, букчасы бик авыр моның,— диде әни, кулымнан букчамны алып.

— Нишләп авыр булсын ди укуы. Без бит әле ярты хәреф кенә өйрәндек.

— Ярты хәреф буламыни?

— Укытучы апа була, диде. Хатип та: «Мин таяк сызып тормыйм, озак, бүген үк сүзләр язарга өйрәнәм»,— дигән иде, апа әйтте:

— Укучылар! Бу гади таяк кына түгел, А хәрефенең яртысы, диде. А хәрефенең ничек төзелгәнен, ничек язылганын белмәгән кеше бер сүз дә яза алмаячак, диде.

— Бүген хәрефнең бер ягын өйрәндек, иртәгә икенче ягын өйрәнәчәкбез. Өйгә эш — өч юл сызарга.

Мин тырыша-тырыша дәфтәремә буй-буй таяклар яза башладым. Бөтенесе дә А хәрефеннән башлана, диде бит апа. Бүген беренче яртысы, иртәгә икенче яртысы. Бик күп нәрсәләр беләчәкбез икән әле. Мин белмәгән нәрсәләр күп икән бу дөньяда.

## Шәмсивафа әби гөле

— Ишегалдына чыпчык эчәрлек су җыелса, гөл чүлмәкләрен баздан алып тәрәзә төбенә куярга вакыт җитте дигән сүз.

Безнең әни шулай ди. Яз башы гына булса да, ишегалдына чыпчык эчәрлек кенә түгел, чыпчык керсә батарлык та күл җыелган бүген кар суыннан.

Шуңа күрә бүген әни белән баздан гөл чүлмәкләрен чыгардык та, тазга су салып, тышларын юдык, балчыгына сулар сиптек. Гөлләрнең дә гөл дип әйтерлекләре калмаган, тамыр да сабак кына.

— Әни! Нигә дип базга төшердең инде син бу гөлләрне? Әрәм булып беткәннәр бит караңгыда!

— Сезгә салкын тимәсен дип.

— Гөлләр базда булганга тимәдемени безгә быел суык? И-и, әни! Гел шаяртасың син, әйе бит?

— Уены-чыны бергә, кызым. Былтыр тәрәзә төбендә гөлләр калдырыйк дип, тәрәзәләрне ике катлы куймаган идек, тәрәзәгә арка куеп утырып та булмады, салкын булды, җитмәсә, тәрәзә астына су китте. Менә быел ике кат куйдык. Тәрәзә ике катлы булгач, гөлләр утыртып булмый шул. Урын калмады аларга.

— Быел, кызым, гөл үстерү синең кулда. Син үрнәк булырга тиеш. Үзең апа, үзең укучы,— диде әни.

Тырыша-тырыша чүлмәкләрне юып сөрттем дә бер-бер артлы мич казнасы янына, идәнгә тезеп куйдым.

— Беттеме? Булдымы? Булса идәндә калдырма, тәрәзә төбенә куй син аларны. Биредә генә калсалар бик мантый алмаслар. Кояш, җылы кирәк аларга,— диде әни.

— Әни! Кара әле, менә бу чүлмәктә гөлнең әсәре дә юк. Тамырына кадәр корыган. Нишләтик икән, әллә кире базга төшерәбезме?

— Юк инде, чүлмәге булса, гөле табылыр. Шундый матур чүлмәкне гөлсез калдыралар димени! Шәмсивафа әбиеңнән кына гөле сабагын алып кайтып утырт әле шуңа. Аның гөлләре кыш көне дә чәчәк ата. Тиз үсә ул. Чәчкәләре дә бик матур ул гөлнең. Безнең гөлләр арасында андые калмаган да. Үзең үстергән гөл булыр. Бар, кызым...

— Хәзер, әни, Диләрәләргә керәм дә...

— Агылый белән тагылый! Берүзең күтәрә алмам дип куркасыңмы әллә?

— Бергә барабыз! Аларның да гөлләре базда бит! Әле классны бизәргә дә берәр чүлмәк гөл алып төшәсе бар мәктәпкә!

Әй күрсәгез икән сез Шәмсивафа әбинең гөлләрен! Без аңар кергән саен гөлләренә кызыгып карыйбыз. Бер тапкыр мактаган идек тә, Шәмсивафа әби ярты сүздә туктатты: «Кызларым! Гөлләремә күз генә тидерә күрмәгез!» — диде. Кабат әйтмәс булдык. Без Диләрә белән еш кына күршедәге ул әбигә ярдәм итәргә кергәлибез.

Безнең авылда Шәмсивафа исеме анда гына. Бәлки, андый исем башка беркемдә дә юктыр. Мин аннан нигә сиңа андый исем кушканнар, дип тә сораганым бар.

— И-и! Кызым! Мин малай булып тумаганга әти ачуланган да шундый исем куйган миңа. Ике ир-ат исеме бит минем атымда — берсе Шәмси, икенчесе Вафа! Минем дүрт апам

булган инде мин туганчы. Бишенчесе мин — тагы кыз бала! Ә апамнарның исемнәре бик матур иде. Йөзек кашына язып куярлык иде! Хәзер андый исемнәр юк инде. Бала-чагага кушмыйлар дип әйтәм. Карт-корыда гына калды ул исемнәр. Олы апаның исеме, без аны «Апакай» дип йөртә идек — Мәраризә иде, аннан кечесе — анысын «Түти» дип атый идем — Газизә исемле, аннан кечерәге — «Аппактүти»нең исеме Гөлфаһидә, ә инде миннән бер генә яшькә олы булган «Нәни апа»ның исеме — Шаһидә иде. Әни шулай барыбызны да әйтеп — Мәраризә, Газизә, Гөлфаһидә, Шаһидә, дип санап китә дә, аннан соң авыз тутырып — Шәмсивафа! дип куя торган иде. Малай, малай дип өметләнгән этигә җитә калган шул. Ике малай исемен бергә кушкан. Берүземә ике исем дип, берьялгызым яшәп ятам менә. Ярый әле сез бар... күңелләремне юатырга!

— Шәмсивафа әби, бәләкәй чактагы карточкаңны күрсәт әле. Шәмсивафа исемле бәләкәй кыз нинди була микән ул?

— Без бәләкәй чакларда андый нәрсәләр юк иде шул.

Шулай да бик үк ышанып бетмәдем мин аның сүзләренә. Бәләкәй кызга кемнең эти-әнисе шундый ике катлы бабайлар исеме кушсын инде? Бу исемне аңар картайгач кына кушканнардыр әле. Шулай була микән ул...

...Диләрәләргә керсәм, ул да гөлләр белән маташа. Аның гөлләре әйбәтрәк сакланган. Хәтта яран гөле яшәрә дә башлаган. Нечкә генә саргылт-яшел тармак та җибәргән.

— Менә күрдеңме! Яз җиткәнен базда яткан гөл дә сизә икән! — диде Диләрә.

Әбисе сүзен кабатлый. Карчыклар сүзен кабатлап борынгы бишлеккә әйләнеп беткән инде ул. Аның сүзенә һич җавап тапмассың!

— Диләрә, буш чүлмәкләрең бармы?

— Ярты баз!

— Әйдә, Шәмсивафа әбигә гөл сабагына керәбез! Зуррак сабак бирсә, мәктәпкә дә алып төшәр идек. Әни әйтә, гөлләр сабактан да үсеп китә, ди.

Гөлләр белән булашучылар без генә түгел икән бүген. Шәмсивафа әби дә гөлләрен коендырып йөри иде без кергәндә.

— Әйдүк, кызларым, әйдүк. Сез кергәч, өйләрем яктырып китте. Менә яз да җитте. Бу язларны да күрермен димәгән идем. Яз җиткәч яшәреп тә киттем әле,— дип каршылады ул безне.

Без аңар гөлләрен урнаштырырга ярдәм иттек. Су чәчрәгән җирләрне генә түгел, өенең идәннәрен дә юып чыктык. Йөгерә-йөгерә Олы чишмәдән су да алып кайттык... Эшләр беткәч кенә үтенечебезне белдердек.

— Гөл сабагы дисезме? Әй балалар, бер дә белмим шул инде. Кайсы гына тармакка тисәң дә, бигрәк тә жәл бит әле...

Ул бөтен почмакны биләп, тармакланып үскән кына гөле тирәли әйләнеп йөри башлады.

— Монысын сындырсам инде... Юк, юк. Бөресе дә бар икән, тиз генә үсеп китә алмас... Әллә бу бәләкәен өзсәм инде...

Гөл сабакларын сындырып бирергә әбинең һич тә батырчылыгы җитмәде.

— Кызларым, тыңлагыз әле, сабагын сындырып рәнҗетмик әле гөлләрне, орлыклар гына бирим үзегезгә? — диде аптырап.

— Орлыклар?..

Шәмсивафа әби бер тартма чыгарды. Аннан бәләкәй-бәләкәй чүпрәк янчыкларга салынган гөл орлыкларын бүлеп безгә дә бирде.

— Рәхмәт, әби. Аларын да утыртырбыз. Тик безгә тиз генә үсеп китә торган гөл кирәк иде шул.

— Шулай дисезме? Ярый, килегез әле якынрак. Карыйк әле... Ничек кенә сындырасы соң, бер дә кулым бармый бит!

Ул шулай, авыр сулап, байтак кына вакыт гөлнең әле бер, әле икенче ягына чыгып йөри торгач, ике кечкенә тармакны сындырып алды.

— Рәнҗемә инде, гөлкәем, саваплы эш бит, кызларымны гөл үстерергә өйрәтәм,— дип, үзен дә, гөлне дә тынычландыргандай итте.

Безгә бирәсе гөл тармакларын икесен ике кулына тотты да бик матур көйләп җыр әйтте.

И гөлем, гөлгенәм,
Бәгырем күңел генәм.
Явызларга суган бул,
Ай-кояшка туган бул!

— Име-томы шушы җырым булсын. Хәзер инде уен дип беркая да тукталмагыз, йөгерегез өйләрегезгә. Җылы балчыкка утыртып, су сибәргә онытмагыз! — дип кычкырып калды ул безнең арттан.

Өйгә кайткач теге матур чүлмәктәге балчыкны йомшартып, күп итеп су сиптем. Ә гөл сабагын, әйтергә дә онытып торам икән, кайту белән сулы стаканга утыртып куйдым. Сәяхәтче гөл тармагы чүлмәктә үзенә урын әзерләгәнне тыныч кына көтеп торды. Бу тикле суны үз гомерендә беренче мәртәбә күрүедер әле. Сабагыннан башка җиргә барганы юк бит аның. Гөл сабагы ниләр уйлаганны мин инде әйтә алмыйм, ә менә минем әле яңа гына тәпи йөрергә өйрәнеп килгән энем бу хәлләргә һич тә тыныч кына карый алмады. Гөл утырткан стаканны кайда гына куйсам да, аякларын киң итеп басып, идән-

нән күтәрелә һәм гөл тармагына күрсәтеп учларын җәя. Бармакларын тырпайтып чакырган төсле итә, үзе «Мә, мә!» ди. Әле аның «бир» дигәне дә «мә», «мә» дигәне дә «мә».

— Бик оста икәнсең, «мә»ләми тор әле!

Гөлемне тагы икенче урынга күчердем дә икенче бер чүлмәккә әби биргән орлыкларны да чәчтем. Тишелеп чыккач, тәрәзә каршындагы бакчага утыртам мин аларны.

Шәмсивафа әби биргән гөл тармагымны иң матур чүлмәккә бик кадерләп кенә утырттым да тәрәзә төбенә куйдым. Чүлмәктәге гөл тармагы ике-өч яфрагын тырпайткан да, берүзенә бер чүлмәк туры килгәнгә сөенеп, тәрәзәгә караган кояшка куана. Безнең тәрәзә төбенә тиз ияләшергә уйлый бу гөл. Шәмсивафа әби гөлләрен генә сагынмаса ярар иде. Сагынып саргаялар, диләр бит. Саргая башласа, нишләрсең?

Әбидән сорарга да онытканмын, бигрәк ашыктык шул. Кайчан тамыр җибәрер икән соң бу тармак? Тамыры булса саргаймас иде. «Сагынма, гөлкәем, сагынма, көннәр җылынгач, кунакка алып барам мин сине». Минем бер дә гөлем яныннан китәсем килми. Тукта әле, тамыр чыгармадымы икән? Тик балчык астында шул, тамыры күренми... Тамырын карыйсым гына килә бит! Мин әкрен генә гөлемне казып алдым да... Әй, ничек утырткан булсам, шул көе! Монда әле тамырның эзе дә юк! Яңадан урынына утыртып куярга гына тора идем, әни күреп алды.

— Борчыма инде шул гөлне! Ул арада нинди тамыр булсын! Гел кузгатып тормыйлар аны. Гөлгә тынычлык кирәк. Яңа утыркан гөлгә кул белән кагылу түгел, озак итеп карап торырга да ярамый. Шиңәр дә төшәр әле. Бер дә сабыр итә белмисең шул!

Гөл утырту осталыгы безнең әнидә дә бар икән...

— Ярый алайса.Ул тамыр җәйгәнче, мин тиз генә Диләрәләргә кереп чыгам әле. Аның гөле ни хәлдә микән?

Мин алар турына килгәндә, Диләрә тәрәзә каршында үскән канәфер (сирень) куакларының корыган ботакларын кисеп йөри иде.

— Чүлмәкле гөлләрең белән эшең беттемени?

— И-и! Өйдәгесен кем дә карый аның! Гөлләрне барысы да сагынган. Бакчадагысы да минем эш бит! Былтыр да канәфер чәчәк атты да коелды, орлыклары җитлекми калды.

— Быел җитлегер микән соң?

— Ул бит яшь агач түгел, аны мин туган елны утыртканнар. Яздан ук карап, төпләрен йомшартсаң, җитлегер, нишләп җитлекмәсен? Әнә әбигә читтән канәфер белән посылка җибәргәннәр. Аларныкы җитлеккән бит. Орлыгына чаклы шундый хуш исле, гел чәчәк исе килеп тора.

— Ничә елдан җитлегә икән соң аның канәфере?

— Әллә кайчан булыр иде инде. Малайлар бит, ел саен чәчәкләрен талыйлар. Быел саклыйм, бер чәчәген дә өздермим. Былтыр имтихан бирүчеләр дә «биш таҗлысы, биш таҗлысы!» дип эзләгән булып, өзеп бетерделәр.

— Биш таҗлысын табып, шуны ашасаң, имтиханны бишлегә бирәсең, дигән булалар, дөрес микән ул?

— Үзем дә инде, алар шулай дигәнгә генә өздерткән идем. Бәлки, биш таҗлы чәчәктә канәфере дә өлгергән булыр иде. Быел елап ялынсалар да, өздермим! Бишле аласылары килсә, әйбәтләп укысыннар! Укымаганнар өчен канәфер таҗында «бишле» үстереп бирәсем юк. Агач төбендә утырсам утырам, яфрагына да кагылдыртмыйм!

— Мине дә чакыр, бергәләп каравылларбыз, яме?

Мин хәзердән үк Диләрәгә ярдәм итә башладым. Агачның төпләрен йомшарттык, корыган ботакларны кисkәләгән булдык. Их, безнең бакчага да бер генә төп канәфер утыртасы иде! Сорасаң бирер иде дә...

— Диләрә, кара әле, монда күп кенә бәләкәйләре дә үсеп чыккан. Безнең бакчада бер генә дә канәфер агачы юк бит...

— Әйдә, хәзер төпләп алабыз да сезнең бакчага да утыртабыз!

Ишеттегезме! Мин уйлап бетерергә дә өлгермәдем! Дус кызың булса шундый булсын ул! Ур-ра!

Ике кечкенә куакны казып алдык та безгә йөгердек. Тик безнең бакча өчен иртәрәк булган икән бу эшебез. Диләрәләр бакчасында коры булса да, бездә әле кар да бар, боз да эреп кенә ята.

Алар бакчасы кояшка карый шул. Ә безнекен йорт каплап тора. Бу хәлне аңлатырга дип әни янына өйгә йөгереп керсәм! Ниләр күрим!!! Идән тулы балчык! Матур чүлмәгем бер якка тәгәрәгән! Минем «мә-мә» дән башканы белмәгән энем, ничекләр буе җиткән, чүлмәгемне идәнгә тартып төшергән!!! Яңа гына утырткан гөлемне йолкып алган! Мин ах-вах килгәнче, гөл тармагын авызына кабып, барлы-юклы ике-өч теше белән чәйни дә башлады.

— Уф!!! Бетергәнсең бит! Төкер хәзер үк! Тьфү! Хараплар гына иткәнсең!!

Ни аның авызындагы гөл тармагын алырга белмим, ни балчык җыярга! Нишләргә белми торган арада, ул малай гөл тармагын йотып та җибәрде! «Мәм-мәм» дигән була үзе! Авызын ерган. Әле тагы сорап маташа, «мә-мә» ди.

— Их син юньсезне! Оятсыз! Бозаумыни син!

Мин әрнеп елап җибәрдем. Нинди үтенүләр белән тапкан тармагымны! Бигрәк тә бернәрсә дә аңламый бу малай!

— Диләрә! Кер әле! — тәрәзә аша аңар кул изәдем.

Көрәген дә ташламый атылып, Диләрә дә кереп җитте.

— Нәрсә булган монда?

— Әнә... ашаган...

— Елама әле, балчык ашаганмыни?

— Балчык ди сиңа! А-а-а! Гөлемне кабып йотты! Тамырыние белән.

Диләрә энем каршысына чүгәләде:

— Ач әле авызыңны, ач! Телең кая?

Тегесе безне мыскыл иткән сымак авызын ачты да ямьяшел телен күрсәтте.

— Йотып җибәргән инде бу, авызында юк.

— Әйтәм бит ашады дип, малай актыгы!

— Тукта әле, үкермәсәнә шулкадәр!

— Нишлибез инде хәзер?

— Нишлибезме? Яңаны утыртабыз!

— Аңа рәхәт, аның гөлен ашамаганнар шул!

— Кайгырма әле шулкадәр! Яз бит хәзер, яз! Бер гөл тармагы таба алмабыз дисеңме?..

## Авылым җыры

Югары оч, Түбән оч,
Уртасында өебез...

Шушы җырны Югары оч кешеләре дә, Түбән оч кешеләре дә җырлый. Барлык кешеләрнең өе дә урталыкта булмый инде. Безнең урам турында бу җыр. Нигә дисезме? Чөнки безнең урам Югары оч белән Түбән очның нәкъ килеп кушылган урыннан башланып киткән. Аның үзен Суык урам дип атап йөртәләр. Ә Суык урамның иң уртасында безнең өй. Кара, кара, әллә безнең өй турында инде җыры да? Ни өчен Суык урам дип кушканнардыр безнең урамга, белмим. Кыш көне суык булганга дисәң, ул вакытта бөтен урамда да суык була, безнең урамда гына түгел. Ни дисәләр дә дисеннәр, минем үземә ошый безнең урамның исеме. Әти әйтмешли, урамыбыз Суык дип аталса да, күңелләребез җылы безнең. Кыш көне урамыбыз буйлап тау-тау кар көртләре өелә. Бөтен авыл малай-кызлары чана шуарга безнең урамга килә.

Ә җәй көне... Иң беренче салават күпере кем урамына чыга? Безнең урамга! Ышанмыйсызмы? Алай булгач, нигә салават күперен карарга безнең урамга җыела соң бөтен бала-чага? Ишетәсезме?

— Яшеле миңа!
— Сарысы миңа!
— Кит, тиле, сарысы ут бит анын!
— Бик беләсең икән, кызылы ут!
— Алайса, яшеле — яшен!
— Юк, юк, миңа зәңгәре!
— Сарысы да, зәңгәре дә сиңа, оста икәнсең!

Безнең авыл бик матур төшкә урнашкан. Бөтен тирә-ягын таулар чолгап алган. Кайчандыр авылдан читкә киткән кешеләр шул тауларны сагынып кунакка кайта. Бәлки, тауларны гына түгел, чишмә буйларын да, тауларын менгәч тә башлана торган урманнарын да сагына торганнардыр. Түземсезлек белән көтәбез шәһәр кунакларын. Көн саен көтәбез, көннәр буе көтәбез. Автобус безнең авыл аркылы үтми шул. Безнең чокыр эченә бер керсәң, чыгарырсың автобусыңны. Шуңа күрә кунакларны каршыларга олы юлга ат, машина белән чыгалар. Чыгалар гынамы сиңа, очалар, чабалар!

Менә беркөнне күршебез Фагыйлә апаларга әти-әнисе белән бер кыз белән бер малай кунакка кайтты. Аларны да олы юлдан ат белән барып алдылар. Безнең ише кызлар өчен кунак каршылаудан да кызыграк нәрсә бар микән? Авылга кем генә кайтмасын, безнең дә кунагыбыз ул. Кунакларның да төрлесе була. Кайберәүләре бик мактана башлый. Шәһәрдә бу бар да, теге бар... Безнең бик ис китеп тормый. Алар кайтканчы ук без кызлар сүз берләшеп куябыз: сер бирмәскә! Башта тыңлыйбыз әйбәт кенә. Кызык бит, бик кызык әйберләр сөйлиләр. Тыңласаң исең китәр! Тик безнең ис китми. Харап икән! «Һи, шул да булдымы искитәрлек нәрсә!» — дибез. Әле кайсыберләре безнең белән русча гына сөйләшергә маташа. Аларны гел дә уенга алмыйбыз. Бик тиз өйрәнәләр безнеңчә сөйләшергә!

...Менә Фагыйлә апаларның капкасы күгәненә кадәр каерылып ачылды, көне буе көткән кунакларыбыз ишегалдына кереп китте. Кара әле, капкадан кергәндә дә арбадан төшмәделәр.

Алар капка төбен бер төркем малай сырып алган. Рифат тикле Рифат та әбиләренә керергә оялып тора. Оялырсың да, кунаклар көн дә кайтып тормый, аларга ерактан гына иянәнергә кирәк башта. Исләре дә икенче төрле кунакларның. Ислемайлары бөтен урамны аңкытты.

Малайлар Рифатны кыстыйлар:
— Бар инде, кер инде, дүрт яклы пәкесе булса, күрсәтсен әле...
— Кит әле, оялмыйча...
— Әй куркак!

Шушы малайлар үләләр инде пәке дип.

Без, кызлар, койма ярыгыннан ишегалдын күзәтә башладык. Урман аша үткәндә бу кунаклар, күп итеп ботаклары белән сындырып, шомырт җыеп кайтканнар икән. Теге кунак малае белән кунак кызы һаман арбадан төшмичә шомырт ашап утыралар.

— Әйдәгез, балалар, өйгә,— диде Фагыйлә апа.— Чәем кайнаган, самаварым өстәл өстендә сезне көтеп, җырлап утыра.

Кара әле, үзе дә җырлаган кебек сөйләшә!

Аркаларыннан сөя-сөя арбадан төшерде кунакларны. Шомырттан аерыласы килмәгән малай, кочагы белән күтәреп, өйгә керә башлады.

— Кави, куй, улым, шомыртлары сытылып, күлмәгеңне пычратыр.

Белдек, малае Кави исемле икән.

Кунак малайның әнисе шунда ук кычкырып та җибәрде.

— Нишләттең чалбарыңны!

Менә шулай була ул шомырт сындырсагыз. Кавинең чалбарында, кызының күлмәгендә, зур тап булып, шомырт эзе калган иде. Үлгәнче юсаң да, бетми ул.

Ул арада кунаклар барысы да җыелышып өйгә кереп киттеләр. Озак көттерерләр микән? Хәзер чәй эчәләр, аннары ял итәләр инде. Ни әйтсәң дә шәһәр кешеләре шул алар... Кунак кызы белән танышасы килә бит. Шулай да ис китмәгән кыяфәт белән капка янындагы бүрәнәгә тезелешеп утырдык та, уйнарга тотындык. Юри кычкырып сөйләшәбез дә, көлешкән чагыбызда барыбыз да ялт итеп капка ягына карап алабыз. Ник бер кеше безнең хәлне аңласын, хет капкадан башын тыгып кына булса да бер караучы кеше булсын!

Төш тә җиткән икән! Менә сиңа кунак кызы саклап утырсаң!

Эштән кайтып килүче Гөлфәниянең әнисе:

— Кызым, бозауга су бирдеңме? — дип эндәште.

Шушы минутта гына әниләр кушып калдырган эшләр искә төште.

— Әнекәем, казлар басуга чыкмадымы икән,— дип, Фәния казларын эзләргә йөгерде. Диләрәнең чебешләр ашатасы бар икән. Ә мин буш чиләкләремне алып, инешкә йөгердем. Кич белән кыярларга сибәргә су ташып куясы бар иде.

Ә малайлар, менә кайгысыз кешеләр, теш араларыннан чертчерт итеп төкереп, чирәмдә сузылып ятып калдылар. Аларга эш кушучы юк микәнни?

Көндезге эшләрне бетереп, әниләр яңадан эшкә киткәч, без тагы Фагыйлә апалар турына җыелыштык. Шул арада Фагыйлә апа, без көтеп-көтеп арыган кунакларны ияртеп, кочагына бөтен бер карбыз тотып урамга чыкты.

— Менә, балалар! Кунак малае белән кунак кызы — Кави белән Галия — сезгә дип күчтәнәч алып кайтканнар. Бик ерактан алып кайтканнар, тату гына ашап, тату гына уйнагыз, яме,— диде дә барыбызга да берәр телем карбыз өләшеп чыкты.

Карбызны ашап бетергәнче, бик матур күлмәкле, чәчләрендә ал тасма бантиклап бәйләнгән Галия белән дуслашып та өлгердек. Тик Мансур гына бөтен эшне боза язды. Карбыз телемен тиз генә кимереп бетерде дә яшел кабыгын койма башындагы чыпчыкка төзәп атып җибәрде, аннары Кавигә борылып:

— Әй, карбыз мондый буламыни ул, иеме, яшьти? — дип, янында басып торган Хатипның иңенә кулын салды.— Карбыз ул карлы-бозлы була! Ә бу — кызыл эчле кабак! Аннары черт иттереп теш арасыннан төкерде дә төкерек төшкән җирне адымы белән үлчәп тә куйды.— Өч атлам. Син бер телем карбыз түгел, бер бөтен карбыз ашасаң да болай булдыра алмыйсың.

Без бу оятсызлыктан ни эшләргә белмичә әле Мансурга, әле еларга җитешкән Кавигә карадык та, Мансурны ачуланырга тотындык.

— Оял азрак, авыз итмәскә иде, нигә сыйландың соң, кабак булгач.Үзеңнән кечеләргә бәйләнмәсәң ни була?

Мансур артына карый-карый такмаклап өенә таба йөгерде.

— Китте көймә, китте көймә, бәрелә-сугыла бозларга!

Кем булса да елый башласа, бездә шундый такмак әйтәләр. Аның шулай дип әйтүенә карамастан, көймә барыбер китмәде, ягъни Кави еламады.

Шушы хәлдән соң урамда калыргамы, өйгә керергәме дип икеләнеп торган Галия Мансурның өйләренә кайтып киткәнен күргәч туктап калды. Бик матур кыска гына күлмәк, аякларында ялтыравыклы башмаклар кигән бу кызга, сүзне каян башларга белми, карап тора башладык.

Кинәт Диләрә:

— Кызлар, әйдәгез су буена, Галиянең бит чишмә буйларын бер дә күргәне юктыр,— диде.

— Туктагыз, мине дә көтегез,— диде Фәния,— баргач-баргач, көянтә-чиләксез бармыйк инде.

Су буена беребез дә буш бармый инде. Бераздан барыбыз да бергә көянтә-чиләкләребезне чылтырата-чылтырата су буена төшеп киттек. Әй бу малайлар, әллә дуслашып та өлгергәннәр инде. Мансурлар капкасы янында үскән карт шомырт төбенә җыелганнар. Агач башында Мансур инде, тагы кем булсын.

— Мансур абый, бер генә тармак ташла әле,— дип, агач башына менә алмаган бәләкәй малайлар тыпырдаша.

— Барыгыз, безгә кереп ашагыз, бездә шомырт бик күп,— диде Галия.— Ялынмагыз шул мактанчыкка.

Матур да соң безнең су буйлары. Яз җитүгә су буйлары сары чәчәккә күмелә.

Чишмәбез дә улаклы. Улаклар янында үскән бөтнекләр шундый хуш ис тарата! Ислемай сипкән диярсең.

Кунак кызы Галия улакка тулып аккан суга шаккатып торды да:

— Кранын ябыгыз тизрәк, болай күп акса, иртәгә кадәр суы бетә бит моның, суга кая барырсыз? — дип кычкырып җибәрде.

— Бетә торган су түгел ул. Тау астыннан чыккан чишмә бу!

Шушы сүзләрдән Галия иңнәрен сикертеп алды да безгә кушылып көлеп җибәрде.Чишмә буенда Галиягә бөтнек иснәттек, сары чәчәкләр җыйдык, салкын су белән яулыкларыбызны чылатып яптык та, чишмәдән сулар алып, тезелешеп өйгә таба киттек.

Карт шомырт агачы яныннан малайлар һаман китмәгән. Кычкырышалар, шаулашалар... Без дә чиләкләребезне куеп, болар янына килдек. Без су буена киткәч, бик кызык хәлләр булган икән монда. Әйттем бит, безнең авылда кызыклар шәһәрнекеннән күбрәк дип! Мансур агач башында тотынмыйча тирбәлеп торган чагында, Борһан абыйларның бал кортлары күч аерган да шомыртка килеп сарган. Агач башындагы Мансурга шәп эләккән алардан. Күп тыпырчына торгач, малай кычыткан арасына егылып төшмәсенме! Ярый, җиңел котылган. Бәхете бар аның. Былтыр да коега егылып төшеп аның бер җире дә сыдырылмаган иде. Тик кортлар Мансурның чакмаган җирен калдырмаганнар. Менә хәзер, күчне җыеп алгач, тагы кыюланган Мансур. Күмәч кебек кабарып шешкән кулын чират белән малайларга тоттырып күрсәтә.

— Менә кара, тотып кара, курыкма, авыртмый ул. Ну, тагы бер корт чакса, шартлый иде шартлавын! Әйдә дуслашыйк! — ди ул, шешкән кулын Кавигә сузып.

Дуслашырсың шул. Бүген элэгэчэк эле аңар. Әти-әнисе бер-берен уздырып мең сорау бирәчәкләр әле.

— Ничә иштанерттың бу җәйдә?

— Бүре тиресеннән тегәргәме әллә аларны?

— Бүре тиресе дә чыдамас, анысы да ертылыр...

Ә инде кунак малае белән кочаклашып өйгә кайтып керсәң, сораулар ява башлаганчы, үзең мактана башласаң, алай ук каты тимәячәк. Ну хәйләкәр соң бу Мансур! Яраткан сүзе дә аның — хәйләсез дөнья файдасыз! Кычыткан арасына егылып төшкәндә дә, шулай дип кычкыргандыр әле!

Нинди генә хәлләр булмый безнең авылда җәй көне.

Кунаклар белән дә бик нык дуслаштык. Алар безгә шәһәр җырларын, без аларга үзебезнең җырларны өйрәттек.

Киткән чакта алар безгә болай дип җырладылар:

Югары оч, Түбән оч,
Уртасында өегез!
Без кайттык та кунак булдык,
Инде үзегез килегез.

# Пьеса



# *Үп мине, Зәйтүнә*

*(Моңсу комедия)*

КАТНАШАЛАР:

З ә й т ү н ә — ямьсез кыз, 19 яшьтә.
Б а н у, Х ә д и ч ә, С а ж и д ә — 18–20 яшьлек кызлар.
Г а б д у л л а, В а х и т, С а д ы й к — 19–20 яшьлек егетләр.
К а р а е г е т — сихергә тап булган егет.
Ш а й т а н — җен белән бутарга ярамый.
Л ә й л ә ә б и — кияүгә чыкмаган, мәңгелек гашыйк, 70 яшендә.
Ә х м ә т җ а н б а б а й — өйләнмәгән, мәңгелек гашыйк, 75 яшендә.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Җәй. Пәрдә ачылганда, кызлар басма янына кер чайкарга җыелганнар. Йөгерешә-йөгерешә уңайлырак урын алып калырга тырышалар. З ә й т ү н ә иң биек җиргә баскан, аның янында Бануның керләр салган чиләге. Сәхнәдә С а ж и д ә, Х ә д и ч ә һәм Л ә й л ә ә б и, Б а н у.

З ә й т ү н ә. Кызлар! Карагыз әле бу матурлыкка! Чыркылдашмагыз әле. Кошлар ничек матур сайрый! Тугайлар ямьяшел! Ә болын... Елга суы...

Б а н у. Юпь-юеш! Төш әле басма башыннан! Бүген басма башы минеке! Беркайчан да монда кер чайкаганым юк! Алдан килгән урын өчен, Зәйтүнә! Минем чиләккә абынма! Китегез, кит, суга мәтәлдерәм үзегезне!

Х ә д и ч ә. Әнекәем! Төртешмә әле! Чаршау-чыбылдыкларың белән бөтен елганы каплап алдың!

Б а н у. Әйттеләр бит сиңа! Алдан килгән урын өчен! Синең чолгаулардан соң чыбылдык чайкаганнар ди монда!

С а җ и д ә. Кызлар, миндә тастымаллар гына, яныгызга басыйм әле?..

Х ә д и ч ә. Кит, кит! Тар тишеккә тана башы! Басманы сындырасыз бит! *(Саҗидәне этеп җибәрә, Саҗидә сабынын суга төшерә.)*

С а җ и д ә. А-а... сабыным суга төште! Синең аркада, пароход морҗасы, басмада кем төртешә...

З ә й т ү н ә. Җитәрегез инде, кеше тыңлап торса, оят, билләһи! Су буе тикле су буена сыеша алмыйсыз!

С а җ и д ә. Ай сабыным! Сабыным, әни үтерә мине хәзер!

Х ә д и ч ә. Су буена кем сабын белән төшә, тиле баш! Өйдә әйбәтләп уарга кирәк иде!

С а җ и д ә. Ашыктырдыгыз бит... а-а!

З ә й т ү н ә. Җитәр инде, елап торма! Хәзер үзем табып бирәм.

Л ә й л ә  ә б и. Табарсың бар. Агымсуда сине сабын көтеп тора ди! И-и, суны болгатып бетергәннәр! Басма башыннан сыпырып төшерермен берәм-берәм!

Зәйтүнә суга керә, Саҗидәнең сабынын тота.

З ә й т ү н ә. Миннән ычкынмас!

Х ә д и ч ә. Бака бар! Бака бар! Зәйтүнә! Синең итәк астыңа керде!

З ә й т ү н ә. Керсә, чыгар әле! Курыкканга куш. Мә, Саҗидә, сабыныңны!

Л ә й л ә  ә б и. Суга шау-шу белән кермиләр аны. Су алыр үзегезне. Иплә п кенә, иплә п. Бисмилласыз эш башлыйсыз... Хәерсезләр. Ни әйтәм, ни өйрәтәм, кермәсә керми икән...

Б а н у. Соң бит, Ләйлә әби, ул минем чыбылдыклар өстендә аяк чолгаулары чайкарга маташа.

Х ә д и ч ә. Минем чолгаулар синең чыбылдыклардан бер дә кайтыш түгел. Чиккән чолгаулар алар! Синең кулъяулыгыңа торырлык! Менә, менә, карагыз! *(Күрсәтә.)*

Л ә й л ә  ә б и. Якланма, якланма, зәхмәт! Кая барып кагылсаң да тавыш чыгармый калмыйсың! Кая, кайсыгыз минем бер сыңар гына мендәр тышымны чайкап бирә.

З ә й т ү н ә. Әй Ләйлә әби! Тузан да төшермисең мендәр тышыңа! Көн дә юып кына туздырып бетердең бугай.

Л ә й л ә  ә б и. Сердәшем бит мендәрем. Төне буе сөйләгән серләремне суга агызмый, әллә сезгә белдеримме?

С а җ и д ә. Безгә сөйләсәң, үзеңә җиңелрәк булыр иде...

Л ә й л ә  ә б и. Миңа болай да авыр түгел. Мәхәббәт серләрен кеше саен таратмыйлар...

Х ә д и ч ә. Дөрес, Ләйлә әби. Авызларында сер тормый аларның, үземә генә сөйлә әле...

Л ә й л ә ә б и. Синең дә тешләрең бик сирәк, Хәдичә. Минем сердән сиңа ни куаныч. Мендәрем белән миңа гына юаныч бит ул.

Б а н у (*кызларга күз кысып*). Ләйлә әби! Син тәҗрибәле кеше инде. Алтмыш ел буе бер генә егетне яратып йөрисең. Шунысы гаҗәп, ул да бары тик сине генә ярата. Менә аңлат әле без тилеләргә, чын ярату нәрсә ул? Мәхәббәт дигән нәрсә бармы, әллә уйлап кына чыгарганнармы аны? Шуны аңлатсаң, мендәр тышың да чайкалыр, кая Хәдичә, бәләкләп җибәр әле!

Л ә й л ә ә б и. Юк, юк, бәләкли күрмә! Изелер дә төшәр! (*Бануга.*) Чолгау дип белдеңме әллә син аны, бәләкләп юарга. Инде ратуга килсәк, ахирәткәйләр...

С а җ и д ә. Сөйлә инде, сөйлә... Мендәр тышыңны чайкап кына түгел, киптереп тә, сыдырып та бирер идем!

Л ә й л ә ә б и. Ярату пәйгамбәрләрдән калган. Шуңа күрә изге булып санала. Йосыф китабында барысы да язылган. Гөнаһка батып сөйләп тормыйм әле.

Зәйтүнә Ләйлә әбинең әйберләрен алып чайкый башлый.

Х ә д и ч ә. Әй, шушы Ләйлә әбинең ялындырулары! Китап китап инде ул, анда безнең авыл егетләре турында язылмаган бит. Менә безнең авылда үскән, безнең чишмә суларын эчкән егетләрнең яратуы ничек була микән?

Л ә й л ә ә б и. Сез бигрәк тагы! Гомер буе бер генә егетне өзелеп сөйгән кыздан ярату серләрен сорап азапланасыз. Белсә инде аны беләсезме кем белер?

Б а н у. Юк, юк, андыйларның яратуын үзебез дә беләбез. Сөйләп тә торма. Менә син үзегезнең мәхәббәт турында сөйлә әле, баштан алып ахырына кадәр!

Л ә й л ә ә б и. Ахырына! Мәхәббәтнең ахыры булгач, мәхәббәт буламыни ул?!

С а җ и д ә. Үзе ахирәткәйләрем, дигән була, үзе ялындыра...

Л ә й л ә ә б и. Ахирәткәйләрем дип әйткәлим шул... Кызлар, үпкәләмәгез инде! Ахирәт дус берәү генә була ул. Сез бит әле аның нәрсә икәнлеген дә белмисез! Минем ахирәт дустым... урыны җәннәттә булсын, гомере кыска булды. Менә дус иде, ичмасам! Чын ахири иде.Ә инде ахирәт дуслыкны болай беркетәләр: иң якын дус кызың белән, инде күптөрле сынаулар үткәч, икәүдән-икәү генә каласың. Аулакта, бер кеше дә күрмәгәндә, ишетмәгәндә, бер-береңнең колагына «Ахирәткә кадәр дус булырга сүз бирәм» дип пышылдап кына ант итәсең. Аннан соң ике рәкәгать намаз укыйсың да, соңыннан бер-береңә бүләкләр бирешәсең. Ахирәт дус ике булмый, бер генә була. Яраткан кешең кебек. Чөнки ул сине яман сүздән, яман күздән дә яклаучың була.

Керләрне чайкап, З ә й т ү н ә керә.

З ә й т ү н ә. Тукта, тукта, ничек диден, аулак урында колактан колакка ант диденме.

Л ә й л ә  ә б и. Дуслыкта сер булырга тиеш. Ә инде яратуга килгәндә, анысы сернең иң зурысы! Сорашмагыз да, сөйләмим дә!

Б а н у. Кызык икән! Керләрен чайкап биргәнче сөйлим дип котыртып торды, хәзер ычкынмакчы була!

Л ә й л ә  ә б и. Син чайкамадың, Зәйтүнә чайкады.

Б а н у. Кызлар! Әйдәгез әле су коендырып алабыз үзен!

Ләйлә әби торып йөгерә башлый. Кызларны шаккаттырып юан талга менеп китә, бер ботагына утыра.

Х ә д и ч ә. Бәхетең инде, Ләйлә әби, манчып чыгара идек үзеңне.

Б а н у. Утырсын әле кетәклектәге тавык кебек.

Х ә д и ч ә. Мин мен дисәм, гомердә дә менә алмас иде!

Л ә й л ә  ә б и. Кызлар! Ничек төшим!

Х ә д и ч ә. Безнең сандугач сайрый башлады, кызлар!

З ә й т ү н ә. Ләйлә әби, хәзер төшәргә булышырмын, җәймәңне генә киптерергә элеп киләм.

Б а н у. Төшеп кенә карасын, без аны хәзер манчып алабыз!

С а җ и д ә. Бану, син бигрәк инде, туры әйтәм дигәч тә.

З ә й т ү н ә. Кеше рәнҗетергә дисәң, Бануга куш.

Л ә й л ә  ә б и. Тукта, мин дә синең белән... Менә мине моннан кем төшерә хәзер.

Б а н у. Әһә, эләктеңме! Мәхәббәтең хакында сөйлим дип ант итсәң, менә шушы чыбылдыкка сикертәбез.

Кызлар агач төбендә, чыбылдыкны өчесе өч ягыннан тотып, әбине сикерергә кыстыйлар.

Л ә й л ә  ә б и. Сөйлим, сөйлим! Тик аның сусәргән чыбылдыгына үлсәм дә сикерәсем юк. Күтәреп төшерегез!

Кызлар әбине агач ботагыннан төшерәләр.

Л ә й л ә  ә б и. Уф, үләм дип торам.

К ы з л а р *(бергә)*. Сөйләмәсәң, яңадан киштәңә озатабыз!

Л ә й л ә  ә б и. Сөйлим, сөйлим, тыңлагыз алайса. Кем өйрәтте дип әйтсәләр, үзебез белдек диярсез, алайса, кеше көләр...

К ы з л а р *(бергә)*. Әллә чынлап та сөйлисеңме?

Л ә й л ә  ә б и. Сездән башкача котылып булмас, ахры. Тыңлагыз алайса: ярату күптөрле була ул. Аларны бер-берсе бе-

лән бутамас өчен, аерым-аерым белү кирәк. Беренчесе, иң изгесе, ата-анага мәхәббәт.

Кызлар. Ләйлә әби! Анысын беләбез дә инде...

Ләйлә әби. Бүлдермәгез! Менә олылар болай дип әйткән: «Кызлар аң булыгыз, ана белән кыз арасында бер мыскал мәхәббәт булыр, ди, кызы кияүгә чыккач, анысына да шайтан көл сибәр»,— дигән.

Хәдичә. Тьфү, тьфү! Әстәгъфирулла! Мәхәббәт турында сөйләшкәндә шайтанны катнаштырма әле.

Ләйлә әби. Әй, ул йөзе караның катнашмаган эше бармы соң? Менә чын яратучылар тирәсендә шайтан чолгана да бәйләнә ди шул.

Саҗидә. Үләм, куркам... нишләп алай итә икән ул...

Ләйлә әби. Шайтанның да чын мәхәббәт белән яратасы килә ди. Мәхәббәткә сусаган, йә булмаса яратудан шашкан кыз баланың йөрәген үзенеке итәсе килә ди. Тик андый яратуның ахыры яхшы булмый...

Саҗидә. Нинди яратуның?

Ләйлә әби. Шашып, өзелеп яратуның... Аны әйтеп тә торасы юк. Әнә күрше авыл Галиябану белән Хәлилне генә алыйк. Шул Исмәгыйль шайтан катнашмаса, нинди пар иделәр. Таһир белән Зөһрәне дә суга агызганнар... Ә инде минем адаш Ләйлә белән мәхәббәттән Мәҗнүн булган сөйгәне турында әйтеп тә торасы юк. Шулай, кызлар, ярату ярату белән, мәхәббәтегезне сакларга өйрәнегез. Яратсагыз да өзелеп яратмагыз, андый эшкә шайтан катнаша.

Бану. Кызык икән... Ләйлә әби, ә сезнең ярату нинди яратуга керә?

Ләйлә әби. Шашып яратуга. Шуңа күрә алтмыш ел буе кавыша алмыйбыз. Безнең мәхәббәткә дә катышкан ул шайтан. Моннан алтмыш ел элек безнең авылга бер тарак сатучы килгән иде...

Агачлар артында Зәйтүнәнең җырлавы ишетелә. Кызлар аның тавышына борылалар. Зәйтүнә керә, кызлар аңар кушылалар.

Сандугачым су ташый,
Кайда икән су башы,
Сандугачым ялгыз башы,
Хозыр булсын юлдашы.

Суга барсаң иртә бар,
Көндез казлар болгата.
Бик сагынсаң чык болынга,
Кошлар сайрап юата.

Ләйлә әби башлап җырлый:

Су агадыр агарып,
Су бозлары агарып,
Син җаныем исемә төшсә,
Зиһенем китә таралып.

Зәйтүнә башлап җырлый:

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Хәдичә,
Бәхетсезләр диңгезеннән
Сулар эчтем белмичә.

Хәдичә. Минем исем кушылгач, гел шундый җыр килеп чыга синең. Матур итеп җырла әле.

Зәйтүнә. Җырның ертыгы булмый. Булса, такмак белән ямыйбыз.

Әй Хәдичә, Хәдичә!
Ярга ятып су эчә!
Тыйнак булып йөргән идең,
Кем ярын үптең кичә.

Хәдичә (*юеш чолгау белән Зәйтүнәне куып китә*). Бирермен мин сиңа «Кем ярын үптең кичә»не! Үземнең ярга да үптермәдем әле, өйгә кайтып җиткәнче йөгердем!

Бану. Катырак йөгереп ташладың бугай. Вахитең төне буе йокы мазасы бирмәде, җырлый-җырлый урам әйләнде.

Ләйлә әби. Кызлар, дим, кызлар! Минем исем белән дә бер җыр әйтеп бирегез әле. Зәйтүнә, сиңа әйтәм!

Саҗидә. Тукта әле, Ләйлә әби, синең җыр җырланган бит инде.

Ләйлә әби. Сөйгән егете белән кавышмаган кызның нишләп инде җыры җырланган булсын ди...

Зәйтүнә. Чираттан. Монысы Саҗидәгә.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Саҗидә.
Судан чыкмый, йөзә белми,
Батып үлгән сай җирдә.

Саҗидә. Бигрәк инде тагы. Җыр чыгара беләм дигәч тә. Ярату турында чыгар!

Ләйлә әби. Әйе шул, әйе. Ярату җырларын гына җырлыйк әле. Минем исемгә дә ятышлы булса... Минем әле сезгә төшендерәсе серлә-ә-ә-әр... у-у-у...

Бану. Кара әле бу спекулянтка! Әле җәймәсен юдырта, әле җыр чыгарырга куша.

Зәйтүнә. Сез әйтеп кенә чыгарып булса ул җырны. Мин гел җырлап кына йөрер идем. Бүгенгә җитәр мәллә?

Кызлар (*бергә*). Ялындырма инде.

З ә й т ү н ә. Бигрәк кирәк дисәгез, үзегез дә кушылыгыз.

Б а н у. Беренче юлын мин әйтәм. «Кулымдагы йөзегемнең»!

Х ә д и ч ә. Икенче юлын мин чыгарам! «Исемнәре Ләйлә...» Туры килми бит, көе артып кала.

З ә й т ү н ә. Менә шулай шул. Теләсә кем чыгара алмый ул җырны. Ләйлә әби, үпкәләштән булмасын, яратып кына җырлыйм.

Кулымдагы йөзегемнең
Исеме Ләйлә әби!
Янып мәхәббәт утында,
Сиксәнгә җитте әби!

Л ә й л ә  ә б и. Сиксәнгә?! Каян килеп сиксән булсын? Бәрәңге алган вакытта җитмеш бер генә тула әле миңа. Китерегез җәймәмне. Мыскыл иттереп торганчы кайтам да китәм. Минем керләрем чайкалдымы, юкмы?!

З ә й т ү н ә. Берүк үпкәли күрмә, Ләйлә әбекәем! Чайкалды гына түгел, кибеп тә җитте бугай. Әрәмәдәге коры тал ботагына элгән идем. Мин хәзер.

Зәйтүнә тал арасына кереп китә.

С а җ и д ә. Кара аны, тал төбендә чоңгыл бар, бата күрмә.

Таллар артыннан Зәйтүнәнең әче тавышы ишетелә. Ул куркып, тыны бетеп йөгереп керә.

З ә й т ү н ә. Кызлар! Су эчендә берәү утыра! Абау! Йөзе кара! Мә җәймәңне. Шуны алам дип, чүт ычкынмадым. Әллә нинди ят адәм, уф!

Б а н у. Кем булсын анда!

Л ә й л ә, С а җ и д ә *(бергә)*. Нәрсә булды, кемне күрдең?

З ә й т ү н ә. Кызыкайларым! Күрәсекәйләрегез булса! Тал төбендә бер әкәмәт бар. Шулхәтле дә ямьсез үзе. Йөзе ком гарәбенекедәй кап-кара! Күзләре шар кебек, ут чәчеп тора!

Б а н у. Үз шәүләсеннән үзе курыккандыр әле. «Матурлыгына» чыдый алмый, тонык судан күзен алмый!

Х ә д и ч ә *(көлә)*. Хак, хак! Шуңа күрә тал артына, тымытык җиргә кереп караган ул.

З ә й т ү н ә *(еларга җитешеп)*. Кызлар, сез нәрсә, мыскыл итмәгез инде...

К ы з л а р *(бергә)*. Бетте, бетте. Шаяртабыз лабаса! Кара, төсең-битең киткән, әллә чынлап та берәр шайтаны тыңлап торды микән.

К а р а  е г е т керә.

Кара егет. Әү, мин монда! Чакырган җиргә бар, диләрме әле.

Аны күрүгә, Ләйлә әби телсез-аяксыз кала. Кузгала алмый.

Бану. Куган җирдән кайт, дип тә әйтәләр. Сине кем чакырган монда. Тал төбенә качып, кызлар сүзен тыңлап йөрисең, хатынша!

Саҗидә. Башка авыл кешеседер... Китегез инде, оялмыйча...

Хәдичә. Хозыр Ильяс диген тагы.

Бану. Ай-һай чибәрлеге! Җеннең тискәре ягы диярсең! Берәр әрмәндер әле шул...

Саҗидә. Ирләр шундый була инде ул. Әни әйтмешли, җеннән аз гына кайтыш булса җиткән. Гомумән, ямьсез ирләр булмый, диләр...

Кара егет. Юк, юк, кызлар, бутый күрмәгез. Җен башка, шайтан башка. Җеннең тискәре ягы да түгел, шайтанның нәкъ үзе булам мин. Таныш булыйк...

Зәйтүнә. Әстәгъфирулла! Үз-үзен шайтан дип торган кешедә өмет буламыни...

Кара егет. Менә ялгыштың, чибәр кыз!

Бану. Эзли торгач, тапты чибәрне!

Хәдичә. Күзе бик майлы, аңар бар да чибәр. Командировочный!

Саҗидә. Күзләрендә ат тоягы эзе бар моның. Кызлар, сак булыгыз...

Кара егет. Өметсез шайтан, дип тә әйтәләр әле сездә.

Бану. Әллә сездә икенче төрле әйтәләрме? Ярый, ярый, күп сөйләшеп торма монда. Бәләк белән кундырырга да күп сорамабыз! Бәләк белән бер тумагансың.

Кара егет. Мин, фәкыйрегез...

Зәйтүнә. Кызлар, җитәрегез инде... фәкыйрь ди бит. Күрше авылдан берәр хәер сорашучыдыр. Әнә мескеннең букчасы да буш күренә.

Бану. Жәлләү дисәң, сиңа куш инде. Әзмәвердәй башы белән хәер сорашып йөрсә, Ходай орыр.

Кара егет. Ул мине күптән орды инде. Тик мин үз эшемне эшли бирәм.

Хәдичә. Букча тоткан бар кеше дә хәерче булмый. Әнә ничек киенеп алган, шайтан!

Кара егет. Әү?

Бану. Син нәрсә дип әле, шайтан сүзе чыккан саен, «әү», «әү» дип торасың, исемең юкмы әллә?

Кара егет. Сез кушкан исем минем үземә дә бик ошап китте әле. Чөнки ул минем җисемемә туры килеп тора.

С а җ и д ә. Кызлар, дим, берәр вак-төяк сатучы түгел микән? Аларның телләренә шайтан төкергән була, чәтердәп торалар...

З ә й т ү н ә. Ярый инде, кызлар, аптыратмагыз кешене. Нәрсә сата микән, сорыйк әле.

Ләйлә әби бер мизгелгә аңына килә. Араларына нинди яман көч кергәнен аңлый. Кинәт каты итеп кычкырып җибәрә.

Л ә й л ә ә б и. Кызлар! Сак булыгыз! Шайтан ул, шайтан!

Б а н у. Акырмасана! Котны алдың! Әллә йокыга киткән идеңме? Шайтан, дип үзебез әйттек бит.

Х ә д и ч ә. Шайтан булмый чурт булсын! Букчасын күрсәтсен әле. Нинди маллары бар икән.

К а р а е г е т. Мин тарак сатучы.

К ы з л а р *(бергә)*. Тарак сатучы?!.

К а р а е г е т. Көзгеле тараклар! Әле менә су анасы берничәне алып калды, шуннан кайтып килү...

Б а н у. Вәйт тиле! Тиле, тиле дигән саен, тигәнәк буе сикерә, диләрме. Чынлап та теленә шайтан төкергән моның. Без дә кимен куймыйбыз, әйе бит, кызлар. Ярый, ярый, су анасына түгел, дию пәриенә сат! Безгә дә күрсәт әле ул таракларыңны, чынлап та көзгелеме?

З ә й т ү н ә (*Ләйлә әбине тарткалый, тегесе өнсез*). Нишләдең? Кызлар, кирәкми, күрсәтмәсен... Ләйлә әбигә әллә нәрсә булды. Әйдәгез, кайтыйк тизрәк...

Х ә д и ч ә. Юк инде, күрсәтсен. Тарак сатучылар самавыр төзәтүчеләр түгел, көн саен килеп тормый.

С а җ и д ә. Шаярта гына торгандыр әле, тарагы булса күптән күрсәтер иде.

Л ә й л ә ә б и (*аңына килеп*). Сорамагыз, тискәреләр! Бетәсез бит! Таныдым мин аны!

Б а н у<br>Х ә д и ч ә } (*икесе бергә*). Аяк астында буталма әле! Күрсәтсен, күрсәтсен! Кайтабыз да китәбез ялындырсаң!

К а р а е г е т. Китмисез. Минем яннан буш киткәннәр юк әле. (*Букчасыннан көзгеле тарак чыгара. Югары күтәрә.*) Менә ул!

К ы з л а р. Көзгеле тарак! Чынлап та көзгеле! Чәчкә кадый торган үзе! Марҗа тарагы!

Б а н у. Гомеремдә беренче тапкыр күрәм.

С а җ и д ә. Искиткеч!

Л ә й л ә ә б и. Кагылмагыз! Алмагы-ы-ы-з! Шайтаннан әйбер алган кеше аның мәңгелек колы булыр!

З ә й т ү н ә. Егет, хакы күпме боларның? (*Кулына алып карый.*) Безнең хәл җитәрлекме?

Кара егет. Хакымы. Хак ярым хак, пот ярым борчак, бер кием чабата, калганы акчалата.

Бану. Ничек, ничек...

Хәдичә. Бер тарак өченме.

Кызлар (*чиратлап.*) Хак ярым хак! Пот ярым борчак! Бер кием чабата! Калганы акчалата!

Кара егет. Дөрес сүзгә җавап юк,
Бәрәңгедә сөяк юк,
Ике сигез бертигез,
Ике чабата бер кием.

Зәйтүнә. Шаяртасыңмы, егет, чын сөйлисеңме, тик бездән андый хакны ала алмассың. (*Тарагын кире бирә.*)

Бану. Шаярта бит ул!

Хәдичә. Мал сатасы килгән кеше шулхәтле шаяртып торырмы.

Саҗидә. Бәясе юнь булса, мин дә берне алыр идем.

Кара егет (*көлә*). Әлбәттә, шаяртам! Кызлар, мин шундый инде, гел шаяртам. Шулай да ун шаяртуга бер җитдилегем бар.

Зәйтүнә. Уен бер булыр... дөресен әйтеп кал егет, ул бәягә безнең тирәдә шул су анасы алса гына инде.

Кара егет. Турысын әйтсәм тагы күпсенерсез... Сезнең өчен аның бәясе берни тормый, ә минем өчен язмыш. Сынап карарга булдым әле...

Зәйтүнә. Язмыш...

Бану. Шайтан язмышка ышаныр икән...

Кызлар. Әйт инде...

Кара егет. Бер таракның бәясе — бер үбү! (*Җырлый.*)

Чәчең озын, чәчең озын,
Тарак кирәк тарарга.
Бәясе бер үбү генә,
Сатучыга ярарга!

Кызлар (*җырлыйлар*).

Малны шундый юнь бәягә
Сатучылар бар микән?
Үпкән-кочкан җилгә очкан,
Дип әйтүләр хак микән?

Кара егет.

Тарак сатам, тарак сатам,
Бәясе зурдан түгел,
Арагызда кайсы кыю,
Тик шуны сайлар күңел.

Кызлар:

Малны шундый юнь бәягә
Сатучылар бар микән?
Үпкән-кочкан җилгә очкан,
Диюләре хак микән?

Кара егет (*Зәйтүнәгә*).

Чәчең озын, чәчең озын,
Тарагың юк тararга,
Кыйгач кашың күрер өчен,
Күзгең дә юк карарга.

Тарак сатам, тарак сатам,
Бәясе үбү генә,
Арагызда кайсы кыю,
Сатам үзенә генә.

Кызлар.

Малны шулай юнь бәягә
Сатучылар бар микән?
Үпкән-кочкан җилгә очкан,
Дип әйтүләр хак микән?

Зәйтүнә. Туктагыз, туктагыз! (*Егеткә.*) Акылың алтын икән, үзең бакыр булсаң да! Һәр егет торса үбеп, авызың китәр җебеп! Бик күп сорамыйсыңмы?

Кара егет. Ике тапкыр үпсәң, ике тарак аласың.

Хәдичә. Малы шәп! Үпкән-кочкан җилгә очкан дигәннәре дөрес ул... Билдән югары — миргә, билдән түбән — иргә!

Сажидә (*үзалдына*). Галигә үптермәдем... Вәлигә үптермәдем... Садыйкка, әй анысы чутланмый... Нәрсә оттым... Кызлар, әллә...

Ләйлә әби (*уянып китеп*). Кызлар, ялгышасыз! Оныттыгыз минем әйткәннәрне!

Бану. Ләйлә әби! Буталма, дидек бит инде. Сине, егылып ялынсаң да, үбәсе юк аның...

Ләйлә әби. Минем язмышымнан гыйбрәт алыгыз. Их, ул ялгышлыклар! Сезнең язмыш белән шаярырга уйлый ул... Үз язмышы түгел...

Бану. Булмаса булган икән, мин риза! Бер үбүдән укам коелмас әле.

Зәйтүнә. Яратмаган кешене үбәмме соң?! Тарак түгел, әллә нәрсә бирсәләр дә — юк!

Хәдичә. Яратуның ни катнашы бар монда! Алыш-биреш бара бит!

Зәйтүнә. Яратуны алышка да, бирешкә дә катнаштырмыйлар! Теләсәгез нишләгез, мин киңәшче түгел.

К а р а е г е т. Анысы шулай, киңәшле эш таркалмас. Ләкин мине үпкән кыз, шушы тарак белән дөньядагы бердәнбер гүзәллеккә дә ия булачак! Гүзәллеккә!!!

Л ә й л ә ә б и. Каравыл, талыйлар! Үтерәләр! Коткарыгыз! Шайтан бар! Шайтан бар! Каравыл!!

Ул кычкыра башлауга, Кара егет югала. Кызлар аны эзләп төрле якка сибеләләр. Сәхнәдә уйга баткан Зәйтүнә белән хәлдән тайган Ләйлә кала. Ә х м ә т җ а н б а б а й керә.

Ә х м ә т җ а н. Кем талый? Кем тия минем Ләйләмә? Гомер буе саклап килгән гүзәлемә кем кул салмакчы була?

Л ә й л ә ә б и. Әнә, әнә тегендә кереп югалды.

Ә х м ә т җ а н. Кем? Кем?

Л ә й л ә ә б и. Шайтан! Ком гарәбедәй кара шайтан, үпмәкче була...

Ә х м ә т җ а н. Синеме? Синеме? Әйт әле, кай төшеңә орынды? Хәзер мин аны... (*Каратэ хәрәкәтләре ясый.*)

Л ә й л ә ә б и. Миндәмени эш! Аңа ышансаң, мине үбәргә дә күп сорамас, бер тарак бәясе генә, ди.

К ы з л а р йөгереп керәләр дә «Әнә тегендә, тегендә» дип чыгып йөгерәләр.

Ә х м ә т җ а н. Ничек диден? Аңлатып сөйлә әле.

Л ә й л ә ә б и. Бер тарак бирсәгез, бер үбәр идем, ди. Телсез-авызсыз итте дә куйды. Әй буталдым инде...

Ә х м ә т җ а н. Синнән тарак сорыймыни? Кем ул, кем?

К ы з л а р тагы йөгереп керәләр.

Х ә д и ч ә. Нишләп тарак сорасын ул аннан? Шушы Ләйлә йөри бөтен нәрсәне бутап!

Б а н у. Тарак сатам, ди, бәясе бер үбү, ди.

Ә х м ә т җ а н. Ләйләме? Әллә теге мин бүләк иткән таракны сатмакчы буласыңмы?

С а җ и д ә. Карагыз әле боларга. Гел алышынып беттеләр... Үбүдәмени хикмәт! Хикмәт гүзәллектә!

Л ә й л ә ә б и. Уф... Шайтан саташтыра. Шайтан... Әйттем мин сезгә, кояш баеган чакта, бу чоңгыл янында йөрмик, дип.

Б а н у. Кая югалды соң ул?

Х ә д и ч ә. Кызлар, мин инде ризалашкан идем...

С а җ и д ә. Мин дә...

Б а н у. Югалды бит, хәерсез! Шул Ләйлә инде, «талыйлар, талыйлар» дип акыра башлады. Кем таласын сине?

Л ә й л ә ә б и. Мин үзем өчен түгел бит, сезнең өчен.

Б а н у. Менә нәрсә, Ләйлә әби, җанкисәккәччәем! Кабаттан ияртеп йөрү бетте сине. Бөтен эшне боздың да ташладың!

Ә х м ә т җ а н. Кем югалды? Кая китте? Аңлатып бирегез әле, шайтан алгырылары!

Кара егет пәйда була.

К а р а  е г е т. Әү! Бабай, кайсысын бирәсең?

Л ә й л ә  ә б и *(Әхмәтҗанга ябыша)*. Мине түгел, мине түгел.

Кызлар Кара егетне уратып алалар.

К а р а  е г е т. Кызлар, бабай барыгызны да бирә бугай, сатулашып тормады.

Ә х м ә т җ а н. Нәрсә дисең? Кайчан әйттем мин ул сүзне?

Б а н у }<br>Х ә д и ч ә } *(бергә)*. Без риза!

Б а н у. Мин беренче!

Х ә д и ч ә. Мин икенче!

С а җ и д ә. Зәйтүнә, ник дәшмисең, син өченче булсаң, мин дүртенче булырга да риза.

З ә й т ү н ә. Белмим инде, Саҗидә, мин куркам. Сиңа соң нәрсәгә матурлык? Бер таракта гына түгел монда хикмәт. Минем өчен язмыш, диде бит ул. Шунысын белергә иде, ахыры ни белән бетәр микән моның...

С а җ и д ә. Ә ул вәгъдә иткән матурлык?

З ә й т ү н ә. Беркатлы син. Шуңа ышандыңмы?

Л ә й л ә  ә б и. Мин беләм аның ни белән бетәсен, мин беләм.

З ә й т ү н ә. Әй Ләйлә әби, син соң кайдан беләсең?

Л ә й л ә  ә б и. Сез белгәнне мин киптереп элгән. Минем кадәр яшәп карагыз әле.

Ә х м ә т җ а н. Яшәп түгел, яратып диген, яратып!

Б а н у. Сезнең ярату бетмәс инде. Тирә-якка даныктыгыз. Хәзер сезнең заман түгел, безнең заман.

Ә х м ә т җ а н. Сөю мәңгелек. Шулай бит, багалмам? Безнең яратудан кеше түгел, шайтан көнләшерлек.

К а р а  е г е т. Мин монда.

Кызлар егетне уратып ала.

Л ә й л ә  ә б и. Акылыгызга килегез! Бирелмәгез аның коткысына!

Ә х м ә т җ а н. Тынычлан, тынычлан... Кая, ниткән шайтан булсын ул, тарак сатучы бит...

Л ә й л ә  ә б и. Син бернәрсә дә аңламадыңмыни, Әхмәтҗан?

Ә х м ә т җ а н. Нишләп аңламыйм, аңладым. Тик мәхәббәтебез хакына мин сине гафу итәм.

Л ә й л ә  ә б и. Гафу итәсең? Димәк, син барысын да беләсең?

Ә х м ә т җ а н. Нәрсәне беләм?

Л ә й л ә  ә б и. Ә нәрсәне гафу итмәкче буласың?

Ә х м ә т җ а н. Мин бүләк иткән таракны сатарга җыенам, диден түгелме соң?

Л ә й л ә  ә б и. Их син! Син бит бернәрсә дә аңламагансың!

Ә х м ә т җ а н. Аңламадым, җаным, аңламадым...

Л ә й л ә  ә б и. Бер сәерлекне дә күрмәдеңме?

Ә х м ә т җ а н. Күрмәдем, җаным, күрмәдем, сиңа гына карап тордым.

Л ә й л ә  ә б и. Их син! Нишләргә соң миңа?

Ләйләгә Шайтанның тавышы ишетелә.
Ләйлә, яшьлек сереңне ачам бит. Кызларны котыртудан тукта. Син таныдың мине. Безнең уртак сер бар. Бүген безнең килешүнең соңгы көне. Гомерлек ярату, дигән идең, яратмадыңмыни гомер буе. Миңа яңа килешү кирәк. Ә сезнең язмыш бүгенге көннән үз кулыгызда. Тик яшьлек узган, узган, узган... Бу тавышны бары тик Ләйлә генә ишетә. Кызлар Кара егет янында кайнаша. Алар Кара егет артыннан ияреп чыгалар. Ләйлә хуштан язып егыла.

Ә х м ә т җ а н. Ай җаным! Тотып кала алмадым. Әйләнчек була инде шулар аркасында. (*Кычкыра.*) Шайтаныма олагыгыз! Мин әйтмәсәм дә, олактылар бугай... Ләйләм генә җан тәслим кыла күрмәсен. (*Битләренә суккалый.*) Әллә үлдеңме, җаным? Мине кемгә калдырып китмәкче буласың? (*Күкрәгенә ятып тыңлый.*) Йөрәге тибә. Әх-мәт-җан, Әх-мәт-җан, дип тибә йөрәге. Әллә нәрсә булган аңар бүген. Йоклап киткәч тагын да матурлана төште. Яратам да үзен, билләһи! Күр инде син аның алсу иреннәрен! Алма кебек кызарып пешкән битләрен! Ул тырпаеп торган колакларына кадәр мәхәббәт сибеп тора бит! Бар матурлыкны бер кешегә өеп бирсә бирә икән, илаһым! Алтмыш ел буе гашыйк мин аңар. Әти-әни ризалыгын көтеп гомеребез үтте. Хәер-фатыйхасыз кая бармак кирәк. Их, туебыз узмаган, туныбыз тузмаган әле! Каным кайнап торган чак! Их, шайтан алгыры!

Әбине ташлап биеп китә. Шайтан музыкасы башлана. К а р а  е г е т керә. Ләйлә әбине күтәреп ала. Музыка туктый, Әхмәтҗан биюдән туктап болар янына килә.

Ә х м ә т җ а н. Һай, рәхмәт төшкере. Үземнең генә көч җитмәс иде. Бирим дигән колына...

К а р а  е г е т. Мин бит син чакырганга килдем.

Ә х м ә т җ а н. Чакырганга?

Л ә й л ә  ә б и (*Кара егетнең кулыннан сикереп төшә.*)

Син мине кемгә күтәртәсең? Белер-белмәс кешегә сөйгәнеңне тоттыргансың.

Кара егет. Ул бит үзе кушты, мин нәрсә...

Әхмәтҗан. Дөрес әйтәсең, җанкисәгем, дөп-дөрес! Кил әле үземә! Башың әйләнеп китте бугай синең... (*Ләйләне бик җиңел генә күтәреп алып чыгып китә.*)

Кара егет. Ләйлә мине таныды. Эшне бозып ташламаса ярар иде. Бирешергә уйламый бу карчык! Әһә!

Нидер исенә төшкәндәй болар артыннан чыгып китә. Зәйтүнә керә.

Зәйтүнә. Кызлар таракчы артыннан йөгерделәр... Кайсысы эләктерер микән? Минем бит әле беркем белән дә үбешкәнем юк. Тарак өчен генә булса һич ризалашмас идем. Гүзәллек бирәм, диде бит... Нишләргә соң?

Каршысына Кара егет чыга.

Зәйтүнә. Ах!

Кара егет. Мине көтәсеңме, Зәйтүнә?

Зәйтүнә. Куркыттың! Шулай капыл дәшәләр димени? Кызлар артыннан йөгергән иделәр, тотмадылармы?

Кара егет. Йөгереп шайтан куып тоткан кешене күргәнең бармы?

Зәйтүнә. Шайтан... Син бит әле исемеңне дә әйтмәдең... Мин Шайтан дисәм, үпкәләмә, яме. Кара әле, тарагың өчен, чынлап та, башка бәя сорамыйсыңмы?

Кара егет. Бәя? Тарак өченме? Юк-юк, башка бәя сорамыйм. Таракның тылсымы...

Зәйтүнә. Әйткән идең шул... Каян килеп чыктың син безгә? Ә син алдамыйсыңмы алай-болай? Нигә әле мин сиңа ышанырга тиеш?

Кара егет (*кулларын селти, һавадан бер бәйләм чәчәкләр тотып ала, Зәйтүнәгә бирә*). Ышандыңмы инде? Бәясен биреп, таракны алган кеше дөньясында беренче гүзәлгә әйләнәчәк...

Зәйтүнә. Беренче? Юк, миңа ул кадәр матурлык кирәкми. Үзебезнең кызлар арасында соңгысы булмасам, шул җиткән. Матурлык булса, бәхетне табу берни тормас...

Кара егет. Бәхетне...Ул бит гел башка төшенчә... Матурлыкка һич тә бәйләнмәгән. Син әле, Зәйтүнә, үзеңнең никадәр матур булганыңны да белмисең икән...

Зәйтүнә. Син мине мыскыл итеп торма, яме. Анысын мин инде бик яхшы беләм. Кызлар аны миңа көненә унар мәртәбә әйтәләр. Озын сүз бозау имезә, артка таяк тигезә, диләрме, әйдә әле, егет, кеше күрмәгәндә эшне бетерик.

К а р а е г е т. Үкенмәссеңме?

З ә й т ү н ә. Нәрсә, сатмаска булдыңмыни тарагыңны?

К а р а е г е т. Сатам. Ә нигә син минем күзләремә карамыйсың, безнең күзләр очрашмаса...

З ә й т ү н ә. Әле тарак сатам, дигән идең... Минем өчен бәясе бик зур булса да күтәрергә әзер идем... Хәзер сиңа минем күз карашым да кирәк икән...

К а р а е г е т. Әгәр дә безнең карашлар очрашмаса, үбешүнең дә, таракның да тылсымы тулы булмас.

З ә й т ү н ә. Ир-ат белән күзгә-күз карашу гөнаһ бит ул...

К а р а е г е т. Гөнаһтан курыккан кеше шайтан белән сүз берләшерме?

З ә й т ү н ә. Үзем дә уйларга уйлаган уемны күземә бәреп әйтмә, яме. Кире уйлавым бар.

К а р а е г е т. Юк, юк, Зәйтүнә, кире уйлый күрмә. Син алмасаң, башкаларга сатмыйм мин ул таракны. Берәү генә ул минем. *(Җырлый.)*

Сине күргәч шайтанлыкны оныттым,
Әйтерсең лә бәхет кошын мин тоттым,
Өметсез шайтан дигәннәр дөрес ул,
Ә син менә өметлегә юлыктың.

Үп мине, Зәйтүнә, үп мине!
Ун гомер эзләдем мин сине!
Тик синнән ярату булмаса,
Дөньяда бер ямь юк лабаса!

З ә й т ү н ә *(җырлый)*.
Нишләде йөрәгем, нишләде,
Карашыңнан күзем камаша,
Шайтанга мәхәббәт булырмы,
Әйтегез, бу нинди тамаша?

Үп, шайтан, үп мине, теләгем,
Кешеләр белсәләр, нишләрмен,
Нәрсә бу, нишләттең йөрәкне,
Аңламыйм үземнең теләкне...

Җырның ахырында Кара егет Зәйтүнәнең чәченә тарак кадый, үбәргә үрелә. Ләкин үбә алмый. Еракта сызгырган тавышлар ишетелә. Кара егет юкка чыга. Зәйтүнә уянып киткәндәй була.

Ут сүнә.

Авыл. Кич булган. Егетләр уен буласы җиргә җыелганнар.

Вахит. Нишләп килмиләр бу кызлар? Күктә йолдызлар җемелди башлады. Карагыз әле, карагыз... Нинди түгәрәк ай бүген...

Садыйк. Айның ундүртенче кичәсе... Хәдичәнең түгәрәк йөзе кебек. Кая йөриләр бу кызлар?

Габдулла. Әти калага киткән иде. Базар шәп булса, читек алып кайтам, дигән иде... Өрләрем яңасын! Аның саурысы синең әбиеңнең намазлыгы кебек чәчәкле булачак. Аның олтаны болгар олтаны, кырыйлары менә болай-болай киселгән булыр. Ну, шул читекне киеп алсам, түбе төшкәнче биер идем биюен!

Вахит. Алла бирсә диген! Синдә читек кайгысы. Кем белән биерсең микән? Кызлар йокларга яткан, ахры, берсе дә күренми.

Габдулла. Килсә алар берәмтекләп килми, килсәләр алар бер кочак килә.

Садыйк. Сиңа кочакларга гына булсын. Кочаклап үлчәргә өйрәнеп беттең бугай инде. Читегең турында хыяллан лутчы.

Вахит. Килмәскә дип ант иткәннәр, ахры.

Габдулла. Аякта читек булса, аларны олаулап та үлчәп була. Минем читекнең балтырлары шадраланып торачак. Үзе чем-кара, елык-елык, бизәкләре, ух! Әле менә шул читекне киеп уенга чыксаммы! Бануны әйтмим дә инде, әле Хәдичәнең дә күзе миндә генә булачак!

Садыйк. Читектә диген...

Габдулла. Ә инде Саҗидә төне буе балавыз сыгачак сине җәлләп.

Садыйк. Тимә Саҗидәгә...

Габдулла. Әй, карагыз әле, Саҗидәгә тимәскә кушкан була...

Садыйк. Әй хыялый чабатачы! Башта киеп кил дә биеп күрсәт! Аннан күрәзәлек итәрсең!

Габдулла. Читекләрем әкрен генә, менә шушылай тутый коштай атлауларымы шы-гыр, шы-гыр итеп...

Вахит. Гыр, гыр! Синең читек түгел ул, безнең кызлар шулай йоклый!

Габдулла. Ә инде ул читекне мин, аякларымны исле сабын белән генә юып, чем-ак чигүле чолгауларга гына урап, кичке уенга гына киеп чыгачакмын!

Садыйк. Җитәр инде шул читегең белән! Косасыны китерә башлады! Читек сандугачы! Салып торып җибәрермен!

Габдулла. Ә-ә-ә-ә! Шулайдыр шул! Кеше аягындагы яңа читек костыра ул! Көнче күбәләкләр!

Вахит. Туктагыз әле! Шым, дидем бит! Әнә киләләр!

Садыйк гармун уйный башлый, Ләйлә белән Әхмәтҗан керә.

Садыйк (*боларны күреп, уйнаудан туктый*). Ләйлә әби бит, сакаллы сабые белән.

Әхмәтҗан. Әссәламегаләйкем, яшьтиләр!

Садыйк (*аны үчекләп*). Саламыңа печән! Кордашлар, чордашлар!

Вахит. Замандашлар! Күршеләр! Авылдашлар!

Габдулла. Мәхәббәт күбәләкләре!

Әхмәтҗан. Әссәламегаләйкем, Габдуллла!

Габдулла. Саламыңа печән, Әхмәтҗан! Иртәгә әти каладан кайтырга тиеш. Яңа читек, мин сиңа әйтим...

Әхмәтҗан. Вәгаләйкүмәссәлам икән болар...

Садыйк. Кызлар күзегезгә чалынмадымы алай-болай, бигрәк тә Саҗидә?

Әхмәтҗан. Чалындылар, чалындылар! Хәзер килеп җитәрләр. Алар бит гел минем күз алдымда. Күздән яздырган юк аларны. Яраткач, менә шулай кулларыннан гына тотып йөртергә кирәк. Шайтан алгырылары! Әй, алмагырылары!

Ләйлә әби. Нәрсә лыгырдап утырасың инде. Кирәкмәгән сүз сөйләп. Исән-имин котылганыбызга шөкер диген.

Егетләр (*барсы да бергә*). Нәрсә булды! Нәрсәдән котылдыгыз! Кызлар белән бер-бер хәл булдымы әллә?

Ләйлә әби. Су чистарак булыр дигән булып, таллы чоңгыл янына кер чайкарга барган идек бүген...

Габдулла. Әллә берәрсе баттымы?

Садыйк. Саҗидә, исәнме, Саҗидә?

Әхмәтҗан.Сезнекеләр исән. Язган булгач Ләйләмне дә коткарып калдым.

Музыка башлана. Сәхнәдән Кара егет узып китә. Аны күрмиләр. Тәэсире Ләйлә әбидә.

Ләйлә әби. Беләсезме су буенда бүген кемне күрдек?

Әхмәтҗан. Кемне дисеңме?

Ләйлә әби. Синнән сорамыйлар бит. Тик кенә тор әле. Сорау гына бирәм. Беләсезме бүген су буена кызлар янына кем килгән иде?

Егетләр (*бергә*). Кем? Кем килде? Әйт инде!

Ләйлә әби (*як-ягына карана. Кара егетне күрә, аның тәэсирендә*). Бүген су буенда Габдулланы күрдек. Күрдек кенәме, мин сиңа әйти-и-и-м...

Габдулла. Мине?! Ләйлә әби! Саташа башладың, ахры. Иләх-миләх диген, як-ягыңа төкер! Әле яңа гына басудан кайттым, атны эчерергә дә су буена энекәш китте.

Ләйлә әби. Ничек инде энекәш китте? Син идең, син! Миңа ышанмасагыз, кызлардан сорагыз, алар да күрде. Шуңа күрә гарьләнеп, шушы вакытка кадәр уенга да килми, өйләрендә утыра булырлар.

Габдулла. Нәрсә! Мәхәббәтеңнән шаштыңмы әллә! Ни калган миңа су буенда көпә-көндез?

Ләйлә әби. Әһә-әһә, көпә-көндез булса бер хәл иде, эңгер-меңгер башланган чакта килдең шул...

Садыйк. Тукта әле, тукта! Габдулла! Нәрсә эшләп йөрдең анда, су буенда кеше котын алып? Әйтәм җирле баядан бирле кызларны олаулары белән үземнеке итәм дип шапырына!

Вахит. Сөйлә әле, сөйлә, утсыз төтен булмый ул!

Габдулла. Нәрсә тыңлап утырасыз шуны! Ләйлә әби чыгарган төтен бит ул. Утырма монда, әби булсаң әби бул!

Әхмәтҗан *(сикереп тора)*. Кем әби! Әби булып нишләгән ул. Ул бит... ул...

Садыйк. Кызма, Әхмәтҗан, кызма! Хәзер чын йөзен ачабыз ул читек сандугачының. Шуннан, Ләйлә әби?

Габдулла. Туктагыз әле, егетләр, шаярта бит ул...

Ләйлә әби. Шаярта? Әле син аны шаяртуга кайтарып калдырмакчымы? Сөйлим болай булгач, әле җәлләп тора идем. Тапкан шаяртыр нәрсә...

Егетләр. Сөйлә, сөйлә...

Ләйлә әби. Шулай, бөтен елганы иңләп кенә, җырлыйҗырлый кер чайкый башладык. Менә мин болайрак бастым, басма башына бүген дә Бану кунаклады, билләһи менә. Хәдичә чолгаулары белән минем кырыемда кайнашты...

Садыйк. Ләйлә әби! Ул төшен кыскарак тот, ух, читек сандугачы!

Ләйлә әби. Шулай итеп, матур гына тезелешеп тотынган идек, теге әрәмәдәге юан тал артыннан Габдулла килеп чыкмасынмы! Аягында өр-яңа читекләр! Ә үзе, ә үзе, анадан тума шәп-шәрә! Искәйләре дә китми!

Габдулла. Шәп-шәрә?! Яңа читекләр белән? Нәрсә бутыйсың? Ул читекләрнең кайтканы юк бит әле!

Вахит. Юктыр шул! Чигүләренә кадәр тәфсилләп сөйләп тордың.

Садыйк. Ташлагыз әле шул читекләрне! Шәп-шәрә дидеңме?

Ләйлә әби. Шәрәнең дә шәрәсе, менә анадан тума!

Габдулла. Тик читек белән туган, иеме?

Вахит. Сүзне кирегә борырга маташма. Нишләдең әрәмәдә шул хәлдә?

С а д ы й к. Җитәрегез инде, су коенгандыр...

Л ә й л ә  ә б и. Коенды ди! Коенмаган кая! Шәрәлеге генә җитмәгән, күзләрен җамаяк тәрилкәсе кебек акайткан, әнә, әнә карагыз әле үзенә! Шул, үзе елмая, әнә нәкъ шулай итеп... ә сулышлары... *(Габдулла, урыныннан торып, Ләйлә янына килә башлый.)* Кит, нәрсә миңа киләсең! Ә сулышлары бәйгедән кайткан айгырныкы сыман... Ух-х-х-х, кит янымнан!

Г а б д у л л а. Юк, монысына түзәрлегем калмады! Олы кеше дип тормам, соңгы тешеңнән мәхрүм итәм хәзер!

Габдулла, йодрыкларын төйнәп, Ләйләгә килә. Әхмәтҗан сикереп торып, араларына баса. Егетләр Габдулланы туктаталар, көләләр.

В а х и т. Шуннан... Сөйлә әле, Ләйлә әби, сөйлә...

Л ә й л ә  ә б и. Нәрсә турында сөйли идем әле?

В а х и т. «...сулышлары бәйгедән кайткан айгыр сымак...» дигән җирдә туктаган идең.

Л ә й л ә  ә б и. Ие, су буйларын менә шулай итеп (*сикереп-сикереп йөреп күрсәтә*) әйләнеп чыкты да, безгә теге ... ниен күрсәтә башлады.

С а д ы й к. Ниен?!

В а х и т. Ну, Габдулла, малай, чигенә барып чыккансың икән!

С а д ы й к. Шым, диләр сиңа! Әйт әле, Ләйлә әби, нәрсәсен күрсәтте? Оялма, оялма, бу инде ояттан узган.

Л ә й л ә  ә б и. Нәрсәсен күрсәтсен! Тарак күрсәтте. Көзгеле тарак, мин сиңа әйтим. Читек кунычыннан шалт итеп тартып чыгаруы булды, бөтен дөнья күк капусы ачылгандай ялт итте!

Ә х м ә т җ а н. Тукта әле, Ләйлә, нәрсә сөйлисең син, җанкисәгем?

Л ә й л ә  ә б и. Нәрсә сөйләдем әле мин ул кадәр. Әллә нәрсә булды әле миңа, башым әйләнеп тора... Соң шуннан... нәрсәсен сөйләп торасың инде. Габдулла тарагын күрсәтүе булды, шулчак кызлар, мин беренче, мин беренче дип кычкырып, Габдулланың артыннан йөгерешә башладылар.

Е г е т л ә р (*барсы бергә*). Шуннан?!

Л ә й л ә  ә б и. Шуннан нәрсә инде, кызларны бер-бер артлы ияртте дә, Сәҗидәсенә хәтле мин дә кешедән калмыйм, дигәч, әрәмә арасына алып кереп китте. Йа Ходай! Нәрсә сөйлим мин?! Әстәгыфирулла! Әстәгыфирулла!

В а х и т. Үтерәм! *(Габдуллага ташлана.)*

С а д ы й к. Бетерәм хәшәрәтне!

Егетләр Габдулланы дөмбәсләргә тотыналар.

Г а б д у л л а. Ай, борыным, борыным! Кан мәллә бу? Ах!.. *(Хәлсезләнеп җиргә авып төшә. Егетләр куркып кала.)*

Вахит. Әллә үлде инде?

Ләйлә әби. Егетләр, ни эшегез бу? Нишләттегез Габдулланы?

Садыйк. Ләйлә әби, әле яңа гына аның этлеген сөйләп тордың бит!

Ләйлә әби. Мин? Габдулланың этлеген? Әхмәтҗан, нәрсә яла ягалар миңа? Нишләп Габдулла булсын ул? Су буена, кем, кайсыгыз соң әле, аты беткере! Вахит, син килгән идең бит! Габдулланың монда ни катнашы бар!

Садыйк. Кая куйдың Саҗидәне? Нәрсә эшләдегез әрәмәдә?

Ләйлә әби. Туктагыз, тукта! Әхмәтҗан, әллә тагы саташам инде? Юк, юк, Садыйк иде ул! Менә чәчрәп китим! Мыегы, мыегы бар иде! Башка җиренә карарга оялып, мыегыннан күземне дә алмадым.

Егетләр тораташ катып калалар. Аннан соң йодрыкларын йомарлап, өчесе дә Ләйлә әби ягына борылалар.

Әхмәтҗан. Сабыр, егетләр, сабыр... Мәхәббәт башына бәргән чибәремнең... зиһене таралган... Берегезне имгәтеп ташладыгыз бит инде. Аңлашыйк әле, Ләйлә...

Егетләр (*барысы бергә*). Вәйт ике тиле! (*Кулларын селтәп, урыннарына барып утыралар.*) Боларның сүзен тыңласаң, башың Себер китәр...

Шул вакыт урамның икенче ягыннан дуамал куалашып кызлар керәләр. Егетләргә игътибар итмичә, тарак сатучы эзлиләр дә куышып чыгып китәләр.

Габдулла (*авырткан борынын тотып*). Нәрсә булган бу кызларга?

Вахит. Килеп тә җиттеләр, үтеп тә киттеләр...

Садыйк. Кемне куалыйлар алар?

Вахит. Ләйлә әбигә күренгән теге шәрә, тьфү телгә алырга да оят, кызларга да күренмәдеме икән?

Габдулла. Тик менә кем кыяфәтендә күренде микән ул, шайтан!

Садыйк. Кем генә булып күренмәсен, кызларның йөрәкләре урыныннан купкан!

Вахит. Нәрсә күреп йөгерделәр соң алар? Безгә борылып та карамадылар?

Ләйлә әби. Шуның эше бу, бары шуның эше...

Егетләр. Кемнең эше?

Ләйлә әби. Кем булсын, Шайтан эше. Нәрсә сезнең күзләр тасырайган, сезгә дә берәр хәл булдымы?

Габдулла. Баш китәр болар белән. Әле яңа гына барыгызны да су буенда анадан тума күрдем, дип котны алдың!

Хәзер кызлар безне барга санамый узып киттеләр! Нәрсә булса да бар авылда, буш нәрсәләр түгел бу.

Л ә й л ә  ә б и. Нәрсә?! Анадан тума дип сөйләдемме? Әллә җанкисәккәйләрем тилебәрән орлыгы ашадыгызмы? Шундый сүзләр сөйләргә ничек телегез әйләнә? Әле сезнең барчагызны да беренче күрүем бүген. (*Әхмәтҗанга сыена.*)

Ә х м ә т җ а н. Егетләр, үзем дә аңламыйм мин бу кызны бүген. Үзен-үзе белештерми башлаган. Ләйләм, алтыным, бағалмам, мине таныйсыңмы, бәгърем?

С а д ы й к. Алтынның да алтыны! Синең сүзең белән Габдулланы үтерә яздык.

В а х и т. Кеше сүзе кеше үтерә, диләр, дөрес икән.

Г а б д у л л а. Бетерик. Очына чыгыйк шушы урында. Йә, кемне күрдең инде болай булгач, чынлап та шәрә идеме?

Л ә й л ә  ә б и. Кит, оятсыз... Кыз кешегә шундый сүзләр сөйләп торма!

Кара егет болар арасында йөри. Бу буталчыктан эче катып көлә. Ул канәгать.

Г а б д у л л а. Әкиятләрең беттеме инде? Синең аркада әнә борын нәрсәгә әйләнде. Бануга ничек күренермен?

С а д ы й к. Матур күренерсең. Чибәрләр чибәр күренми, сөйгән чибәр күренә.

В а х и т. Кызлар безне кәкре каенга терәтте бүген.

С а д ы й к. Әйдәгез, кызларны эзләп килик әле. (*Гармунын уйнап җибәрә. Җыр башлана.*)

Урамыгыз кар икән,
Үтеп булмый көрәксез,
Шәфәкъ баткан, картлар яткан,
Нигә чыкмый, йөрәксез.

Урамыгыз төз түгел,
Төзәтүче без түгел,
Кызлар үзе ялынмаса,
Ялынучы без түгел.

Урам буе, юл буе,
Идел буе, су буе,
Көттем, җаныем, көннәр буе,
Йокламадым төн буе.

Кашың кара нилектән,
Битең кызыл нилектән,
Авыр сүзләр дә әйтмәдем,
Хәтерең калды нилектән?

Егетләр җырлап чыгып китәләр.
Тарагын күкрәгенә кысып, Зәйтүнә керә. Җырлый.

Авыл арасын узаем,
Яшел ефәк сузаем,
Яшел ефәк күз яшьләрем,
Синсез ничек түзәем.

Кушымта:

Чәчем озын, чәчем озын,
Тарагым юк тарарга,
Кыйгач кашым, күз карашым,
Көзгем дә юк карарга.
Бер үбүгә бер таракны
Кемнәр сата, кайсыгыз,
Тарак алам, тарак алам,
Бәясен сорамагыз.

Кара егет (*җырлый*).

Урамыгыз төз икән,
Төз җирләре тоз икән.
Кеше сүзе буш икән,
Сөеп туймас кыз икән.

Кушымта:

Чәчең озын, чәчең озын,
Тарагың юк тарарга,
Шушы бер тарак җитә бит,
Бәхетеңне табарга.
Тарак сатам, тарак сатам,
Бәясе юнь, күрегез!
Кыюларның бәхете артыр,
Бер суырып үбегез!

Зәйтүнә егетне күреп ала.

Зәйтүнә. Шайтан!

Кара егет. Әү! Әү, әү... (*Кайтаваз булып ишетелә, Кара егет югала.*)

Зәйтүнә. Әй Кара егет, кая югалдың? Әллә күземә күренә башлады инде. Бу бит аның җыры. Кыюларның бәхете артыр... Бөтен тәнем калтырый. Чык төшә бугай... Кызык... Тарак миндә, ләкин үпмәде бит ул мине. Бирде дә куйды. Язмыш дип тә сөйләнгән иде. Нәрсә әйтәсе килде микән ул тикле олы сүз белән. Хәзер үк елга янына барам да табам әле үзен. Со-

рыйм әле... Нәрсә дип сорармын соң? Кара әле, егет, син нигә миңа бу таракны бушка гына бирдең дип сораргамы? Әгәр дә ул миңа, матур булсаң башкалар кызыгыр иде, башкалар үбәр иде, мин бит кызгандым сине дисә... оятымнан кая керермен... (*Таракның көзгеле ягыннан карый.*) Тарак миндә, ә матурлык юк. Тәвәккәл таш яра, диләр. Булмаса булган икән! Барам елга янына... Әй, кем ул анда? Әллә синме? Ал тарагыңны, шайтан! Үпмисең икән, тарагың кирәк түгел миңа!

Шаулашып, парлашып, егетләр-кызлар керә. Зәйтүнәнең юлын бүләләр, ул аларны аралап чыгып китә алмый.

Егетләр. Сукыр тәкәле уйныйбыз, сукыр тәкәле! Габдулла йөртсен, Габдулла! Аның күзләре берсе мәгърибтә, берсе мәшрикъта, яулык бәйләмәсәң дә була!

Габдулла. Күз бәйләп түгел, башыма чиләк кидертсәгез дә, тотам кирәген!

Вахит. Борын чиләккә сыяр микән соң?

Габдулла. Күп сөйләшеп торсаң, синекен үземнеке белән тигезләргә дә күп сорамам!

Кызлар. Ярар, ярар! Тагы әтәчләнергә тормагыз. Менә яулык.

Габдулланың күзен бәйлиләр, ул эзләргә керешә. Сибелеп качалар.

Габдулла (*эзли*). Әй, сез кайда, күк-күк!

Зәйтүнә. Мин монда... күк-күк!

Габдулла. Мин хәзер... хәзер тотам үзеңне!

Зәйтүнә (*күзен йома*). Мин көтәм...

Габдулла Зәйтүнәне тотып ала, яулыгын чишә.

Габдулла. Зәйтүнә!

Зәйтүнә. Син! Ә ул кая югалды?

Габдулла. Кем?

Зәйтүнә. Койрыклы җен! Үзең бер дә кайтыш түгел икән... Тарак сатучыны әйтәм.

Габдулла. Тагы шул тарак сатучы! Ну, очратсам үзен! Кабыргаларын санар идем!

Яшеренгән җиреннән Бану чыга, Габдулла белән Зәйтүнәне күрә.

Бану. Әһә! Менә син ничек итеп эзлисең икән! Сукыр тәкәле уйныйбыз дигәч тә, гел сукыр тәкәгә әйләнмә инде.

Габдулла. Тукта әле, Бану! Ул бит үзе минем кочакка килеп керде!

Бану. Үзе! Беләм мин синең кем икәнлегеңне! (*Чыгып йөгерә.*)

Габдулла. Ух, Зәйтүнә... Бану, дим, Бану!..

Зәйтүнә. Йөриләр шунда... Үзләре сукырлар, җитмәсә, күзләрен дә бәйләп куйганнар.

Хәдичә белән Вахит керә. Күз карашлары белән сүз берләшәләр. Вахит, арттан килеп, Зәйтүнәнең күзен каплый.

Зәйтүнә. Ай! Кем бу? Синме? Таныдым! (*Вахит кулларын ала.*) Вахит...

Хәдичә. Ә менә монысы Хәдичә!

Вахит. Кемне көтә идең?Синең егет хәзер килеп җитәр! Чабата башы чыгып калган иде! (*Көләләр.*)

Зәйтүнә (*Вахитны этеп җибәрә*). Сине түгел!

Шул вакыт шаулашып егетләр-кызлар килеп керә. Ләйлә белән Әхмәтҗан да аларга ияргән.

Хәдичә. Тимә Вахитка! (*Зәйтүнәгә ташлана, чәченнән эләктерә, аннан тарак килеп төшә.*) Тарак! Көзгеле тарак!

Зәйтүнә. Бир! Ул минем чәчтән төште!

Хәдичә. Тапкан табыш, түләп алыш! Якын килмә!

Зәйтүнә. Бир диләр сиңа! Ул минеке!

Хәдичә. Ха-ха! Кызлар! Егетләр! Зәйтүнә тилебәрән орлыгы ашаган! Ярдәм итегез! Үтерә!

Тавышлар.

— Нәрсә булды?

— Ни бар?

— Көзгеле тарак!

Хәдичә. Зәйтүнә минеке дип талаша!

Бану. Кай арада эләктерден әле син аны, мыштым!

Хәдичә. Без аның бәясен беләбез!

Саҗидә. Кызлар, Зәйтүнәнең...

Бану. Буталмасана әле, апаем...

Зәйтүнә. Су буеннан кайткач кына күрдем мин аны. Минеке ул хәзер... җибәрегез мине... (*Таракны кире тартып ала.*)

Ләйлә әби. Хараплар гына булгансың икән...

Зәйтүнә. Бу юлы миңа синнән киңәшләр кирәк түгел, Ләйлә әби.

Габдулла. Тапканнар шаккатыр нәрсә! Көзгеле тарак, имеш! Ахирәт гамәле мәллә ул! Менә базардан без дә алып кайтырбыз әле, әйеме, егетләр!

Бану. Сезме?! Телегез генә сезнең!

Хәдичә. Төне буе сукыр тәкә булып йөрдегез, йә, кайсыгыз нәрсә бүләк итте?

Саҗидә. Зәйтүнә, тотып карыйм әле... Тарак дисәң дә

тарак! Чәчеңне тарыйсың да, көзгедән карыйсың... Менә бүләк, ичмасам...

Габдулла. Бүләк?! Кем бирсен аңар бүләк!

Зәйтүнә. Бирүчеләр табылды! Хуҗасы мин!

Егетләр. Кем бүләк иткән? Кем ул, кем?

Зәйтүнә. Күп белсәгез, тиз картаерсыз!

Бану. Кем бүләк итсен аны Зәйтүнәгә! Кызлар! Без бит ул таракның бәясен беләбез, әйе бит!

Кызлар. Беләбез! Беләбез!

Бану. Ә Зәйтүнә андый хакны бирә торганнарданмы? Юк шул...

Егетләр. Нәрсә турында алар? Нинди хак...

Бану. Димәк, ул аңар ялынып, ялварып, шай... үп әле мине, дип, үп, дип...

Кара егет керә. Аны күрмиләр. Бану ярты сүздә туктап кала, көләргә тотына.

Егетләр. Тилерденңме әллә? Нәрсә кызык таптың? Кем биргән аны? Кем?

Хәдичә. Әйтсәң әйт инде... ерык авыз... Таракны безгә... су буенда... күрдек... *(Көләргә тотына.)* Ха-ха, хи-хи... Үләм...

Вахит. Хәзер монысы тотынды.

Садыйк. Ләйлә әбигә күренгән теге шәрә кызларга да күренмәдеме икән?

Габдулла. Миңа уйлый күрмәгез тагы! Ләйлә әби барысызны да күрдем, диде.

Садыйк. Саташмаган булса... Ләйлә әби, син аңлатсаң гына инде...

Ләйлә әби. Мин аңлаттым бит инде. Су буенда шай... *(Көләргә тотына. Кызлар барысы да көлә. Егетләр аптырашта.)*

Садыйк. Юкка түгел бу, егетләр. Шүрәле кытыклый мәлләә боларны. Кызлар, без... *(Төчкереп җибәрә.)* Борын кычыта башлады әле...Зәйтүнәгә бүләк, әллә миңа күчтәнәч тия инде...

Габдулла. Миңа тигәне тимәсен *(Төчкерә.)* Борын кычыта, үләм! Алла борыным, борыным!

Вахит. Әпчехи, әпчехи!

Тыела алмыйча төчкерәләр. Әхмәтҗан да калышмый. Бары Зәйтүнә генә көлми дә, төчкерми дә, таракка карап юана. Барысы да бу хикмәтнең Зәйтүнәдән чыкканлыгын аңлыйлар. Төрлесе төрле якка кайсы көлеп, кайсы төчкереп таралышалар.

Зәйтүнә. Таралыштылар... Әй егет! Шайтан егет! Синең эш бит бу әйеме? Син мине яклап калдың... Ни өчен?.. Шулай итеп, минем дә яклаучым булдымыни? Нинди бәхет! Кем син, җенме, шайтанмы, миңа барыбер! Рәхмәт сиңа! Ә бүләгең өчен

нинди рәхмәтләр әйтсәм дә аз булыр. Кызлар көнләшеп үлә яздылар. Ишетәсеңме, әй! Син кайда? Нигә син бу таракны миңа бушлай бирдең? Нигә үпмәдең мине? Син мине җәлләдең бары... Яклавың да шуннан гына... Минем яратасым килә! Өзелеп, шашып яратасым килә!

Шайтан музыкасы яңгырый. Зәйтүнә бии башлый. Сәхнә алдыннан Кара егет үтә. Ул йонлач, чын шайтанның үзе.

Пәрдә

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Урман янындагы болынлык. Еракта елга күренә. Көтү чираты бүген Зәйтүнәдә. Зәйтүнә чәчәкләрдән такыя үреп кигән, кулында яңа туган яшь бәрән.

Зәйтүнә. Һәс, һәс! Кая чамалыйсың! Туймас тамак! Болын гына җитмәгән, урман печәнлегенә чамалыйсыңмы? Һәс! Анда сине бүре тансыклагандыр... Һай! Ристан! Сугыш чукмары! Тагы мөгезсез каласың киләме? Хәзер җәйләүгә алып төшәрбез... Су эчертермен үзегезгә...(*Бәрәнне сөеп.*) Ә кечкенәләр барысы да матур...

Бану, Хәдичә, Саҗидә күренә. Алар кача-поса Зәйтүнәне күзлиләр.

Бану. Әнә, әнә! Сарыкка әби булган... кулында яңа туган бәрән!

Саҗидә. Уф, үләм, пештем... Бу эссегә ничек түзә ул... Кызлар, әллә кайтабызмы?

Хәдичә. Шыңшыма әле... тотынды... ни күреп иярдең соң?..

Бану. Туктагыз әле... Сарыкларны җәйләүгә алып төшкәч, черем итәргә ятмый калмас... Чиратта мин үзем гел шулай итәм. Зәйтүнә йоклап китүгә, әкрен генә үрмәләп киләсең дә чәченнән таракны шалт! Шылдымы?

Саҗидә. Кызлар, мин куркам... Әллә бүгенгә калсынмы?

Хәдичә. Мин булып мин дә шүрләп куйдым әле...

Бану. Уйламагыз да! Менә әйтегез әле, ни пычагыма аңар тарак? Егете-фәләне юк! Бу — бер! Аның тубал чәченә керә торган тарак түгел ул! Бу — ике! Аннан соң нишләп ул тарак Зәйтүнәдә булырга тиеш әле, ә?

Саҗидә. Монысы була өч...

Бану. Саный беләсең икән, акыл керә башлады сиңа да.

Хәдичә. Карагыз әле, карагыз, кем белән сөйләшә ул анда?

Саҗидә. Әллә янында берәр кеше бармы?

Х ә д и ч ә. Кызлар, кызлар, үләм... сарык бәрәннәре белән сөйләшә... Хи-хи, мәдрәсә ачкан, әдәп-әхлакка өйрәтеп маташа, үләм...

Кызлар күзәтәләр. Зәйтүнә чәченнән тарагын ала. Көзгесенә карый, моңсуланып китә. Таракны чәченә кадый да йокларга ята.

Б а н у. Әйттем бит, әнә йокларга ятты ул. Хәдичә, Аллага тапшырдык...

Х ә д и ч ә. Әллә Саҗидә генә барып килсенме?

С а җ и д ә. Нишләп мин, башта ук син дип сөйләштек бит...

Б а н у. Ул җебегәнгә ышансаң, «Зәйтүнә, тарагыңны биреп тор әле»,— дип уятып сорар. *(Саҗидә үпкәли.)*

Б а н у. Көпә-көндез нәрсәдән куркасың? Сарык бәрәннәре тотып ашамас әле...

Х ә д и ч ә. Бәрәндәмени эш! Зәйтүнәдән куркам мин!

С а җ и д ә. И Ходаем, никләр генә иярдем икән сезгә...

Б а н у. Җитәр инде...Хәдичә, сыз!..

Хәдичә Зәйтүнә ягына үрмәли башлый. Кызларга борылып карый, тегеләр көч биреп, кул болгыйлар. Кинәт Хәдичә сикереп тора да чәбәләнә башлый, атылып-бәрелеп кызлар янына килә.

Х ә д и ч ә. Үләм, үләм... Чакты, чакты!

С а җ и д ә. Нәрсә чакты, елан мәллә?

Х ә д и ч ә. Таяк белән суккандай итте! Шөпшә бугай! Үләм! Үләм! Безелди! Чәчкә керде, чәчкә! *(Чәчләрен туздыра, куа, чәбәләнә.)*

Б а н у. Монда килмә, монда килмә! Селтәнмә, диләр!

Х ә д и ч ә. Нәрсә катып калдыгыз! Ярдәм итегез! Шөпшә оясы анда! Шөпшә!

С а җ и д ә. Акырмасана! Хәдичәкәем! Хур булабыз бит!

Х ә д и ч ә. Үлүләрем шушы икән! Кияүгә дә чыкмый әрәм булам бит! Ай, тагы берсе чакты!

Б а н у. Елан чакмаган бит, корт чаккан! Уятасың хәзер Зәйтүнәне...

Х ә д и ч ә. Уянса уянсын! Бер тарак өчен җанымны фида кылыр хәлем юк! Безелди бит, тотыгыз инде! Алла, борыным!

Кызлар чәбәләнә-чәбәләнә Хәдичә яныннан качалар, Зәйтүнә янына киләләр. Хәдичә дә алардан калмый.

Х ә д и ч ә. Зәйтүнә! Үләм! Коткар! Корт чакты! Шөпшә бугай... Салкын су! Су бир... Су бир...Яна! Яна!

З ә й т ү н ә *(сикереп тора)*. Ут бар мәллә? Кем яна?

Х ә д и ч ә. Яна! Яна! Борыным яна! Су бир!

С а җ и д ә }
Б а н у } *(бергә)*. Корт чакты! Хәдичәгә күч сарды бугай!

З ә й т ү н ә (*ярдәмгә ашыга*). Чәбәләнми генә тора беләсеңме син? Хәзер угын алам. Бал корты чакканга дөнья җыеп акырасыңмы? Шифалы бит аның чагуы.

Х ә д и ч ә. Пычагыма кирәкме аның шифасы! Борыным, әнекәйләрем!

Хәдичәнең борыны шешеп чыга. Бану белән Сажидә көләләр.

З ә й т ү н ә. Тынычлан, диләр сиңа! Туеңа кадәр шиңәр әле... Әнә үги ана яфрагы капла...

Х ә д и ч ә. Туеңа чаклы? Кичке уенга ни борын белән чыгармын? Вахитка ничек күренермен?

З ә й т ү н ә. Әзрәк битеңне каплап торырсың, миннән курыкмыйлар бит әле.

С а җ и д ә (*ярарга тырышып*). Хәдичәкәем, борының үсә башлады әкренләп. Кып-кызыл, үзеңә дә күренә торгандыр, әйеме?

Х ә д и ч ә. Кит моннан, син мыскыл итеп тор тагы!

Б а н у. Зур түгел, зур түгел! Килешеп кенә тора!

Х ә д и ч ә. Көлегез инде, көл! Мин дә көләрмен әле! А-а-а-а...

З ә й т ү н ә. Җитәрегез инде, нәрсә йөрисез монда эш ташлап? Әллә миңа чәй алып килдегезме?

С а җ и д ә. Безме? Без?..

Б а н у. Җиләккә дип уйлаган идек...

З ә й т ү н ә. Көтүлеккәме? Бирелә кәҗә шомыртлары гына... Савытларыгыз кайда?

Х ә д и ч ә. Без бит уйлаган гына идек... Уйладык, уйладык та, бармаска булдык. Су кереп чыгарбыз мәллә дигән идек, уйладык, уйладык та...

З ә й т ү н ә. Кешечә ялганлый да белмисез. Мине сагынып килмәгәнсездер бит?

Б а н у. Тукта әле, Зәйтүнә, матурлап кына сөйләшик әле...

Х ә д и ч ә (*катгый*). Күрсәт теге көзгеле тарагыңны! Вәйт шул!

З ә й т ү н ә. Ә-ә-ә! Күптән шулай дияргә иде аны.

Б а н у. Чынлап та, шушы булдымы дуслык? Үзенә алган, безнең турында уйлап та карамаган!

З ә й т ү н ә. Сиңа кирәк ул егет, үзең эзлә, дип, Бану, син әйттең түгелме соң?

Б а н у. Ярый инде, юкка да ачу саклап йөрмә. Үткән эшкә салават. Кабат туры килсәме! Күрсәт тарагыңны!

З ә й т ү н ә. Кичә карадыгыз бит инде, тагы ни кирәк?

Х ә д и ч ә. Нәрсә карадык? Караңгыда рәтләп күреп тә булмады.

Зәйтүнә таракны кызларга бирә.

Зәйтүнә. Мәгез, күргәнегез, күрмәгәнегез шул булсын!

Кызлар таракны кулдан-кулга йөртәләр, көзгесеннән карыйлар.

Саҗидә. Әнекәйләрем! Шундый тараклар да булса була икән дөньяда!

Бану. Китер әле үземә.

Хәдичә. Искиткеч! Мал дисәң дә мал инде!

Бану. Зәйтүнә! Бир миңа бу таракны! Синең чәчләргә ярый торган тарак түгел бу! Әйдә, менә көмеш беләзеккә алыштырыйк әле?

Хәдичә. Ни өчен сиңа? Зәйтүнәкәем! Үземә бирсәң, гәрәбә муенсаларым синеке!

Саҗидә. Гел сез беренче инде. Миндә дә алыштырыр әйбер бар ла ул... (*Алкаларын салырга тотына.*)

Зәйтүнә. Кызлар, мәшәкатьләнмәгез. Берегезгә дә тәтемәс.

Кызлар (*бергә*). Нәрсәгә ул сиңа! Синең тубал башка тырма тешле тарак та таман!

Зәйтүнә. Бирмим булгач, бирмим! Мин аны сатып алдым.

Бану. Синме? Сатып?!

Хәдичә. Без бит аның бәясен беләбез.

Саҗидә. Мин дә беләм. Аның бәясе бер үбү, әйе бит, кызлар?

Бану. Менә, менә... Сине кем үпсен, Зәйтүнә! Турысын әйткән туганына ярамаган ди, бигайбә, дөресе шул!

Хәдичә. Синең үзеңне көзгедән караганың бармы?

Зәйтүнә. Син дә көзге дип сөйләшеп торасың, тукмак борын! Үзеңне бел.

Хәдичә (*ике куллап борынын каплый*). Минем борын ул вакытлыча гына. Мин...

Бану (*Хәдичәгә*). Шым! (*Зәйтүнәгә.*) Димәк, син... ул сораган хакны тулысы белән бирдең? Димәк, син аңар үптердең?

Зәйтүнә дәшми.

Бану. Дәшмисең? Димәк, үптермәгәнсең! Ул да сине үпмәгән! Үпмәгән! Кызганган мескенкәйне... хәердән булсын дигәндер инде! Ха-ха-ха!

Зәйтүнә. Үбешүен үбешмәдек әлегә...

Хәдичә. Әһә! Аңлашылды мәсьәлә, юкәдә икән чикләвек! Димәк, урлагансың! Каракның карагы булып чыктың болай булгач! Тарак карагы!

Зәйтүнә. Юк, урламадым! Ул миңа үзе бирде!

Бану. Көтүчеләргә тарак өләшүчеләр килгән ди! Тоттыр-

ганнар, бар! Хәзер авылга кайтабыз да даныктырабыз үзеңне! Ка-рак!

Зәйтүнә. Кызлар дим, җанкисәкләрем! Берүк алай дип сөйли күрмәгез! Мин карак түгел...(*Елый башлый.*) Мәгез, алай булгач... алыгыз, рәхәтен күрегез... Миңа бернинди бәхет тә, матурлык та бирмәде ул тарак... ымсындырды гына...

Кызларга таракны бирә. Алар «миңа, миңа» дип кычкырышалар, талашырга тотыналар. Шул вакыт Шайтан кыяфәтендә Кара егет килеп керә. Кызлар куркышып, таракны ташлап чыгып йөгерәләр. Зәйтүнә, җиргә сыгылып төшеп, елап кала. Шайтан егеткә әйләнә, Зәйтүнә янына килеп утыра, чәчләреннән сыйпый.

Зәйтүнә. Син? Нигә шулай мәсхәрәләттең мине? Ничек авылга кайтып күренермен? Ал тарагыңны, ал, үзеңә булсын... син бит аны миңа үзең биргән идең... Бушка килгән малның бәрәкәте юктыр, күрәсең... Бәхетсез мин, бәхетсез... ямьсез, шыксыз мин... Кызлар дөрес әйтәләр... Инде карак кушаматы тагыласы гына калган иде...

Кара егет. Зәйтүнә! Үзеңнең йөрәгеңне үзең белмисең син. Никадәр ярату, никадәр мәхәббәт уты дөрли анда...

Алар бер-берсенә тартылалар. Кара егет Зәйтүнәне үбә. Кинәт күк күкри, яшен яшьни, Зәйтүнә һушсыз булып егыла.

Кара егет. Зәйтүнә! Шушы мизгелдән синең күкрәгеңдә кеше йөрәге түгел, минем йөрәк тибәчәк. Ә синең йөрәгең миндә... Мин дә кеше булып карыйм әле. Ничек була икән ул. Син һушсыз... Кешеләр өчен йөрәкләр алышыну җиңел түгелдер, күрәсең. Ах, никадәр саф, эчкерсез синең йөрәгең! Синең кебек саф күңеллеләр дөньяда аз бит, Зәйтүнә. Хәзер син иң гүзәл, иң сылу кызга әйләнерсең. Таракның иң зур тылсымы, бәя тылсымы шул. Ах, Зәйтүнә! Синең йөрәк... (*Кулы белән күкрәген тота.*) Ә син минем йөрәккә бирешмә! Ярату шушы була микәнни? Ләйлә белән Әхмәтҗанны алтмыш еллык мәхәббәт утына салдым, дип көлеп йөргән идем... Утның да төрлесе була икән... аларга кавышырга мөмкинлек бирмәдем, тик сынмадылар... Нинди ләззәтле икән бу ярату... Зәйтүнәнең мәхәббәтенә мин тылсым белән ия булдым. Тагы бер генә үбәргә иде сине... Тик һич тә ярамый шул, мин сине үбәргә тиеш түгел! Ул заман йөрәгең кире кайтачак... Тик бу турыда беркем дә белергә тиеш түгел! Әгәр дә миндә типкән йөрәк мәҗбүр итмәсә. Зәйтүнә! Менә болар сиңа! (*Бер төенчек әйбер калдыра, таракны Зәйтүнәнең чәченә кадый, китә.*)

Зәйтүнә (*уяна*). Озак йоклаганмын! Бу нәрсә? Тарак миндә! Ә болары кемнеке? Әлбәттә, минеке! (*Төенчектән кул-*

*мәк, читек һәм башка әйберләр чыгара. Ул шат, күзендә тантаналы утлар уйный.)*

Ут сүнә.

## ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Кич булган. Әхмәтҗаннар өе. Урам яктан Л ә й л ә  ә б и керә. Сызгырырга тырыша, килеп чыкмый, җирдән таш алып, Әхмәтҗаннар тәрәзәсенә ата.
Тәрәзәдә Ә х м ә т җ а н күренә.

Л ә й л ә  ә б и. Чык әле, тор-тордан хәбәр килгән.

Ә х м ә т җ а н. Нишләп йөрисең тавык кетәклеккә менмәс борын? *(Пышылдап.)* Әни йокламаган әле...

Л ә й л ә  ә б и. Чык дигәч, чык! Сүзем бар!

Ә х м ә т җ а н. Иртәгә әйтерсең...

Л ә й л ә  ә б и. Ничек таң аттырырмын, соң булыр дип куркам...

Ә х м ә т җ а н. Җәйге төннең, хәзер таң ата...мин, ни...

Л ә й л ә  ә б и. Хуш алайса, минем исемемне оныт... иртәгәгә кадәр...

Ә х м ә т җ а н. Ләйлә дим, Ләйлә... тукта әле, бүген чыга алмыйм, әни күлмәк-ыштанны яшереп куйган...

Л ә й л ә  ә б и. Тьфү икән алайса! Бүген сөйләшмибез икән, иртәгә гәүдәмне агым сулардан эзләрсең, таба алмассың!

К а р а  е г е т узып китә. Картлар аны күрмиләр.

Әхмәтҗан югала, яңадан күренгәндә, өстендә хатын-кызлар киеме. Алар берберсен Хәлил белән Галиябану итеп хис итәләр. Тик рольләр алышынган, Әхмәтҗан — Галиябану, Ләйлә әби үзенең катгыйлыгы белән Хәлил ролендә. Тик алар белән Шайтан «дирижерлык» итә, алар, әлбәттә, аны сизмиләр.

Ә х м ә т җ а н *(җырлый).*

Тәрәзә төбем каты бал,
Ашыйсың килсә ватып ал,
Сөюләрең чынлап булса,
Галиябануым, сылуым иркәм,
Тәрәзәдән тартып ал!

Л ә й л ә  ә б и.

Билемдәге ал билбавым
Тормый кыстырган җирдә.
Үзе чакыра, үзе кача,
Җаным бәгърем, сылуым иркәм,
Чыкмый чакырган җиргә.

Ә х м ә т җ а н.

Йөгереп төштем су буена,
Суда кошлар йөзә дип.
Чыкмыйсың дип үпкәләмә,
Галиябануым, сылуым иркәм,
Куркам кеше сизәр дип.

Л ә й л ә ә б и.

Урамнардан үткән чакта
Күзем төште чарлакка,
Иңбашыңа шәлең салып,
Җаным бәгърем, сылуым иркәм,
Чыксана инде аулакка.

Ә х м ә т җ а н.

Кызып урак урган чакта,
Уч төпләрем тирләр дим,
Күптән атылып чыгар идем,
Галиябануым, сылуым иркәм,
Әнкәй сизсә тиргәр дим.

Ләйлә әби Әхмәтҗанны тәрәзәдән тартып ала.
Шайтан көлә. Әхмәтҗанның өстендә хатын-кыз киеме.

Л ә й л ә ә б и. Кара, бу кием дә килешеп тора үзеңә...

Ә х м ә т җ а н. Караңгыда күренмәс дигән идем... Әнинекен кидем...

Л ә й л ә ә б и. Бүген уенга чыгасыңмы? Әллә тагы үземә генә каңгырап йөрергәме?

Ә х м ә т җ а н. Үзеңне генә беркая да җибәрмим! Җитте! Синсез яшәү мөмкин түгел! Телисеңме, иртәгә үк яучы җибәрәм?

Л ә й л ә ә б и. Яхшылык белән бирмәсәләр, мин ябышып чыгам.

Ә х м ә т җ а н. Ярый, җаным-бәгърем, сөйләшү бер булсын. Мин иртәгә үк яучы җибәрәм.

Л ә й л ә ә б и. Хуш, җаным! Мин тыныч күңел белән китәм. Су буенда, уенлыкта күрешербез.

Ә х м ә т җ а н. Юлыңа ак җәймә.

Ләйлә әби китә. Әхмәтҗан өенә кереп китә. Шайтан кулларын уа, сикергәли.

Ут сүнә.

## БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Кечке уен. Егетләр — Габдулла, Вахит, Садыйк һәм башкалар. Кызларны көтәләр.

Габдулла (*аягында яңа читекләр, кроссовка булуы да мөмкин. Читегенә карап*). Тагы тузан кунып бетте. Аз гына селкенденңме, бер бармак калынлык тузан утыра...

Вахит. Яңгыр юк бит. Күрше авылда яуган, диләр.

Садыйк. Арабызда гөнаһлылар күбәеп китте бугай.

Габдулла. Әй Садыйк, суфиланып утырма әле. Гөнаһсыз дөнья булмас. Күңелсез яшибез диген. Бер кунак кызы да килеп чыкмый авылга.

Вахит. Бануың ишетсә, күрсәтер кунак кызын!

Габдулла. Аның да чәтер-чәтер ызгышуы... бик күңелле дип торасыңмы әллә? Шулхәтле киребеткән нәрсә, һаман үз кырыгы кырык... Егетләр, карагыз әле, кем ул бу якка килеп ята?..

Садыйк. Ята? Кайда?

Габдулла. Ятмый инде! Килә бу якка, әнә, әнә... Бирим дигән колына, чыгарып куяр юлына! Кунак кызы!

Егетләр төзәтенәләр. Габдулла кызга каршы барырга омтыла. Иелеп, читекләрен кулы белән сөртә. Вахит аңар абынып егыла. Кызның каршысына берәм-берәм килеп басалар.

Егетләр (*бергә*). Әссәләмәгаләйкүм, чибәр кыз!

Габдулла. Менә фәрештә!

Вахит. Гүзәлнең гүзәле!

Ул кунак кызы — Зәйтүнә. Аны танырлык түгел. Кием, чәч, баш, күз — гел башкача.

Зәйтүнә. Егетләр, сез кем белән исәнләшәсез?

Садыйк. Хелло, Тутси!

Вахит. Нәрсә диден син аңар?

Садыйк. Валлаһи, мин әйтмәдем, авыз әллә нәрсә сөйли!

Габдулла (*очкылык тота башлый*). Әссә... ыйк! Ыйк!

Зәйтүнә. Нәрсә булды сезгә, әллә мине танымыйсызмы?

Сәхнә түрендә Шайтан күренә, ул көлә.

Габдулла. Таны...ыйк! Ой... юк! Таны...ыйк!

Зәйтүнә. Җитәрегез инде, кая калганнар?

Вахит. Гафу итегез, кемнәр?

Зәйтүнә. Кызлар килмәдемени әле?

Габдулла. Ә-ә... кызлар! Нинди кызлар? Без сезне генә көтеп утыра идек.

З ә й т ү н ә. Җитәрегез инде, шаярта беләбез дигәч тә...
В а х и т (*алга чыгып*). Буйнос Айрес! Бисамо мучо!
З ә й т ү н ә. Исәнләштек бит инде.
С а д ы й к. Нәрсә сорадың син аннан?
В а х и т. Авыздан әллә нинди сүзләр чыга башлады малай, акылны алды бу чибәр...
З ә й т ү н ә. Бонжур, мсье Садыйк!
С а д ы й к. Нәрсә диде ул миңа?
Г а б д у л л а. Син мие сыек Садыйкмы дип сорады бугай?
С а д ы й к. Ә мин нәрсә дидем?
Г а б д у л л а. Әллә, мин мие сыек сарык дигән шикелле әйттең, ишетмәдеңмени?
С а д ы й к. Менә, малай, авыз әйткәнне колак ишетми башлавы шушы икән... Тамчы да ишетми...(*Колагын чистарта.*)
З ә й т ү н ә (*Габдулланың яңа читекләрен күреп*). О-о! Вери гут! Мейд ин Америка?
Г а б д у л л а. Юк ла, әти базардан алып кайткан иде, арчинскийлар.
В а х и т. Кара син аңлыйсың? Нәрсә дип сорады ул синнән?
Г а б д у л л а. Читекләрең бик матур, амриканский мәллә, диде.
З ә й т ү н ә. Кач пара?
В а х и т. Нәрсә качып бара?
Г а б д у л л а. Бу юлы төрекчә сорый, бәясе күпме, ди. (*Зәйтүнәгә.*) Кем белсен инде, бәрәңге саткан акчага алган идек...
З ә й т ү н ә. Күпме пышылдашырга була инде? Минем биисем килә, кая гармунчыгыз?

Садыйк уйнап җибәрә. Егетләр төртешә-төртешә биергә чыгалар. Б а н у керә.

Б а н у. Кара әле боларга! Уенны да башлаганнар! Габдулла! Җанкисәк, борыл бу якка да!
Г а б д у л л а. Нишләп йөрисең монда?
Б а н у. Менә иске авыздан яңа сүз! Синең янга уенга чыктым!
Г а б д у л л а. Бар өеңә кайт, синнән башка да урын тар!
Б а н у. Нәр-сә?!
Г а б д у л л а. Кәлшә белән кәбестә! Бар, тай, диләр сиңа!
Б а н у. Мин тай булсам, син аттыр моннан! Әле шулаймыни? Кем ул кыз! Әйт хәзер үк!
В а х и т (*бии-бии Бану янына килә*). Без үзебез дә белмибез, иностранка!
Б а н у. Минме страм! Күрсәтермен мин сезгә!

Араларына керә. Шул вакыт Х ә д и ч ә күренә.

Х ә д и ч ә. Нинди пәри туе монда? Сәлам егетләрнең асылларына! *(Аның сәламен алучы юк.)* Вахит дим, нигә селкенәсең шулкадәр? Кара әле бер генә, бәхет кошың, баллы прәннигең килде-е-е-е...

В а х и т *(биюеннән туктамый)*. Кыз булгач, әнә шундый булалар аны! Мин аның белән көннәр буе да, төннәр буе да биергә риза. Әй, мәхәббәттә нәрсә аңлыйсың соң син, тишек борын!

Х ә д и ч ә. Кем ул кыз? Кемнәргә кайткан? Хәзер мин аны чәченнән асып куям!

В а х и т. Кермә арага!.. Баллы прәнник... хуш... *(Бии.)*

Бану белән Хәдичә пыр тузып чыгып китәләр.

С а д ы й к. Уф, аякларым, коткарыгыз!

В а х и т. Булды, җитте, биисем килми...

Г а б д у л л а. Читекләр тишелде... а-а-а.

Кызларны ияртеп, Б а н у белән Х ә д и ч ә керәләр.

Б а н у. Менә күрдегезме, берүзенә күпме егет!

С а җ и д ә. Безнең авыл кызы түгел лә ул...

Х ә д и ч ә. Кара, кара, гел Садыйк янында бөтерелә...

Б а н у *(кычкырып)*. Тәк, тәк, тәк...

Бию туктала, егетләр, хәлсезләнеп, авып төшәләр.

Б а н у. Безнең кирәк юк икән бүген сезгә, ә? Егетләр! Без дөрес аңладыкмы моны? Кунак кызларының яхшы гадәтләре бар, алар киләләр дә китәләр. Без калабыз!

Г а б д у л л а *(ыңгырашып)*. Кияүгә чыксалар, аларның да кала торган гадәтләре бар...

Б а н у. Син әле шулаймыни... әй, моның рәт киткән бит... Кая, теге шартлавыгын күрик әле, чык әле уртага... *(Зәйтүнә дәшми. Ул танырлык түгел.)* Белмәсәң бел, менә боларның, безнең аяк астында аунаганнарның, ияләре бар! Ишеттеңме?

Зәйтүнә, мыскыллы караш ташлап, борылып китмәкче була. Бану аны чәченнән тартып туктата. Яулык салына. Зәйтүнәнең чәченнән көзгеле тарак килеп төшә.

К ы з л а р *(бергә)*. Көзгеле тарак?!

С а җ и д ә. Әстәгафируллаһ! Зәйтүнә ич бу!

Б а н у. Зәйтүнәне җен алыштырган!

Х ә д и ч ә. Сихерче ул, сихерче!

С а җ и д ә. Кызлар, кычкырышмагыз әле...

Б а н у. Зәхмәте кагылмасын, таегыз, арабызда шайтан бар!

З ә й т ү н ә. Нидән өркисез, кызлар? Бу бит мин, сез белгән Зәйтүнә!

Егетләр-кызлар сибелешеп, таралып бетәләр. Зәйтүнә үзе генә кала. Тарагын ала, көзгедән карый.

З ә й т ү н ә. Әнекәйләрем! Кем бу? *(Көзгенең икенче ягын әйләндереп карый. Артына карап ала.)* Мин! Бу мин! Курыктыгызмы? Гашыйк булдыгызмы? Ха-ха-ха! Шул кирәк сезгә! Ха-ха-ха!

Ут сүнә.

## АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Икенче көн кич белән. Су буе. Басмада Г а б д у л л а. Кулында төенчек. Ул Зәйтүнәне көтә.

Г а б д у л л а *(үз-үзенә сөйләнә)*. Әллә нишләтте бит бу Зәйтүнә мине. Әллә чынлап та сихере бар инде. Тартыплар китергәндәй китерде су буена. Әгәр дә ул килмәсә? Җүләр тек җүләр мин! Килерен, килмәсен белми торып, төенчек күтәреп су буена кил инде... Өйләренә генә барасым калган икән. Садыйк белән Вахит барлыгын да онытмаска кирәк. Аларда да хәйлә күп... *(Черки үтерә.)* Черкиләрнең туена туры килдем, ахры. Талап үтерәләр хәзер... Барыбер китмим! Килми калмас әле...Бану белән араны өзәргә кирәк. Авылда егетләр бетмәгән, аңар да табылыр. Ә Зәйтүнәне барыбер үземнеке итәм! Барыбер! Сүзне ничек башларга соң? Тел бәйләнә... Бәйләнә генәме, авызга сыймый башлый... сүзне ботка итә... Болай диярмен... Зәйтүнә, диярмен, мин сине әллә кайчаннан бирле яратып йөргәнмен икән, үзем генә белмәгән икән, диярмен... Синнән башка миңа берсе дә кирәк түгел икән, диярмен... Бану белән... Бану белән вакыт уздыру өчен генә йөргән идем, диярмен... Килә! Валлаһи килә! Зәйтүнә!

Көянтә-чиләкләр күтәреп, З ә й т ү н ә күренә.

Г а б д у л л а. Исәнме, Зәйтүнә!

З ә й т ү н ә. Тьфү, куркыттың бит!

Г а б д у л л а. Курыкма, Зәйтүнә, бу мин, Габдулла!

З ә й т ү н ә. Исән әле. Син икән шул. Кемнедер көтәсең, ахры...

Г а б д у л л а. Каян беләсең?

З ә й т ү н ә. Берәрсен көтмәгән булсаң, черки талатып утырмас идең...

Г а б д у л л а. Юк, беркемне дә көтмим... Булмаганны...

Су коенырга дип килгән идем, салкынайтып җибәрде шикелле...

Зәйтүнә. Явар, ахры... күптән кирәк иде. Мондый көнне, ай-һай, йөрәгендә ут булмаган кеше, су керәм дип йөрмәс!

Габдулла. Зәйтүнә!

Зәйтүнә. Нәрсә, Габдулла?

Габдулла. Дөрес әйтәсең, йөрәк яна шул...

Зәйтүнә. Их, ул ялкыннарны су белән генә сүндереп булса...

Габдулла. Зәйтүнә, минем хәлне аңладың бугай... Йә әйт алай булгач, йөрәк ялкынын икәү бергә сүндерәбезме?

Зәйтүнә. Нигә миннән сорыйсың, Габдулла? Мин кабызган ялкын түгелдер бит йөрәгеңдә?

Габдулла. Син кабызган! Зәйтүнә, син генә кабыздың ул ялкынны! Утын бирдең, суын да бир, Зәйтүнә!

Зәйтүнә чиләге белән елгадан су ала.

Зәйтүнә. Бер чиләк җитәрме? Әллә икесен дә биримме?

Габдулла. Зәйтүнә! Шаяртасың икән... Мин бит бүләк белән килгән идем... Әти базардан кәләшемә дип, бер пар читек алып кайткан иде, мә ал, сиңа булсын...

Зәйтүнә. Миңа? Кәләшеңә дип алып кайткан бит!

Габдулла. Син кәләшем бул, Зәйтүнә...

Зәйтүнә. Габдулла, тагы нәрсәләр әйтәсең бар, әйтеп бетер инде, чиләкләрем авыр ... *(Китәргә итә, Габдулланы тыңламый.)*

Габдулла. Зәйтүнә... әйтәсе сүзләр... бар иде дә...

Габдулла читекләрне кире төрә башлый. Зәйтүнә чиләкләрен алып чыгып китәм дигәндә, каршысына Вахит чыга. Габдулла куак артына поса.

Вахит. Зәйтүнә... нихәл...

Зәйтүнә. Сине күргәч бетте хәл. Син дә су коенyргамы?

Вахит. Юк ла... көтүдән кәҗәбез кайтмый калган... шуны эзләп йөри идем. Куаклар арасына бер хайван кереп киткәндәй булды, күзеңә чалынмадымы, безнең кәҗә түгел идеме?

Зәйтүнә. Юк, юк, кәҗә түгел, Габдуллалар бозавы иде бугай... арканыннан ычкынган, муенчагы өстерәлеп бара иде...

Вахит. Габдуллаларныкыдыр... аларның бозавы шулай, уҗымга чыгарга ярата. Күп йөрсә, аягын сындырырлар әле...

Зәйтүнә. Күрсәң, әйт үзләренә, килеп алсыннар. Урманга китсә, мин әйтәм, җанвар-киеккә ризык булыр... Китәсеңме басмадан, юкмы?

В а х и т. Кара әле, Зәйтүнә, суыңа бака баласы эләккән, яңасын алып бирим әле...

Суны Габдулла яшеренгән төшкә түгеп җибәрә. Габдулла сикереп чыгып йөгерә.

З ә й т ү н ә. Вахит дим, кара әле, сезнең кәҗә түгелме?

В а х и т. Юк, юк, Габдуллаларның тиле бозавы. Кара, кара, чабып китүләре дә Габдулланыкы! Мал иясенә охшамаса, хәрәм була дип әйтәләр, дөрес икән!

С а д ы й к килгәне күренә.

В а х и т. Ярый, Зәйтүнә, мин китим әле, караңгыда кара кәҗәне эзләве авыр булыр. Уенлыкка төш, яме, бергә биербез! *(Китә.)*

З ә й т ү н ә. Хуш иттек... Садыйк... Син дә кәҗә эзлисеңме?

С а д ы й к. Юк, Зәйтүнә! Мин сине эзләп килдем. Өегезгә дә кергән идем...

З ә й т ү н ә. Юкка борчылгансың, Садыйк. Рәхмәт инде... Су юлын мин яхшы беләм.

С а д ы й к. Бер генә минутка тукта әле, Зәйтүнә. Китер, чиләкләреңне үзем күтәреп торам. Мин читләтеп сөйли алмыйм, һәрвакыт турысын ярам. Гашыйк булдым мин сиңа. Ничек элегрәк күрмәдем мин сине. Менә монда, йөрәгемнең иң түрендә син, Зәйтүнә!

З ә й т ү н ә. Аягымны бөкләп кереп утырдыммы?

С а д ы й к. Көлмә әле, Зәйтүнә! Яратам мин сине!

З ә й т ү н ә. Чү, Садыйк! Мондый сүзләр алай җиңел әйтелмиләр. Күз күргән матурлыкка алданма. Һәркемнең үз язмышы. Ә беләсеңме язмыш нәрсә ул? Синең язмышың Сажидә. Ваклама язмышыңны, бәхетсез калырсың. Гафу ит, акыл өйрәтә дип уйлама, үземне-үзем дә аңлап бетермим бу араларда. Авыр миңа...

С а д ы й к. Әйттем бит чиләкләреңне үзем күтәрәм дип. Мин чынлап әйтәм, иртәгә үк яучы җибәрәм, зинһар, кире какма!

З ә й т ү н ә. Шаяртма!

С а д ы й к *(Зәйтүнәне кулыннан тота)*. Мин шаяртмыйм! Мин...

Кинәт нииндидер көч Садыйкны Зәйтүнәдән йолкып ала.

С а д ы й к. А-а! Нишлисең!

З ә й т ү н ә. Мин түгел...

С а д ы й к. Кем, кем?

В а х и т *(керә)*. Мин, кем булсын! *(Вахитны шул ук көч башка якка этәрә.)* Нәрсә төрткәләшәсең?

С а д ы й к. Үзеңне бел! Нәрсә эзләп килдең монда! Борыныңны тешләп өзәм бит!

В а х и т. Тешләткәннәр ди сиңа, тешеңне сугып сындырырмын! *(Әүмәкләшеп сугыша башлыйлар. Зәйтүнә чыга.)*

Шайтан узып китә, көлә.

## ҖИДЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Әйбәтләп ягылган мунча эче. Х ә д и ч ә, Б а н у, С а җ и д ә мунча керәләр.

Б а н у. Кызлар! Суын күп коймагыз, бездән соң да керүчеләр бар...

Х ә д и ч ә. Уф, үләм, кызлар! Ләүкәсенә менегез әле, ләүкәсенә!

С а җ и д ә. Үлми тор әле! Бик кызгансың, ахры! *(Салкын су сибә.)*

Х ә д и ч ә. Ай! Тиле! Салкын бит!

С а җ и д ә. Кара әле, ничек чыжлый, мунча ташыдай кызган! *(Тагы сибә.)*

Б а н у. Саҗидә! Шәрә көе чиләк тоттырып суга җибәрәм үзеңне! Салкын су болай да ярты кисмәк кенә калган!

Х ә д и ч ә. Бану! Себеркене мәтрүшкә белән пешерденме?

Б а н у. Мәтрүшкә генәме сиңа! Тыңкыш борын! Карлыган, имән, тал яфрагы да куштым!

Х ә д и ч ә. Кызлар! Карагыз әле, ябыктыммы азрак, юкмы?

Б а н у. Кая ул ябыгу! Бигрәк тазарып киттең соңгы вакытларда! Кызлар, адәм күрке чүпрәк дип юкка гына әйтмиләр инде... Күлмәксез йөри торган булса ничек танырлар иде микән кешене?

Х ә д и ч ә. Танымаслар ди сиңа! Әнә теге, кәкре аяклысы Бану диярләр иде.

Б а н у. Әнә теге арт йомшакларын мыймылдатып барганы Хәдичә диярләр иде.

Х ә д и ч ә. Үзеңне бел! Кызлар, карагыз әле, иң олы күкрәк Саҗидәдә икән!

С а җ и д ә. Кит, оятсыз!

Х ә д и ч ә. Шаяртабыз лабаса! Үпкәләп утырма! Зәйтүнә нишләтте үзебезне, ә? Юкса бездән дә матур кызлар авылда юк иде!

Б а н у. Бер кисәк исле сабын бетердем инде, файдасы бармы?

С а җ и д ә. Битең шалкан кебек булган инде.

Х ә д и ч ә. Чөгендер кебек диген! Кып-кызыл бит! Нигә шулхәтле ышкыйсың аны!

Б а н у. Күпме сабын бетерсәң дә юк икән. Булмаса бул-

мый икән. Таракта аның сере. Таракта! Теге Кара егет тәки югалды бит... Аның букчасында бер генә тарак булмагандыр инде.

Хәдичә. Кызлар, шым... Зәйтүнәнең тарагы хәзер монда килеп җитәргә тиеш...

Кызлар (бергә). Ничек?!

Хәдичә. Әхмәтҗан картны юмаладым. Ләйләне юындырырга чакырабыз, эссесе калса, син дә керерсең дидем.

Саҗидә (елап җибәрә). Тарактамыни хикмәт! Садыйк борылып та карамый. Гармунчы булгач, болай да бөтен кызларның күзе анда иде!

Бану. Мунча болай да юеш,тукта әле...

Хәдичә. Бакча капкасы ачылды, кем килә анда, тәрәзәдән кара әле...

Саҗидә. Әллә егетләрме?

Бану. Әхмәтҗан бабай!

Тыштан Әхмәтҗан тавышы килә.

Әхмәтҗан (тамак кыра). Эһем-эһем, мунчада кемнәр бар, мулла белән абыстай килә...

Саҗидә. Кемнәр килә ди...

Бану. Шыңшыма инде, мунча җеннәрен куркытыр өчен әйтә. (Әхмәтҗанга.) Без монда, Әхмәтҗан бабай, синме? Булдымы?

Әхмәтҗан. Булды, булды...

Хәдичә. Ничек бирде?

Әхмәтҗан. Сезнең аркада гөнаһлы булдым, кызлар! Ләйлә өчен дип сорадым мин аннан... Сезгә биреп китәм инде... Ләйләне дә юындырып, чәчләрен тарап...

Бану. Китер таракны! Килештек бит инде. Бар, Ләйлә әбине алып кил тизрәк!

Әхмәтҗан. Сездән рәхмәт ишетмәссең! Мәгез, мунча пәриләре! (Таракны ыргыта.)

Бану. Беренче мин! Көзге китер!

Хәдичә. Нәрсәгә бу таракка көзге! Тара да кара! Тара да кара!

Бану чәчен тарый башлый. Кызлар, күзләрен тутырып, Бануга карап торалар.

Бану. Йә, берәр үзгәреш бармы? Күпме тарарга була инде!

Саҗидә (лампа белән якынрак килеп). Үзгәреш бар да кебек, юк та...

Хәдичә. Кая? Нинди үзгәреш күрдең? Шул ук бит, шул ук борын!

Бану. Лампаның филтәсен күтәрә төш әле! Йә? (Чәчен артка ташлап тарый.)

С а җ и д ә. Әнекәем! Үзгәрә башладың!

Х ә д и ч ә. Кая? Кай җире?

С а җ и д ә. Бер колагың кып-кызыл булган!

Б а н у. Шул гынамы?

Х ә д и ч ә *(авыр сулап)*. Шул гына...

Б а н у. Өшегән колак ул минем! Мунчага керсәм гел кызара. Башка үзгәреш...

Х ә д и ч ә. Күренми...

С а җ и д ә. Тамчыкайларым да үзгәреш юк. Бану тек Бану.

Х ә д и ч ә. Бирегез әле таракны үземә. *(Таракны ала, тарый.)* Йә, ничек?

С а җ и д ә. Авызыңны бөрештермә... Елмайма, елмайма, әйбәт кенә тор...

Х ә д и ч ә. Әйтегез инде?

Б а н у. Көзгесеннән кара, әйтергә телем бармый!

С а җ и д ә. Аның берәр төрле догасы юк микән?

Б а н у. Белмим шул... Шайтан тарагына нинди дога укырга микән соң...

С а җ и д ә. Дога булгач дога инде... Зыяны булмас... Бисмилләhиррахмәниррахим... бирегез әле үземә. *(Таракны ала, чәчен тарый.)* Ничек, кызлар, матур күренәмме?

Б а н у.<br>
Х ә д и ч ә. } *(икесе бергә.)* Юк!

С а җ и д ә. А-а-а... соңгы өметем иде...Нишлибез хәзер?

Мунча ишеген кагалар. Ләйлә әби булып, мунчага Ш а й т а н килгән.

«Л ә й л ә». Юынып беттегезме инде?

К ы з л а р. Юк, юк, әле башладык кына... Ләйлә әби, кер, чишен, чишен...

Б а н у. Хәдичә янына ләүкәгә үрмәлә...

С а җ и д ә. Сөякләрең җылынсын бераз...

«Л ә й л ә». Рәхмәт, кызлар... туктагыз әле, бераз хәл җыям. Әхмәтҗан бик каты ашыктырды. Сулышыма капты бугай... Уф, уф...

Б а н у. Хәзер себеркене кайнарлап бирәм... Чишенә башла...

«Л ә й л ә». Мунчагыз салкын бит! Пары да булмагач, ничек чабынырмын?

Х ә д и ч ә. Салкын? Ләүкәгә менеп кара, башың пешәр!

«Л ә й л ә». Банукаем, тондыр әле берәр чүмеч ташына... тирләп утырыйм әле бераз...

Б а н у. Салам, салам, Ләйлә әби. Берне түгел, икене салам... Ләйлә әби, синең белмәгән нәрсәң юк инде бу дөньяда. Менә шушы тарак белән матур булуның тәртибен дә өйрәтеп бирсәң иде...

«Л ә й л ә». Кайдан килеп эләкте бу тарак сезгә?

Б а н у. Зәйтүнә биреп торды, бер мунчага...

«Л ә й л ә». Ә бит син булсаң, гомердә дә бирмәс иденң, Бану!

Б а н у. Эш миндәмени хәзер! Таракның файдасы тими бит әле...

«Л ә й л ә». Тели белсәң теләк, тели белмәсәң башыңа имгәк! Рәтен белеп эшләргә кирәк! Мич башыннан егылып төшүнең дә рәте бар дигәннәр! Ә монда эш нәрсәдә?

К ы з л а р. Матурлыкта!

«Л ә й л ә». Шул гынамы? Моның өч кагыйдәсе бар. Беренчесе: мунчаның сул як нигезендә үскән җиде төп карт кычыткан кирәк.

Х ә д и ч ә. Бану, йөгер, син ишек төбендә...

Бану кычыткан алып керә.

«Л ә й л ә». Шуннан, иң элек таракны салкын суда юалар, юеш чәчкә кадыйлар да ләүкәгә сузылып яталар! Шуннан соң берегез шул кычыткан белән ләүкәдәгенең үкчәләрен җиде тапкыр чапсын! Әгәр дә мәгәр шул вакытта «ах» дигән тыныгыз чыкса, таракның сихере бетә, файдасы булмый! Йә, кайсыгыз беренче?

Б а н у. Әнә Хәдичә булсын беренче. Мә таракны, чайкадым салкын суда.

Хәдичә таракны кадый, ләүкәгә сузылып ята. Бану тастымалга төреп тоткан кычыткан көлтәсе белән Хәдичәнең аякларын чабарга тотына.

Х ә д и ч ә. А-а-а! Үтерәсең! Җитте! Матур буласым килми!

Б а н у. Бөтен тәҗрибәне боздың, төш ләүкәдән! Әйдә, Саҗидә, синең чират!

С а җ и д ә. Кызлар, мин куркам...

Б а н у. Куркасың? Садыйгың Зәйтүнәгә өйләнеп куйса, кая барырсың? Ят, диләр сиңа! *(Бану Саҗидәне чаба башлый. Ике селтәнүдә Саҗидә ләүкәдән сикереп төшә.)*

С а җ и д ә. Ай аякларым, ай бармакларым! Авызкайларыма кабыйм мәллә!

Б а н у. Китегез инде! Җебекләр! Хәдичә, ал кычытканны! Каты сукма, яме?

Х ә д и ч ә. Үзең ничек, мин шулай! *(Чәбәкли.)* Бер , ике, өч...

Б а н у. А-а! Җитте! Үтерәсең! Уф! Воды! *(Еларга тотына, аңар кызлар кушыла.)*

«Л ә й л ә». Шуңа да түзмәс кеше булыр икән! Үзегезнең кем икәнлегегезне күрсәттегез, кызлар, сер бирдегез...

К ы з л а р. Үзең чабынып кара, түзәрсең микән!

«Л ә й л ә». Миңа нәрсәгә матурлык? Әхмәтҗан мине болай да ярата.

Кызлар. Нишләргә соң инде?

«Ләйлә». Аның тагы бер юлы бар.

Кызлар. Сөйлә тизрәк, югыйсә куып чыгарабыз үзеңне мунчадан!

«Ләйлә». Түгәрәкләшеп утырасыз, лампаны менә шулай уртага куегыз. Ә таракны лампа янына. Таракның көзгесеннән төшкән нур сезнең чырайларны яктыртсын. Шуннан соң чират белән беренче әтәчкә кадәр җырларга кирәк.

Кызлар. Дөресме шул сүзең?

«Ләйлә». Минем кайчан ялган сөйләгәнем бар.

Саҗидә. Кызлар, мин өйгә кайтам, җырлый да белмим...

Бану. Юк инде, җаным, бергә башладык, нишләсәк тә бергә! Җырлыйбыз!

Кызлар җыр башлый. «Ләйлә әби» фокус ясаган кебек таракны әләктерә дә мунчадан чыгып китә, тыш яктан ишеген терәтә. Яулыгын сала. Ул — Шайтан, елмая, кулында тарак.

## СИГЕЗЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шул ук төн. Зәйтүнә ялгыз. Җырлый.

Китәм инде, китәм инде,
Китсәм кайталмам инде.
Сынды сабыр канатларым,
Сабыр итәлмам инде.

Ләйлә әби керә.

Ләйлә әби. Нәрсә булды сиңа? Суга төшкән кебек йөрисең, танымыйм мин сине...

Зәйтүнә. Син дә шулай дисеңме, егетләр дә танымаган иделәр башта. Ә бүген барысы да чиратлашып, бары тик сине генә яратабыз, дип, су буеннан җибәрми аптыраттылар. Ә миңа аларның кирәкләре юк. Потлары бер тиен.Бернәрсә аңламыйм.

Ләйлә әби. Үзеңне аңламыйсыңмы, әллә аларнымы?

Зәйтүнә. Үземне-үзем аңламыйм. Менә бу төштә бушлык... Салкын бушлык. Дөньяның яме, матурлыгы киткән сымак... Кояш та җылы түгел шикелле. Җаным өши. Нишлим, киңәш бир!

Ләйлә әби. Зәйтүнә! Теләгеңә ирештең бит, нигә һаман риза түгелсең?

Зәйтүнә. Нинди теләккә, Ләйлә әби?

Ләйлә әби. Чибәрсең, матурсың, горурсың... Егетләр дә барысы да синеке, ымла гына. Сиңа тагы нәрсә җитми?

Зәйтүнә. Син дә шулай дип торгач инде, мин тагы кем белән киңәшим? Өйдә әни елый. Аларга да сан калмады миннән. Нәрсәгә кирәк булды миңа бу гүзәллек? Тормышның матурлыгы бетте минем өчен. Өметсезлек, өметсезлек миндә. Яшисем килми башлады...

Ләйлә әби. Чү, балам, чү! Кеше ишетә күрмәсен...

Зәйтүнә. Берсен дә җенем сөйми... Арыдым... Үземнән-үзем арыдым... Нишлим?

Ләйлә әби. Җенем сөйми дисеңме? Хәзер аңладыңмы инде хәлеңне? Ярый әле үземә килгәнсең. Берәр хәйләсен табарбыз, коткарам мин сине бу хәлдән.

Зәйтүнә. Өйрәт әле, Ләйлә әбекәем, өйрәт! Сине тыңларлык кына көчем бар. Кызлар да миннән читләштеләр, мунчага да әйтмәделәр... Әнә ничек җырлыйлар... Ишетәсеңме, бәхетләләр...Җырлыйлар! Ә минем елыйсым килә.

Ләйлә әби. Зәйтүнәкәем! Тарак алдың бит син теге Кара егеттән... Хәзер күзләремә карап дөресен генә әйт, ул сораган бәясен бирдеңме?

Зәйтүнә. «Тарак сатам, тарак сатам, Бәясе үбү генә...» Ләйлә әби! Үпте бит ул мине!

Ләйлә әби. Әй бала, бала! Ул вакытта әйттем мин сезгә. Кызлар! Харап буласыз, дидем! Мәхәббәткә сусаган кызлар янына һәрвакыт шайтан ияләшә, алданулар шуннан... Йөрәгеңдә дә бушлык, шуның зәхмәте... Синең йөрәгеңне урлаган бит ул, аңладыңмы... алышынгансыз... Ә менә без җиндек аны бүген... Әхмәтҗан иртәгә яучы җибәрәм, диде...

Зәйтүнә. Син...сез... ничек җиңдегез?

Ләйлә әби. Анысы соңыннан... Зәйтүнә! Әле синең эш узмаган... Әллә синең йөрәк белән Шайтанга рәхәттер дип уйлыйсыңмы?

Зәйтүнә. Минем йөрәк белән булсын да...

Ләйлә әби. Ул бит Шайтан! Нәрсәгә аңа кыз баланың саф йөрәге! Уеннан уймак чыгарырга уйлаган... Син аның тозагында түгел, ул синең җәтмәгә эләккән... Ничек диләр әле, чөйне чөй белән чыгарырга кирәк, диләрме... Менә шулай, сүз бер булсын. Зиһенеңне җуйма. Акыл безгә ни өчен бирелгән? Шайтанны да җиңә алмагач, безнең бәябез ике тиен бер акча!

Зәйтүнә. Нишлим соң?

Ләйлә әби. Акылың белән син аны кичке уенга чакыр. Акылың белән чакыр. Ул килер, синең йөрәкнең яратуына түзә алмас. Тик аны күрүгә ашыкма, түз, синең яныңа үзе килсен.

Зәйтүнә. Килмәсә?

Ләйлә әби. Килер! Ә инде аның китәр юлында Әхмәтҗан торыр. Артыш таягы белән, ишеттеңме? Хәзер әйтеп килим әле үзенә. Нык бул!

Зәйтүнә ялгыз. Ачудан шартларга житешеп, Бану, Хәдичә, Сажидә керәләр. Алар яңа гына мунчадан чыккан. Бануның кулында кайчы.

Бану. Әнә үзе! Әтрәк-әләм!

Хәдичә. Адәм тәганәсе! Син! Синең аркада барысы да!

Сажидә. Зәйтүнә! Садыйк белән минем арага кермә, зинһарлап сорыйм.

Зәйтүнә. Ә-ә-ә, шулаймыни!.. Егетләрегездән колак кагасыгыз килмимени? Сез мактанып йөргән чакта миңа рәхәт иде дип беләсезме? Йә, ничек? Бәйрәм ашы кара-каршы... Матур да алар гына...Чибәр дә алар гына... Егетләр дә аларга гына... «Синең тубал башка тарак нәрсәгә?» «Сиңа матурлык нәрсәгә?» Кем сүзләре ул, чәчбиләр? Дөнья куласа, әйләнә дә бер баса!

Бану. Менә ничек? Әле син шулай дип торсыңмы. Хәдичә, тот үзен!

Зәйтүнә. Кызлар! Тыңламагыз мине! Минем сүзләр түгел алар! Әллә нәрсә булды миңа. Һич кенә дә алай дип әйтәсе түгел идем. Сезнең егетләр...

Бану. Безнең егетләрме? Безнең егетләр тынгылык бирми башладымы сиңа? Хәдичә, тот әле бер кулыннан!

Хәдичә. Сажидә, нәрсә карап торасың!

Зәйтүнә. Кызлар, бәгырькәйләрем, туктагыз әле...

Бану. Соң инде.

Зәйтүнәне тотып алалар. Бану кайчы белән Зәйтүнәнең чәчен кискәли. Толымнары сузылып төшә. Габдулла, Садыйк, Вахит керәләр.

Егетләр. Кызлар иртәләгән бүген... Зәйтүнә дә килгән! Зәйтүнә, Зәйтүнә!

Зәйтүнәнең башы түбән иелгән. Егетләр хәлне аңлап алалар.

Габдулла. Кызлар! Кайсыгызның эше бу?

Садыйк. Сажидә, син түгелдер бит?

Кызлар дәшми. Шул вакыт Кара егет керә.

Кара егет. Зәйтүнә! Чакырдыңмы мине? Минем үземнең дә сине бик күрәсем килгән иде. Зәйтүнә! Минем сиңа күп нәрсәләр турында сөйлисем бар! Иң башта мә тарагыңны.

Зәйтүнә. Көзгеле тарак... Минем чәчләргә генә түгел, үземә дә аның кирәге юк... Үзеңә булсын... Йөрәгемне кайтар... Кайтар өметемне, кайтар мәхәббәтемне! Матурлыгымны да сиңа бирәм... Миңа бернәрсә дә кирәк түгел... кайтар йөрәгемне...

Кара егет. Мин сиңа барысын да аңлатам... Мин үзем дә сихри көч эчендә идем, Зәйтүнә... Мине дә кара көч Шайтан файдаланды, аңламадыңмыни? Бүген, бары тик бүген безнең икебезнең дә йөрәкләр бергә булганда гына җиңәбез без аны, Зәйтүнә!

З ә й т ү н ә. Аңламыйм, син кем, нигә минем күңел шулай буш соң?

К а р а  е г е т. Син бит әле минем сине чынлап та яратканымны белмисең... Мин яратам сине, Зәйтүнә!

З ә й т ү н ә. Син мине? Чынлапмы!

Егетләр Зәйтүнәнең чәчен кем кискәнне ачыклыйлар. Банудан кайчы табалар. Алар, Кара егетнең «Мин сине яратам, Зәйтүнә!» дигән сүзләрен ишетеп, айнып китәләр.

Г а б д у л л а. Егетләр, туктагыз әле, монысы кем була тагы!

В а х и т. Без белмәгән кеше, килмешәк була!

С а д ы й к. Ә нигә әле ул безнең Зәйтүнә белән серләшеп тора? Тот үзен! Тукма!

З ә й т ү н ә. Туктагыз, харап итәсез!

Г а б д у л л а. Эткә талау тимәс! Күп карап тордык, җитте! Ояты юк моның! Бәр! Бәр!

В а х и т. Кушаяклап!

Егетләр сугышалар, кызлар көч биреп тора.

З ә й т ү н ә (*каты тавыш белән*). Туктагыз! Хәзер барысын да ачыклыйбыз! Кара егет! Үп мине!

Егетләр бу сүзләрдән шаккатып бер позада катып калалар. Кара егет торып баса, аны каты гына кыйнаганнар. Ул Зәйтүнә янына килә.

К а р а  е г е т. Зәйтүнә, үп мине!

Алар кочаклашып үбешәләр. Шул вакыт яшен яшьни, күк күкри, Кара егеттән Шайтан аерылып китә дә төрле позаларда калган егетләр, кызлар арасында йөри башлый. Ул озын койрыклы, йөнтәс. Шул вакыт юан артыш таягы тоткан Ә х м ә т җ а н һәм туй күлмәге кигән Л ә й л ә керәләр. Әхмәтҗан Шайтанны куарга тотына, артыш таягы белән аңар сугам дип, егетләргә, кызларга тондыра, алар җанланалар. Шайтан көлә-көлә тамаша залы аша чыгып китә. Әхмәтҗан аның артыннан төшмәкче булганда, аны Ләйлә туктата.

Л ә й л ә  ә б и. Син кая, әнә тегеләрне дә уят!

Әхмәтҗан үбешеп торган Зәйтүнә белән Кара егеткә кагыла. Алар уянып китәләр. Оялалар, ләкин алар бәхетле. Барысы да эшнең ничек беткәнен аңлый. Уен-көлке, котлау, музыка башлана.

П ә р д ә

# ЭЧТӘЛЕК

**Повесть**

Карурманнан чыккан юлчылар.... 4

**Хикәяләр**

Сагынасыңмы, дип сорыйлар... 46
Май кырмыскасы 52
Кода килде 57
Каз утырттым 61
Әти 67
Мәскәүдә милли «перестройка» 76

**Балалар өчен хикәяләр**

Җәнлекләр кайта 82
Үтмәс товар 84
Кое чыпчыгы 87
Яңалык 89
Сөенче 90
Ипи пешерәбез 92
Ярты хәреф 97
Шәмсивафа әби гөле 99
Авылым җыры 105

**Пьеса**

Үп мине, Зәйтүнә (*Моңсу комедия*) 112

Литературно-художественное издание

*Назифа Каримова*
*(Каримова Назифа Харисовна)*

**Ностальгия**

(Повесть, рассказы, пьеса)

(на татарском языке)

Редакторы *Р.Ә.Заһидуллина*
Рәссамы *М.М.Саттаров*
Бизәлеш редакторы *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник редакторы һәм компьютерда биткә салучы *С.Н.Нуриева*
Корректорлары *Г.Г.Зиннәтуллина, Л.Ш.Шәфыйкова*

Нәшриятка 04184 нче номерлы лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 5.07.2004. Форматы 84×108 $^1/_{32}$.
Офсет кәгазе. «Antiqua» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 8,4 + форз. 0,21.
Шартлы буяу-оттиск 8,72. Нәшер-хисап табагы 9,61 + форз. 0,36. Тиражы 2000.
Заказ Э-450.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул.Баумана, 19.

**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы дәүләт унитар предприятиесе.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.